1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2018 АВГУСТ № 8

СөЕмбИКә

ISSN 0869-1398

ДАРУ САЙЛЫЙБЫЗ
үзебезнекеме, читтән кайтканымы

ЯРЫЙ ӘЛЕ АЕРЫЛГАНМЫН
ачыктан-ачык сөйләшәбез

РЕЗЕДА ХӨСӘЕНОВА СЫЙЛЫЙ
тутырган тавык

Рузалия СӨНГАТОВА:

ИПИ ТОРСЫН ТАБЫН ТҮРЕНДӘ!

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Илдар ЮЗЕЕВ

НИШЛӘТТЕҢ МИНЕ?..

Мәхәббәт, нишләттең син мине?..
Хисләрне яңарттың,
Йолдызга караттың,
Күңелне бай иттең,
Телемне бал иттең,
Зиһенне чуалттың,
Биеттең, елаттың,
Өемне гөл иттең,
Кем идем, кем иттең,
Төнемне көн иттең,
Көнемне төн иттең,
Яндырдың – көл иттең...
Нишләттең син мине, мәхәббәт?
Тилерттең, шаштырдың,
Сагышлар уяттың,
Наз гына оялттың,
Кабыздың, сүндердең,
Тыңлаттың, күндердең.
Чәчәкләр өздердең,
Сагынгач түздердең,
Ялгызым калдырдың,
Татлы яшь тамдырдың,
Күңелне нечкәрттең...
Мәхәббәт, син мине нишләттең?..

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Тәфтилә ханым. 60 нчы еллар.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

8’2018



Фото: Газинур Хафизов

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәмматова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Рузалия Сөнгатова
Фото: Анна Арахамия

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды:
2.08.2018 ел
Заказ Е-1930
Тираж 4821

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002





Август. Илдар Зарипов эше.

Баш мөхәррир сүзе



Жәйнең соңгы ае... Җәйнең бөтен төсләрен, тәмен, байлыгын, хиссиятен бергә җыйган август аена кердек. Журналыбызның бу саны да шундый: үзе хисле, үзе якты, үзе әрнүле. Сокландырырлык, үрнәк алырлык, илһамландырырлык, кыскасы. Сабагында өлгергән җимеш кебек, бөтен сынауларны узып, үз бәхетләрен татыган язмышларны бергә тупладык без.

«Ярый әле аерылганмын...» дип әйтергә көч тапкан Замирә Рәҗәпова тарихы ышаныч уятырлык.

«Ир фикере» сәхифәсендәге героебызның «Хатыным муенымда түгел, хатыным – кочагымда!» дигән сүзләре үзебезгә мөнәсәбәтне үзгәртерлек.

Еллар буе могҗизага ышанган һәм үз дигәненә ирешкән Илсөяр Мөфлихanованың кичергәннәреннән исә тормыш кагыйдәләре язарлык.

Дөньяны ышаныч һәм мәхәббәт яшәтә дип юкка гына әйтмиләрдер. Бер-береңә һәм могҗизага ышану! Кулны төшермичә, шул могҗизага ирешү юлларын эзләү! Шул чакта гына җимеш татлы була.

...Ә урамда – август. Җәй инде үтеп бара. Тик һәр җәйне кабатларга була. Безнең хыялларга чикләр юк бит?!

Гөлнара САБИРОВА





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





«ИРЛӘР КАЙДА, БЕЗ ШУНДА...»
Мәдинә Авзалова
16

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





6
ИТӘК КИГӘН ГЛАДИАТОРЛАР
Ландыш Әбүдәрова



24
«ЛӘЙЛӘНЕ ТЫҢЛАРГА КИРӘК»



20
БҮЛӘК
Гөлнур Сафиуллина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





26
ТАТАРНЫҢ БАР ДУНАЕ
Гөлнур Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



32

ИСЕМСЕЗ
Яңа исем: Альбина Гайнуллина

ЯШӘЕШ 



40

БӘХЕТКӘ ЮЛЛАР УРАУ
Гөлнур Хәсәншина



48

«БӨТЕНЛӘЙГӘ КИЛЕГЕЗ...»
Мәдинә Авзалова

ШУЛАЙ УК: 

10

НИНДИ ДАРУ ЭЧӘРГӘ?
Мәдинә Авзалова

44

«СЫРОЕД»ЛАР СЫР АШАМЫЙ
Лилия Гәрәева

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



62

ХУМУС

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

БУРЫЧ ГАФУ ИТЕЛМИ. ИЛАҺИ НИЯТ КЫЛДЫМ

«ҮЗ КОЯШЫМ ЧЫКМАС ДИМӘ» РОЗА САБИРОВА. ХИКӘЯ

ЗАНЗИБАР. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ

МИЛӘҮШӘ АЙТУГАНОВАДАН МАСТЕР-КЛАСС




ИТӘК КИГӘН ГЛАДИАТОРЛАР



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

КҮРДЕК ТӘ ТЕЛ ШАРТЛАТТЫК. КАЙБЕР АВЫЛЛАРНЫҢ САБАН ТУЕНДА ХАТЫН-КЫЗЛАРЫБЫЗНЫҢ КӨРӘШКӘ КЕРЕП БИЛ АЛЫШУЫН, МАШИНА ТӘГӘРМӘЧЕ ТОТЫП ЧАБУЫН, ПОТЛЫ ГЕРГӘ БӘЙЛӘГӘН ЯУЛЫКНЫ ТЕШЛӘРЕ БЕЛӘН КҮТӘРЕП, ТҮГӘРӘК БУЙЛАП ӘЙЛӘНҮЕН...



Инстаграм бу мизгелләрне көне-сәгате белән онлайн күрсәтеп барды. Чәчләр тузгый, көрәшергә уңайлы булсын дип кигән арзанлы футболка, тирләп, аркага ябыша, күкрәкләр атлаган саен гәүдәдән аерылам-аерылам дип селкенә, сыланып торган ыштан менә ертылам, менә ертылам дип тартыла, чигә буйлап шыбырдап тир ага, тамырлар шартлардай булып бүртә, күзләр чыгардай булып акая, ә иң мөһиме: карашларда хайвани дәрт барлыкка килә! Мәйдан да хайвани ләззәт кичерүдән үкерәме? Футбол стадионнарында яки борынгы Римдагы гладиаторлар сугышы вакытындагы кебек, халык көч биреп, теләктәшлек белдереп торамы, диюем. Юк, әллә ни түгел. Бу җәһәттән Сабантуй мәйданы икегә бүленә: берәүләр көч биреп тора, икенчеләре йөз җыера. Һәртөрле күренешне киңкүләм мәгълүмат чаралары аша үзләштерергә ияләшкән халык әлегә дәшми. Хатын-кызларны Сабантуй мәйданына көрәшкә керергә яки ат урынына җигелеп, машина өстерәргә нәрсә мәҗбүр итә? Авыр тормыш мәшәкатьләреме? Ә бәлки Сабантуйда җиңеп алган бүләк кызыктырадыр? Карагыз, менә мин нинди сәламәт, дип, үзеңне күрсәтәсе килү теләгедер? Сораулар күбәйгән саен риторик төсмер ала бара. Ә нәтиҗәләр еш кына табибка мөрәҗәгать итү белән тәмамлана: сынган колаклар, аяк-куллар, эчке органнардагы проблемаларның көчәюе, умыртка баганасына көч килүләр... Өстәвенә, репутация дигән нәрсә бар бит әле: очрашканда, ир-егетләр урамның икенче ягыннан үтүне куркынычсызрак күрә, бала-чага әниләренең итәгенә сырыша, әби-чәби авыз эченнән генә дога укый башлый...

«Pane e circenses!»

– Бездә Сабантуй регламентын кем билгели? Оештыручылар. Ә оештыручылар кемнәр? Чынлыкта, Сабантуй – традицион бәйрәм, аның алдан расланган бернинди регламенты да юк, димәк, ул традиция буенча үткәрелергә, шуннан тайпылмаска тиеш. Ә традиция шундый: татарларда хатын-кызлар беркайчан да көрәшмәгән. Мин моны белеп әйтәм, чөнки минем әти тарих фәннәре докторы, профессор Сәлам Алишев, татар халкы һәм Идел буе халыклары тарихын өйрәнгән галим буларак, бу турыда хезмәтләрендә бер сүз белән булса да әйтер иде, – ди бу күренеш турында психология фәннәре докторы, профессор Булат Алишев.

Тарихчылар әйтүенчә, Сабантуйның меңьеллык тарихы бар. Вакытлар узу белән традицион бәйрәмнең эчтәлеге үзгәргән. Мәсәлән, уңыш иярләренә ботка пешерү этабы төшеп калган. Татарстанда ул рәсми бәйрәм статусын алгач, Сабантуй авылларда һәм районнарда бер үк вакытта үткәрелә башлады. Капчык сугышы, капчык киеп йөгерү, кашыкка йомырка салып йөгерү, чүлмәк вату, әтәчкә менү, ат ярышы һәм көрәш – болар бәйрәмне Сабантуй итә торган төп уеннар. Соңгы вакытта исә мәйдан халкын шаккаттыру өчен оештыручылар нинди генә ярыш төрләре уйлап чыгармый! Хатын-кызларның, җигелеп, машина тартуы да, тәгәрмәч күтәреп чабуы да – шул сериядән.

Борынгы Рим хөкүмәте гади халык өчен цирклар, гладиаторлар сугышы, хайваннар сугышы кебек шоу-тамашалар оештырып, аларга бушлай арзанлы ризык – ипи, шәраб, май өләшүне актив куллана торган булган. Шулай итеп, ул тыныч, хыялдагы имин тормышны тудырырга тырышкан. «Ипи һәм тамаша!» дип, халык мәйданга агылган. Соңгы елларда Сабантуйларның асылын бозып, берсен-берсе уздырып, шоу ясарга тырышучы оештыручылар әнә шулай Борынгы Рим сәясәтчеләрен хәтерләтә. Югары рейтинглы шоулар, кыска вакытлы дан һәм табышка өмет итеп, чама хисен югалту җәмгыятьтә түбән инстинктларның өскә чыгуы турында сөйли. Беренчедән, оештыручыларның милли бәйрәмебез Сабантуйны рейтинг яки дан өчен кулланырга хакы бармы? Икенчедән, ни өчен гладиаторлар ролендә хатын-кызлар?

ФИКЕР

Россия Көрәш федерациясенең башкарма директоры Булат ХӘБИБРАХМАНОВ:

Милли көрәштә хатын-кыз көрәшчеләр бар. Алар спортның бу төре белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнә. Бөтен дөньяда күч кулланыла торган спорт төрләре буенча хатын-кызлар өчен аерым турнирлар үткәрелә. Шуңа да татарча көрәш буенча да турнир оештыру турында сүзләр йөри. Бу милли көрәшне тагын да популярлаштырырга мөмкин. Ә менә Сабантуйларда көрәшкән хатын-кызларга килгәндә, монда безнең катнашыбыз юк. Бу Сабантуйларны оештыручылардан тора. Шулай ук гер, штанга күтәрергә кергән хатын-кызлар да була анда. Кемгәдер ошый, кемгәдер ошамый.

Сабантуй-пати

– 1985 елларда миңа кадәрге авыл советы рәисе Сабантуйны үзенчәлеклерәк итеп үткәрү максаты белән хатын-кызлар көрәше керткән. Шуннан бирле Күгәрчен хатын-кыз көрәшчеләре белән танылу алды, – дип сөйли Балык Бистәсе Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы Альберт Сафин. Ул бу вазыйфада 1999 елдан бирле эшли. Бу урында Күгәрченнең шәл бәйләүче кызлар-апалар авылы булуын да искә төшереп үтәсе килә. – Быел Сабантуй Ураза гаетенең икенче көненә үк туры килгәч, көрәшкә хатын-кызларны кертмәдек. Алга таба күз күрер, чөнки элегрәк елларда утызлап хатын-кыз көрәшкә керә иде, хәзер инде 7-8 генә калды. Мамадыш, Теләче районыннан хатын-кызлар көрәшергә килә иде. 2008 елда җырчы Салават хатын-кызлар көрәшен карарга махсус килде. Һәркайсына үзенең бүләкләрен тапшырды. Салават призына, дигәч, бик күп катнаштылар ул елны. Нәкъ менә хатын-кызлар көрәшкәнне карарга дип Күгәрчен Сабан туена халык күп җыела, түрәләр дә килә иде.

Альберт Тәлгать улы бу күренешнең вакытлы булуын таный. Яшь кызларның көрәшәсе килеп тормый, ди ул. Аларның әни буласы бар шул әле...

«Булдырам бит!»

Ә менә 17 ел рәттән батыр калган Фәния Җәләлова:

– Сабантуй алдыннан күңел җилкенә, ашкына башлый, көрәшергә дигәндә, каннар кыза, йөрәк алгысый башлый. Көндәшне алып салуның рәхәтлеге ни тора! Әнә Салават килгән елны бер ай элек кенә операция ясаткан идем. Шул килеш батыр калдым, – ди.

Һәр сүзеннән сизелә: Фәния апада спорт дәрте, спорттагыча комарлык ташып тора. Ә бит бер ел элек кенә мәрхүм булган әнисенә дә, башка көрәшмим, дип сүз бир-



Фото: www.pixabay.com

PRESSA

гән. «Кызым, көрәшмә дип әйтмим, имгәнерсең, дип куркам», – дип әйтә торган булган әнисе. Ләкин Сабантуй мәйданына җитүгә кан үзенекен иткән. «Аллага тапшырдым инде, ни булса – шул, дип көрәшкә кердем һәм беренче урынны алып кайттым», – дип, әле дә юксыну белдерә көрәшче апа. Үзе кыз вакытыннан бирле көрәшә, абыйсы да, энесе дә көрәшчеләр икән.

– Имгәнүдән курыкмыйсызмы?

– Анысын уйлап, куркып торасың икән, көрәшкә кермә инде син, наный! – Фәния апаның «наный» дип йомшак итеп сөйләшүе эретеп җибәрә. Бер яктан караганда, минем белән «меңнәрне егардай» батыр сөйләшә, икенче яктан – йомшак сүзле, назлы авыл апасы.

– Көрәш барыбер хатын-кыз шөгыле түгел инде, «вата» бит ул...

– Наный, хатын-кыз теләсә кайсы авыр хезмәттән ватыла. Көрәштән соң да тән бер көн авыреап тора, ял иткәч үтә ул. Ә без, авыл кызлары, авыр эш эшләп үстек. Син – кыз бала, авыр эшкә тотынма, булдыра алмассың, дигән кеше булмады.

Фәния апаның сүзләрендә гапгади хаклык ята. Әйе, җыйнак гәүдәле гап-гади авыл апасы ул. Бүгенге көндә Балык Бистәсендә яшәп ята, пилмән бөгүче булып эшли. Ә күп еллар элек беренче тапкыр көрәшкә дә «Булдыра алам!» дип кергән...

Эмансипация

– Бүгенге көндә Сабантуйда хатын-кызларның көрәшүе кемнеңдер лоббие буларак бара, ә оештыручылар моңа юл куя. Хатын-кызларның көч кулланыла торган спорт төрләре белән шөгыльләнүен шәхсән үзем дөрес түгел дип саныйм. Ләкин мин, ир-ат буларак, аларның... «юләрләнүен» тыя алмыйм. Алла хакы өчен, юләрләнәселәре килә икән... Безгә, ир-атларга, хатын-кызларның Сабантуйда ат урынына җигелүе дә, көрәшүе дә кирәкми.

Күрәсең, бу – эмансипациянең бер өлешедер. Гиперкомпенсация дигән феномен бар. Озак вакытлар нәрсәдер рөхсәт ителмичә тыелып килә икән, билгеле бер чиккә җиткәч, ул агым булып бәреп чыга һәм чаманы югалта. Хатын-кызларның да феминистик дулкында ирек даулавы, яулавы әлегә ажиотаж ноктасында. Үтәр вакыт, алар тынычланыр, барысы да үз ярларына кайтыр.

Бу – иҗтимагый аң өлкәсенә карый торган мәсьәлә. Хатын-кызның башына нинди уйлар килсә дә, без аны туктата алмыйбыз инде. Хатын-кызлар тәмәке тарта, аракы эчә, сүгенә, шулай ук көрәшә дә. Әгәр дә мин бүген плакатлар тотып: «Көрәшмәгез!» дип урамга чыгам, тавыш күтәрәм икән, хатын-кызлар үзләре үк мине дошман дип игълан итәчәкләр, – дип шәрехли мәсьәләнең бу ягын Булат Сәлам улы.

Ир-атлар үзләре үк: «Хатын-кыз – ул хәзинә, аны сакларга, якларга, кайгыртырга кирәк», – ди. Ул чагында ни өчен хатын-кызлар үзләренең хәзинә икәнен онытып җибәрә соң? «Сез хәзер ирекле, ир-ат белән хатын-кыз хокуклары тигез», дигән ярлык белән ирләр җаваплылыктан кача. Ә хатын-кыз баласын таба да, тәрбияли дә, үстерә дә. Хезмәт хакы аз булган эшкә урнаша, икенче бер ир-ат кул астында эшли. Завод цехларына бара, әрҗә күтәрә, төзелештә бил бөгә, офисларда кәгазь эшенә чумып утыра, йорт сала, ипотека түли – булдыра, ир-ат белән бертигез эшли. Ә нигә эшләмәскә, тигезлек бит!

Дөньяның кайсы гына цивилизация тарихына тукталмыйк, барысында да хатын-кыз ир-ат канаты астында яши. Башта әтисенең кызы, абыйсының сеңлесе, аннан соң ана һәм ир хатыны итеп кадерләгәннәр. Ул бүген дә шулай: хатын-кыз – әни дә, апа да, сеңел дә, хатын да, әби дә. Аңа бүген дә – бөтен әхлакый кануннар, гореф-гадәтләр асты өскә килгән заманда да ир-ат канаты астындагы күләгә җитми. Феминизм – ир-атларның җавапсызлыгына каршы тору буларак барлыкка килгән агым ул. Шуңа да феминизм шаблоннары астында хатын-кызны мәсхәрәләргә кирәкми. Үзен ир дигән ирнең кайсысы әнисен, балаларының әнисен яки сеңлесен мәйданга чыгарырга риза булыр иде? Үзен хатын-кыз дигән хатын яки кызның кайсысы мәйданда гавамның түбән инстинктларын канәгатьләндерергә алынсын?

Халкыбызның йөз аклыгы булган Сабантуйны шоу көненә калдырмый гына үткәрергә ярыйдыр бит? Әлеге дә баягы йөз аклыгын югалтмый гына...

ФИКЕР

Клиник-диагностика үзәгенең баш табибы, КДМУның хезмәт медицинасы һәм гигиена кафедрасы ассистенты, югары категорияле табиб Әлфрит РӘХИМҖАНОВ:

Сәламәтлеге яхшы икән, кешене ярышларда катнашудан тыярга ярамый. Ләкин һәркемнең сәламәтлегендә бер чик була. Мәсәлән, билгеле бер авырлыктан артыграк күтәрергә, иелергә, кискен хәрәкәтләр ясарга ярамый. Андый вакытта ул табиб белән киңәшләшергә тиеш. Профессиональ спортта табиб рөхсәтеннән башка ярышларга кермиләр.

Сабантуйлардагы ярышларда кеше үз ихтыяры белән катнаша. Монда оештыручылар үз өсләренә зур җаваплылык ала. Шуңа күрә кеше күп җыела торган чара үткәргәндә, медицина бригадасы, ашыгыч ярдәм машинасы кизүен алдан хәстәрләргә тиешләр. Ярышларга кан басымы авырулы, тахикардия, брадикардиясе булган кешеләр кергәндә, аларга медицина ярдәме кирәк булуы бар, чөнки ярыш – һәрвакыт өстәмә көч куллану ул. Уен оештыручылар да катнашучыларны һәрдаим кисәтеп торырга тиеш: «Апа, авыруларың бармы, кузгалмасмы?» – дип.

Авыр күтәрүгә килгәндә, «Санитар нормалар һәм кагыйдәләр» дигән норматив бар. Бу документ, һәм анда хатын-кызга ничә метр арада ничә килограмм авырлык күтәреп барырга ярый дигән норма күрсәтелгән. Сабантуйны оештыручылар моның белән дә таныш булырга тиеш. Авыр капчыклар, герләр күтәртү кешенең эчке органнары төшүенә сәбәп булырга мөмкин. Без бит хокукый дәүләттә яшибез, бер-бер хәл килеп чыккан очракта, ярышта катнашкан кеше оештыручыларны судка да бирә ала. Гадәттә, безнең халык судлашып йөрми, ләкин эш анда түгел.

Безнең динебез дә ирләр күз алдында хатын-кызларның гаурәтләрен күрсәтеп көрәшүне тыя. Хатын-кызлар ярышын ирләр күзәтеп торырга тиеш түгел. Шуңа күрә дә ирләр һәм хатыннар ярыша торган урыннарны махсус аерып, бүлеп куярга кирәк.

СИН КЕМНЕҢ СЫҢАРЫ?



Тормыш язган хикәят

«Егет сайлап өйләнәме, әллә кыз үзенә ирне үзе сайлап аламы?» дигән сүз чыкканда, гел уйланып калам. Кемнең пары кем булачагы без туганчы ук күкләрдә – тәкъдир тактасына язылып куелган югыйсә.

Мин барып кергәндә энем, сукрана-сукрана, улын чишендереп тора иде.

– Ничә әйттем хатынга: «Баланың баш киемен әйбәтләп карап кигерт, югыйсә колаклары бөкләнеп, тырпаеп кала», – дип. Кеше янында малайны чишендерергә дә оялам...

Улының киемнәрен күтәреп, ул бүлмәләренә кереп китте.

Почмак якта оекбаш бәйләп утырган әни әллә аңа, әллә миңа, әллә үзалдына әйтеп куйды: «Күзләрең сукыр түгел – кемгә өйләнгәнеңне белгәнсеңдер... Берегезгә дә ирексезләп китереп такмадым хатыннарыгызны».

Әнинең бу сүзләре уйларымны моннан кырык еллар элек булып узган туй көннәремә алып кайтты.

...Ике елдан артык яратып-сөеп йөргән кызым бер көнне:

– Газизчик, кайчан өйләнәсең инде? Әтиләр бирәрсенә биреп җибәрмәсеннәр тагын! – дип, күңелемә ут салды.

– Ничек биреп җибәрсеннәр, – дим, – сөйләмә булмаганны! Укуым бетүгә, августта өйләнешәбез!

– Кара, син нинди тиз! Башта кыз сорарга килеп карагыз әле. Аннары менә шушы копилканы вак акчалар белән тутыра тор.

Ул минем алдыма уртасына вак акчалар сыярлык тишек ясалган калай капкач белән ябылган бер литрлы пыяла банка чыгарып куйды. Монысына аптырамадым. Танышларым арасында инде башлы-күзле булучылар шактый: аларның туй вакытында кияү белән яшь кәләшне каршы алырга чыккан балачага өстенә сибәргә акча ваклата алмыйча иза чигеп йөргәннәрен күргәнем бар. Елмаеп куйдым... Булачак хатыным хәтта бу хакта да алдан кайгырта!

Аның әти-әнисе – минем булачак әби-бабай белән, әлбәттә, таныш идем инде. Кызларына өйләнергә теләвемне, вакыт уздырыр өчен генә йөрмәвемне сиздереп тә куйган идем. Әтисе – безнең яклардан, шуңа күрә ул мине «якташ» дип, шунда ук якын итсә дә, әбиләр урамына «яз» килеп, «кар» тиз генә эрергә ашыкмады. Ана кеше үзенең баласына тормыш юлдашы итеп яхшыларның да иң яхшысы, булганнарның да иң булганы туры килүен тели. Шуңа күрә монысына кәефем кырылмады. Үземнең дә башкалардан ким булмавымны, алар гаиләсе өчен чит кеше түгеллегемне күрсәтергә тырыштым.

Август башында «копилка» тишегенә инде акча салып булмый башлады – банка шыплап тулды, безнең туебызга да санаулы көннәр генә калды.

Ул вакыттагы гадәтләр буенча өч көн туй иттек. Соңгы көнне иртән туйга кайткан кунакларны авылыбызның табигате белән таныштырырга булдык. Безнең якның ургылып-ургылып аккан чишмәләре, болын-кырлары белән сокланып йөрделәр. Сәйранда шактый йөргәннән соң, арып, кайтырга дип, авылга таба борылдык. Шул вакыт хатыным, башкаларга сиздермичә генә, җиңемнән тартты: «Әйдә, әкренрәк кайтыйк әле, өйнең кайда икәнен беләләр бит, адашмаслар». Кунаклар аз гына алга китүгә, ул мине кочаклап алды да, елап җибәрде. Бер мәлгә югалып калдым...

– Ни булды?! – дим, тәмам аптырап.

Аның җавабы мине, дөресен әйткәндә, аяктан ега язды:

– Гафу ит, Газиз, мин сине яратмыйм... Беркайчан яратмадым да... Минем күңелем бүтәндә, уемда ул гына...

Ул, күз яшьләренә буылып, үкседе дә үкседе... Аяк астында җир шуышу шулай буладыр инде... Бераздан гына телгә килә алдым. Бу минутта, нигәдер, үземнән бигрәк аны күбрәк кызгандым.

– Матурым (күз яшьләре белән җебеп бите буйлап аккан сөрмә-кершәннәр дә, елаудан кызарган борыны да матурлыгын чыннан да бозмый, киресенчә, ихласлыгы, чарасызлыгы аңа сөйкемлелек кенә өсти иде), бу сүзләреңне нигә өйләнешкәнче әйтмәдең соң? Хәзер елаудан ни мәгънә? Ике елдан артык очрашып йөрдек бит... Мине генә түгел, әти-әниләрне дә утка салачаксың! Үзеңнекеләрне дә, минекеләрне дә...

– Мин аны яратам, ә сине кызгандым, үпкәләтермен дип курыктым, – диде ул күзләремә карап. – Гафу ит мине булдыра алсаң! Гафу ит, Газиз!

Ул вакытта миңа каян килгәндер ул сабырлык – бүгенгәчә аңлый алмыйм.

– Әйдә, матурым, тынычлан, яшьләреңне сөрт тә, өйгә кайтыйк, безне югалтканнардыр, – дидем. Бер-беребезгә без шундый якын да һәм бик ерак та идек...

Кайтышлый, бүгенге хәлне бүтән искә алмаска, бер-беребезгә тугрылыклы булырга сүз бирештек.

Туйлар узып, кунаклар таралгач, хатыным бер айга пионер лагерена вожатый булып китеп барды, мин дә эшемә чыктым. Шулай итеп, Ходай безгә бер ай аерым яшәп, уйланырга, фикерләребезне бер калыпка салырга, беребез өчен икенчебез кем икәнен аңларга, хәтта сагынырга вакыт биргәндер. Бер айдан соң яңадан очраштык та, ир белән хатын булып яшәп киттек.

Моннан кырык ел элек «Кем өйләнде соң? Кем кемне сайлады?» дип, үз-үземә биргән соравым еллар кадагында эленеп калды. Тормыш иткәндә берничә тапкыр үземнекенә охшаган хәлне очратырга туры килде. Ул кешеләрнең дә тарихлары, бер каләм белән язылгандай, минекенә охшаш иде. Соравыма җавапны гомер көзенә авышкач кына таптым...

Газиз ХӘМИДУЛЛИН

PRESSA

Фармацевтлар: «Охшаш, – дип, үзебездә җитештерелгән даруларны тәкъдим итәләр. – Катнашмасы да шул ук, бәясе дә арзан...» Әмма һәр очракта да булышамы ул авыруга? Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары, фармацевтика фәннәре докторы Фәридә ЯРКӘЕВА белән сөйләшүне редакциягә килгән хаттан башлап җибәрдек. «Мин моннан 15 ел элек инфаркт кичердем. Шуннан бирле бер генә көн дә калдырмыйча дару эчәм, – дип яза Яшел Үзән районыннан Мәрзия ханым. – Озак вакытлар үткәч, даруханәдә әлеге дарулар урынына арзанлыракларны тәкъдим иттеләр. Хәзер шуларны эчәм. Әмма аермасын күрмим. Ни өчен безнең даруларны – арзанлыларын билгеләми икән тибаблар? Күрәсең, үзебездә җитештерелгән даруларга ышаныч юк».



Мәдинә АВЗАЛОВА

НИНДИ ДАРУ ЭЧӘРГӘ?

Чыннан да, табибларның бик сирәге авыруга үзебезнекен тәкъдим итә. Автор әйткәнчә, күрәсең, ышаныч юк аларга. Арзан, димәк, сыйфатсызмы? Әллә ул даруларны җитештерү технологиясе башкамы?

– Дару белән тәэмин итү – ул милләтебез куркынычсызлыгы мәсьәләсе. Россиядә «Фарма-2020» федераль программасы кабул ителде. Бик күп препаратлар шул программа буенча әзерләнә. Бездә җитештерелә торган препаратларның 90 процентына якыны – дженериклар, ягъни чит ил препаратларының синонимы. Хәзер без онкологик, гормональ чирләрне, бронхиаль астма авыруларын, югары технологияле дарулар ярдәмендә, үзебез дә дәвалый алабыз. Ә чит ил дарулары кыйммәт тора. Чөнки дару уйлап табу өчен дистәләгән еллар кирәк. Ул башта фәнни лабораторияләрдә сынала. Бер күзәнәктән – молекуладан дару хәленә килгәнче, йөзләгән сынау-тикшеренүләр үткәрелә. Ул бездә дә шулай. Әйе, сез әйткәнчә, чит ил даруларына аналоглар күп бездә. Даруханәләрдә хәзер иң элек әнә шул аналогларны – катнашмасы шул ук булган – үзебездә әзерләнгән даруларны тәкъдим итеп карыйлар. Һәрхәлдә, провизорлар шулай эшләргә тиеш.

Ләкин шунысы да бар: сирәк очрый торган генетик, онкологик авыруларга каршы даруларның күбесе бездә эшләнми. Швейцария, Америка кебек фармацевтика өлкәсендә алга киткән көнбатыш илләрендә югары технологияләрдән файдаланалар. Аларда җитештерелгән препаратлар үтемле һәм яхшы нәтиҗә бирә.

Бер уңайдан, акушер-гинекологларның фикерен дә җиткерәсе килә. Табиблар: «Бездә җитеште-

реле торган чит илнекенә охшаш дарулар тиешле нәтиҗә бирми», – дип саныйлар.

– Даруны эчеп, сынап, чагыштырып карамыйча әйтүе кыен. Әйткәнемчә, бүгенге көндә алыштыргысыз чит ил препаратлары юк түгел. Тик без бит еш кына салкын тисә дә, аз гына сызлана башласак та, әлеге дә баягы кыйммәтле даруларны сайлый башлыйбыз. Узгынчы чирләрне үзебезнең арзанлы дару белән дә җиңәргә була бит. Шикәр диабеты, кан басымы, инсульт, инфаркт, яман шеш кебек гомерлеккә озата барган чирләр һәрвакыт үзеңне контрольдә тотуны таләп итә. Ә бу исә билгеле бер сәгатьтә табиб билгеләгән даруны эчү дигән сүз. Пациентның кайберсе аны учлап-учлап эчәргә мәҗбүр. Әйтик, өч препаратны берьюлы эчтең исә, аның сәламәтлеккә зыян китерә торган өстәмә тәэсире булырга мөмкин. Шуңа, эчә башлаганчы, табиб белән киңәшергә, тартмасындагы киңәшләрне дә игътибар белән укып чыгарга кирәк. Дөресен әйткәндә, безнең халык ныклап авырый башлагач кына дәваланырга керешә. Кайчак ул соң булырга да мөмкин. Белеп һәм дөрес эчкәндә, дару файдадан башка берәүгә дә зыян китерми. Без хәзер өлкәннәргә шуны җиткерү, аларга ярдәм итү максатыннан табиблар белән берлектә җитди аңлату эшләре алып барабыз. Ул федераль программада да каралган. Болар бит барысы да безнең яшәешкә бәйле.

Бүген авылда яшәүчеләрне, шул исәптән, өлкән кешеләрне һәм инвалидларны кирәкле дарулар белән вакытында тәэмин итеп тору өчен республиканың бөтен 43 районында да сәламәтлек саклау учреждениеләренең фармация эшчәнлегенә һәм дару препаратлары сатуга лицензия алган бүлекчәләре эшли. Хәзер Татарстанда медицина оешмаларының 544 шундый бүлекчәсе халыкка тиешле хезмәт күрсәтә.

Инвалидларның күбесе социаль пакетта каралган бушлай дарудан баш тарта. Ни өчен?

– Бу хакта без инде күп сөйләштек. Бер әбидән сорыйм: «Даруга дип каралган 800 сум синең өчен күп акчамы? Ни өчен аны даруга гына тотмыйсың?» – дим. Юк, күп акча түгел икән. «Анда миңа кирәкле чит ил дарулары юк», – ди әби. Әнә бит, чит ил даруы дип кенә торалар! Бүгенге көндә республикадагы инвалидларның 67 проценты, ә Идел буе регионында хәтта 82 проценты бушлай дарудан баш тарткан. Сәбәпләре шул ук: «Кирәкле дарулар юк». Алга таба бездә дә, чит илләрдәге шикелле, дару иминлеге кертеләчәк. Әгәр дә пациентның кыйммәтрәк дару аласы килә икән, рәхим итеп ал, тик җитмәгән кадәресенә акча өстәргә генә кирәк булачак. Сораштырулардан күренгәнчә, инвалидларның 70 проценты даруга дигән акчаны көнкүреш кирәк-ярагына тота икән. Андыйларны инвалидлык төркеменнән алырга тәкъдим итүчеләр дә бар. Янәсе, алар даруга, дәвалануга мохтаҗ түгел.

Фәридә Фатиховна, халык БАДка ышана. Мәгълүматлардан күренгәнчә, аның әйләнеше, башка препаратлар белән чагыштырганда, 22 процент тәшкил итә. Ул чыннан да файдалымы? Әллә күренекле юморист Райкин әйтмешли, «Дурят нашего брата!» дияргә генә каламы?

– Килешәм. Аны бит дару итеп түгел, «азыкка биологик өстәмә» итеп саталар. БАД буларак теркәү өчен озак вакыт кирәкми. Аны дару кебек җентекләп тикшермиләр. Дару булмагач, җитештерүчеләргә куелган таләп-җаваплылык та шуның кадәрле генә. БАДның нәтиҗәсе белән кызыксынучы юк. Бәлкем, аның да организмга зыян сала торган яклары күптер. Кыйммәт торса да халык аңа акчаны кызганмый. Бу эшкә, ягъни БАДны пропагандалауга табибларны да тарталар әле. Ә пациент кемгә ышана? Әлбәттә инде, табибка...

Казан шәһәренең Мәскәү базары тирәсендә генә дә дүрт-биш даруханә. Ике-өч адымда гына урнашканнары да бар. Дөресме ул шулай? Минемчә, дару – иң күп сатыла һәм дәүләткә зур керем кертә торган тауар. Былтыргы нәтиҗәләр нинди?

– Былтыр Россия фармацевтика базарының күләме, акчага күчереп әйткәндә, 8,1 процентка үсте: 1632 миллиард сум тәшкил итте. Ә бездә ул 33,8 миллиард сум тирәсе. Үзебездә җитештерелгән дарулар өлеше акчалата 35 процент тәшкил итә. Җитештерүчеләр арасында беренче урынны – «Таттехмедфарм», аннары «НПК «Катрен», «ЦВ Протек», «Татхимфармпрепараты» һәм «Пульс» җитештерү җәмгыятьләре алып тора. Аптека учреждениеләренең саны да шактый үсә төште. Бүген республикада 869 аптека бар. Былтыр, җан башыннан исәпләгәндә, 8703 сумлык дару кулланылган. Урнашу мәсьәләсенә килгәндә, кайбер илләрдә ул, мәсәлән, халык саныннан һәм даруханәләрнең нинди ераклыкта булырга тиешлегеннән чыгып билгеләнә. Янәшәдә урнашканнары һәрвакыт конкурент булып калачак бит.

Илнең кайбер төбәкләрендә даруларны маркировкалау буенча эксперимент башланып китте. Мондый билгеләрне, штрих-кодка өстәмә итеп, һәрбер дару тартмасына куячаклар. Аның файдасы бармы? Без бу проектка кушылачакбызмы?

– Европада бу эш белән инде 2010 елдан бирле шөгыльләнәләр. Маркировка зур өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк. Сыйфатсыз, контрафактлы даруларны ачыкларга булышачак. Күз алдына китерегез: дару сатып аласың, шуны эчәсең. Чынлыкта, ул дәваламый да, зыяны да юк. Ә кулланучы бу хакта белми. Даруларны маркировкалау бу ялганга юлларны ябачак. Даруның «фальш» булуын сатып алучылар даруханәгә куелган сканерлар ярдәмендә ачыклый алачак.

Бу чит ил даруларына да кагыла. Июль аеннан «Медицина продукциясен фальсификацияләүгә һәм халык сәламәтлегенә куркыныч яный торган җинаятьләргә каршы көрәш турында Европа Советы Конвенциясен ратификацияләү турында» закон көченә керә. Димәк, ялган чит ил дарулары да сизелерлек кимер дип көтелә.

Фото: Ксения Богданова



АВЫЛ ХУҖАБИКӘСЕ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

– ЕГЕРМЕ БИШ ЕЛ ЭЧЕНДӘ УНӨЧ ЙОРТ ТӨЗЕДЕК. ҺӘРБЕРСЕН ҮЗЕБЕЗГӘ ДИП, ГОМЕРГӘ ШУШЫНДА ЯШӘЯЧӘКБЕЗ ДИП САЛДЫК. Ә АННАН ТАГЫН КҮЧЕНЕРГӘ, САТАРГА ТУРЫ КИЛДЕ... УНӨЧ ЙОРТ! ОЗЫН БЕР УРАМ ЛАБАСА БУ!







Карабаштагысы – бистәдә калыккан ике катлы беренче йорт була. Азов диңгезе буендагысы... Хәер, анысы да зур, иркен булгандыр – яңа хуҗалары әнә шушы көннәрдә 80 миллионга сатып җибәргән. Урамның бер очыннан икенчесе күренеп торган Кызыл Чишмәдә дә алар салган йортлар бишкә тулган инде. Быел «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесендә катнашкан Зилә Гыйниятуллинаны күпләр әнә шул биш йорт буенча хәтерләп калды да инде. «Авылны яшәтүче фермер», дип әйттеләр аның турында сәхнәдән.

– Ирем белән беренче тапкыр монда килгәндә бәби көтә идем. Ул мине авыл башында калдырды да, үзе булачак йортыбыз урынын карарга китте. Каршыма бер ир кеше килә, кулы белән эчен тоткан, кан гына... Хатыны кадаган икән моңа. Икесе дә исерекләр. «Без шушында яшәячәкбезме?» – дим аптырап Юныска. Һәм кинәт исемә төште... Авыл башында бер чишмә бар монда, апаның туе вакытында без шул чишмәдән су алырга туктаган идек. Җизни: «Әйдә, таралып бетеп барган авылны күрсәтәм сезгә», – дип, урамга алып кереп китте. Минем яшь чак. «Тау кадәр алтын бирәм дисәләр дә, бу авылда яшәмәс идем», – дидем шул вакыт. «Беркайчан» дигән сүзне әйтергә ярамый икән... Алдыма алтыннар чәчүче булмады менә – үзем килдем... Яшәп ятам, егерме биш ел булды инде. Безнең Бөгелмә районында Кызыл Чишмә дигән бу авыл барын да белми идем аңарчы. Апа белән хәзер дә көләбез...

Кайчандыр Кызыл Чишмә дә мәктәбе, клубы, кибетләре эшләп торган зур авыл булган. Бөгелмәгә, Әлмәткә – алардан кул сузымы гына, калалар барысын да үзенә тарткан. Башта шәһәргә балалары киткән, аннан үз яннарына әти-әниләрен алдырганнар. «Без килеп урнашкач, 1993 елда да күченүчеләр булды әле. Авылда берүзем калам лабаса, дип шундый курка идем», – ди Зилә.

...Иң беренче сыерны аларга Юниснең Оренбург өлкәсендә яшәүче әнисе җитәкләп алып килә. Шуннан башлана инде... Маллар башта биш-алты була, аннан егермегә үк җитә. Яшьлек белән барысына да түзелә. Эш күплеге – бер нәрсә, авылда тынычлык юк. Кызыл Чишмә тулы... наркоман. «Әби, бакчаңа чыгып йөрмә, бакча – безнеке. Мәк утырттык, көз килеп җыячакбыз», – дип карт-корының өйләренә кереп әйтеп йөриләр: курку да юк, өркү дә. Милиция дә, авыл советы да түгел, авылдан аларның эзен Юнис суыта. Була, барысы да була: «аңлашырга» килүләр дә, һавага яки аяк астына мылтыктан атулар да... Боларыннан котылдык, дип куанганда гына, авылга... чегән таборы килеп урнаша. Буш йортларны ачып керәләр дә яши башлыйлар.

Ул елны Зилә белән Юнис үзләренә булышырга бер гаиләне яллаган булалар. Хатыны, әлбәттә, салгалый. Анысына гына түзәр идең әле... Бер көнне шул хатын төн кунарга чегәннәрнең бароны янына китә. Югалганын сизгәч, дөнья бетереп, ире эзли башлый. «Әни ачуын әти бездән алыр», – дип куркып, аларның өч баласы сарайга, печән арасына кереп кача. Һәм... тәмәке кабызалар. Кырык метр озынлыктагы зур яңа сарай мизгел эчендә яна да бетә. Илле машина печәннән көл өеме генә кала. Ярый балалар үзләре чыгып котыла. Сентябрь аенда була бу хәл. Малларга кышлыкка нидер әзерләргә өлгерсәләр дә, баш санын киметмичә барыбер булмый. Шушы очрактан соң, Юнис кабат кулына мылтык ала – чегәннәрне авылдан сөрә. Инде, ниһаять, тынычлап эшләсәләр дә була...

– Башкалар вак суганны стаканлап кына утыртканда, мин аны алтмышар килограмм чәчтем. Базарга чыгарып сата идем. Бәрәңгене дә гектарлап үстердек. Казларны ел саен өч йөз баштан азрак асрамадык. Ел саен унбиш мендәр дип кенә санасак та, каз мамыгыннан ун елга йөз илле мендәр тутырганмын. Сарык йоныннан үзем ясаган юрганнарның санын исә белмим... Дусларга, туганнарга шактый тараттым. Икебез дә авыл баласы бит – җирдә яшәгәч, шулай эшләп көн итәргә кирәк дип беләбез.

Россиядәге фермерларның өчтән бере – хатын-кызлар.

Азов диңгезе буенда ял базасы төзегәндә дә авылны ташламый алар. (Ике мең чакрым җирне ерак дип тормыйлар: төзелеш материалларына кадәр моннан алып китәләр. Үзләренә яшәргә йорт, берьюлы илле кеше ял итә алырлык кунак өйләре салып куялар. Тик ике-өч елдан аларның барысын сатарга туры килә. Юнисның намаздагы әнисе: «Ул йортларыгызда кем ял итмәс?! Ризалыгым юк!» – дип каршы төшә: әни сүзен аяк астына сала алмыйлар.)

Диңгез буенда йортлар төзелә, ә Кызыл Чишмәдә шул җәйне... кымыз цехы ачыла. Үзләре асрарга теләгән нәселле кәҗәләрне Ставрополь шәһәренең фәнни-тикшеренү институтыннан гына сатып алып булуын белгәч, ике кечкенә улларын утыртып, иске ЗИЛ машинасында юлга чыгып китәләр. Кире кайту – үзе бер тарих! Илле чакрым саен туктап, печән чабалар – кәҗәләрне ашаталар, савалар. Алар өчен авылда махсус агач сарай төзелә. Башкортстанга барып өйрәнеп кайталар да, бөтен таләпләргә туры китереп кымыз ясый башлыйлар: пыяла шешәләрдә чыгаралар, яраклылык вакыты – нибары өч көн...

– Ул вакытта хөкүмәттән ярдәм юк иде әле. Аннан грантлар ала башладык. Беренче гранттан соң менә бу тракторга баедык. 2012 елда откан грант акчасына 40 баш үгез алдык. Аннан соңгы грантка тагын трактор алабыз дип хәл иттек. 2014 елда грант алуда инде олы улым Мансур катнашты. Миллион ярым откан иде. Ул елны ике миллион өч йөз меңгә өченче тракторны алдык. Техникасыз булмый... Узган ел исә алты миллионлык грант оттык. Менә бу КАМАЗ машинасы, үлән чапкыч, сөт үткәргеч – барысы шул акчага алын-

Фото: Ксения Богданова

PRESSA

ды. Хөкүмәт булышмаса, үз көчең белән генә боларга ирешеп булмый.

Зилә Гыйниятуллинаның хуҗалыгы – Бөгелмә районындагы иң зур фермер хуҗалыкларының берсе бүген. Өч йөз гектар җир, йөз илле баш мөгезле эре терлек, 20 ат... Йорт салган саен газ, су, ут кертәсе, документ тутырасы, җир кишәрлеге алган саен аны рәсмиләштерү артыннан йөрисе... Зилә, уенын-чынын кушып: «Бу еллар эчендә адвокат, юрист, нотариус, икътисадчы һөнәрләрен үзләштердем инде», – дип көлә.

Грантка гына өмет итеп утыра алмыйсың: аны алу да бит җиңел түгел.

Кызыл Чишмә инде күптән аларның үз авылларына әйләнгән.

– Биектауда Юнысның дусты бар иде – Нәгыйм Әмирович Сәгъдиев. Ул анда район башлыгы да булып торды. Мәрхүм инде хәзер... 2000 нче еллар башында Юнысны ул гел үзе янына чакырды. Кат-кат! «Кил, райпо рәисе итеп куям», – дип тә әйтте. Ит комбинаты директоры урынын да тәкъдим итте. Торак-коммуналь хуҗалыгын җитәкләргә дә сорап карады. «Кызыл Чишмәдән китмим», – дидем. Мин китмәгәч, Юныс та кузгала алмады. Яратам шушы авылны! Матур бит монда! Табигатен генә күр! Кайда бар тагын шундый җирләр... Авылдан башка яши алмыймдыр инде. Сыерлар белән сөйләшергә, яңа туган бозауларны сыйпарга кирәк миңа... Каядыр китәргә уйласак, Краснодарда, диңгез буенда да ята ала идек – теләмәдек. Үзеңне ирексезләп тотынып булмый мондагы эшләргә. Хәер, без башка эш белмибез дә. Беркая бармыйбыз. Бара алмыйбыз... Минем беркайчан театрда да булганым юк менә. Бу дөрес түгел, әлбәттә... Барсам, спектакльне ахырга кадәр карап бетерә алырмынмы икән – тик утырырга иялләшмәгән лабаса... Тик балалар янныбызда «эшлибез» дип янып тормаса, ярдәм итмәсә, кызыксынмаса, боларның берсенең дә кирәге булмас иде. Тырышуларыбызның дим...



Бервакыт Зиләгә Карабаш мәктәбе директоры шалтырата: «Айнур нишләп укырга йөрми?» – ди. Әни кеше аптырап кала: «Ничек инде йөрмәсен, көн саен үзем озатам лабаса», – ди. Укудан качып йөри торган бала түгел, ни булды икән дип, тәмам хафага төшә. Гаилә кич өйгә җыелгач, барысы да ачыклана. Бөгелмәдән ерак түгел терлекчелек комплексы салып яталар. Юныс шунда эшләүчеләргә үзенең экскаваторын арендага биргән. Ике белгече белән бергә. Экскаваторны аларга тапшырырга әтисе белән Айнур да барган. Руль артында аның ничек эшләвен күргәч, комплекс хуҗалары: «Экскаваторны улың белән бергә генә алабыз», – дигән шарт куйганнар... Әнисе малайны мәктәпкә илтеп куя, әтисе, артыннан ук барып, аны эшкә алып китә икән. Айнурга бу вакытта нибары ун яшь була!.. «КАМАЗ машиналарына йөк төягәндә дә, шоферлар: «Аның кебек бераү дә әкрен генә, җайлап кына сала алмый», – дип әйтәләр, – ди әнисе. – Техниканы сизә ул – кулы эшкә ятып тора. Әтисенә рәхмәт, өйрәтүче – ул. «Имтиханыңны бирдеңме? Укуларың ничек?» – дип сораганы юк аның Айнурдан, «Кайт, трактор ватылды», – дип кенә шалтырата. Ул да, абыйсы да кайтып керүгә эшкә тотыналар, аларга кушасы юк – үзләре белеп эшлиләр».

Олы уллары Мансур Казан дәүләт төзелеш һәм архитектура институтында белем ала, Айнур – Казан дәүләт энергетика университеты студенты. Егетләр авылга кире әйләнеп кайтырмы, әти-әниләре башлаган эшне дәвам итәрме?

– Кечкенәсе шәһәрдә калмаячак – анысын тәгаен беләм. Хәер, кемгә өйләнерләр бит әле... «Сез авылга кайтырга тиеш», дигән сүзне мин аларга әйтмәячәкмен. Улларымның үз тормышы, үзләре хәл итәрләр...

Әйе, кайтсалар җиңел тормыш көтмәячәген алар белә, күреп үскән. Киртәләр – адым саен. Уңышларга караганда проблемалар һаман да күбрәк.

Кәҗәләр тарихын искә төшерәбез.

Кымызлары башта бик әйбәт сатыла аларның.

Санэпидемстанция хезмәткәрләре 50 мең акча сораганга кадәр. Бирмиләр. Ә нигә бирергә? Тир түгеп, тиененә кадәр эшләп алган хәләл акча бит ул! Андый очракта нәтиҗә бер инде – «ябарга» дигән карар чыгарып китәләр. Юныс дөреслек эзләп Казанга, авыл хуҗалыгы министрлыгына бара. Шуннан соң аларга башка бәйләнмиләр. Әмма озакламый кибетләргә... Мәскәү кымызы кайтарып тутыралар. Пластик шешәгә салынган, яраклылык вакыты өч ай булган кымызны! Өч ел асрагайнан соң, йөз баштан артык кәҗәне көтүе белән Самара ягына сатып җибәрми чара калмый...

Бүген 90 баш савым сыерлары бар аларның. Көн саен 400 литр сөт савалар. Җәй башында Казаннар килеп алган, әйбәт түләгәннәр. Хәзер әнә сөткә бәя бик төшкән. «Кайбер якта литрын 12 сумга гына җыялар, дип әйтәләр, безгә 14 сум түлиләр әле», – дип куаналар. Барысын саннарга күчерә башлагач, куанырга әллә ни урын да калмый шул: люцерна орлыгының тоннасы 160 мең сум тора. Солярканың литры – 40 сум. Кышлыкка 2 мең тюк печән әзерлиләр. Шуның кадәр үк салам. 200–300 тонна фураж сатып алалар. Ә җыючылар итнең килограммына 150 сум бирәләр, иң күп дигәндә – 250 сум... Табышны җитештерүче түгел, арадашчы ала.

Эшләргә кеше таба алмау – Кызыл Чишмә кебек шәһәргә якын авылларның тагын бер проблемасы инде ул. Пенсионерлар гына яшәгән авылда эшче куллар каян килсен?! (Хәер, баштагы мәлләрдә пенсионерларны да яллап караганнар. Әмма аннары алардан баш тартканнар. «Кесәгә пенсия керсә, калган көннәрдә ничек яшисен уйламыйча, ун көн тоташтан эчәргә мөмкин», – диләр.)

Авылда кеше таба алмагач, биш ел элек Самара өлкәсеннән бер гаиләне эшләргә алып кайтканнар. Башта алар өчен дип йорт, мунча төзеп куйганнар. «Тәрәзәләренә пәрдәгә кадәр элдем», – ди Зилә. Икесенең дә паспортлары юк, ире хәрби билетына кадәр югалткан... Аларның документларын тәртипкә китерү өчен шактый тырышырга туры килә. (Хәрби билетны эзләп табу өчен Мәскәүгә, Оборона министрлыгына кадәр мөрәҗәгать итәләр!) Бала көткәннәрен белгәч, үз кулмәген кигезеп, аларны язылышырга алып бара. Карават, коляска, киемнәр – боларын да аларның туачак сабыйларына Зилә әзерли. Хезмәт хакы биргәч, беренче мәлдә кибеткә дә алар белән бергә йөри: «Минем алда аракыга үрелмәсәләр дә, он, ярма, май урынына, бөтен булган акчаны шоколад, суыра торган конфет, печеньега туздырырга мөмкиннәр. Хәзер кирәк-яракны үзем генә алып кайтып бирәм», – ди Зилә. Йортны инде байтактан алар исеменә яздырганнар, әмма газга, утка һаман да үзләре түли икән.

– Кызлары җиде айлык булып туды. Баланы тудыру йортында алып калдылар, үзен чыгардылар. Баш табиб бер көнне: «Килсен әле, бала чүпрәге булса да үткләп торыр», – ди. Машина белән илттем, кузгалып аз гына киткән идем, көзгедән күрәм – кире әйләнеп чыкты. Мин дә кире борылдым. «Әйберләремне генә алдылар, үземне җибәрделәр», – ди. «Мин сезгә уен уйнап йөримме?» – дип, баш табибка кердем. Ул аптырап китте: «Хуҗабикә калырга рөхсәт итми, эш күп дип әйтә ди бит», – ди. Үз баласына шундый мөнәсәбәт булганны, минем терлекләрне ничек әйбәт карасын инде ул? Бозау эчкәнме, ашаганмы, асты корымы – бу хакта борчылмый ул. Нишлисең, менә шундый кешеләр белән эшләргә туры килә... Шуңа күрә икәү бергә каядыр чыгып китә алмыйбыз – гел күз-колак кирәк. Бер елны Төркиягә ялга барган идек. Бөтен гомергә беренче тапкыр ял итү булды ул... Без юкта эшкә чыкмаганнар, атна буе эчеп ятканнар. Ярый әле малайлар өйдә иде.

Инде авылны яшәтү турында.

Зиләләр килеп төпләнмәсә, Бөгелмә районында Кызыл Чишмә дигән авыл күптән булмас иде, мөгаен. Алар башкаларда да өмет уятканнар. Кире кайтучылар, яңа нигез күтәрүчеләр бар. Зилә белән Юныс салган беренче йортны да сатып алучы табылган – алар үзләре күршегә, яңа нигезгә күченгән. Эшчеләр өчен дип салган йортта да инде башка гаилә яши. Алар авылда өлгерткән бишенче йорт исә әлегә яңа хуҗаларын көтә – ишеген ачып кер дә яши башла. Аларга эшкә килгән гаиләгә булыр дип торалар.

– Ә менә монда – авылның уртасында мәчет салырга хыялланам, – ди Зилә. – Иртән азан тавышына уянасым килә... Үземнең көчем җитәрме, белмим, әмма улларым аны барыбер башкарып чыгар дип уйлыйм...

Мансур белән Айнурга эш җитәрлек әле монда!

Мансур белән Айнур әтиләре ясаган ике күл тирәсен халык килеп ял итә алырлык урынга әйләндерергә телиләр: беседкалар ясарга, агачлар утыртырга... Хәер, күлләр – бүген үк Кызыл Чишмәнең матурлыгы! Карп, кәрәкә, ак амур балыклары җибәргәннәр: тирә-юньнәр хәзер балыкка йөри. («Йөрсеннәр! Акча өчен түгел, халык өчен эшләнгән эш бит. Үзләреннән соң җыештырырга гына онытмасыннар».) Юныс хәтта күлләргә төнбоекка кадәр алып кайтып утырткан булган.

Болары – күңел өчен башкарылган эшләр. Күңел өчен генә куяннар асраганнар (берара озынколаклар 400 башка кадәр җиткән!), декоратив кош-кортлар тотканнар... Бакча, ишегалды тутырып чәчәкләр үстерәләр. Туганнарга, якыннарга һәрдаим ярдәм итеп яшәүләре дә – күңел кушканга. Һәр адымнан табыш эзләүчеләрдән ерак алар. «Әтием Мияссар белән әнием Сания догалары да юл ачадыр. Кеше сөйләмәделәр, башкалардан көнләшмәделәр... Алар кебек дөрес итеп яшисе килә», – ди Зилә.

«Мал асрап кына баеп булмый», – ди ул...

Әйе, баеп булмыйдыр, бәлки. Әмма тирә-юнеңне, янәшәдәге кешеләрне үзгәртергә була.

«ИРЛӘР КАЙДА, БЕЗ ШУНДА...»



КОМБАЙНЧЫ СӨНГАТОВЛАР – БЕРЕНЧЕЛӘР САФЫНДА.

Мәдинә АВЗАЛОВА



Әйтерсең, бөтен дөньясына ут капкан. Җир өстендә тәбә куырырдай мондый эссе көннәрнең күптән булганы юк иде әле. Күк йөзе зәп-зәңгәр, хәтта ак болытлар да каядыр кереп качкан. Кызу урак өстендә: «Безнең редакциядә дә урак өсте», – дип, ашыга-ашыга юлга кузгалабыз. Ә юлыбыз – Буа ягына, аның да әле республикада иң атаклы хуҗалыкларның берсе булган – җаваплылыгы чикләнгән «Авангард» җәмгыятенә. Хәзер шулай йөртелә алар. Элек рәхәт иде ул: теге колхоз, бу колхоз... Исеменә карап кына эчтәлеге үзгәрми, дип тә әйтеп булмый. Нык үзгәргән, нык алга киткән хуҗалык бу. Дөресен әйткәндә, кая килеп эләккәнебезне соңыннан – шаулап торган иген диңгезе уртасында калып, әкияттәге сыман, каяндыр калкып чыккан урак батырлары белән өзек-өзек сөйләшүдән соң гына аңладык. Ни өчен өзек-өзекме? Чөнки безне күрүгә комбайннарын туктатып, яныбызга килгән ул егетләр белән озак гәп куертып тору мөмкин дә түгел. Сөйләшкәндә, бер – безгә, бер диңгез корабына күз төшергәләп алалар. Аңлыйбыз егетләрне: вакытның сәгате түгел, минуты-секунды кадерле алар өчен.

Хуҗалыкның генераль директор урынбасары Расых Яфизов безне юлга ук чыгып каршы ала да, үзе артыннан ияртеп китеп, иксез-чиксез иген кыры уртасында калдыра. «Әйләнеп килсеннәр инде, аннан сөйләшерсез». Ерактан тузан туздырып, җир җимертеп килгән

гайрәтле комбайнның күз ачып йомганчы тулып өлгергән башакларны йота-йота безгә якынлашуын көткән арада, Расых Әмирҗанович шактый мәгълүмат бирергә өлгерә. «Авангард» җәмгыяте 2004 елда оешкан. Мактаулы эшләре белән танылырга өлгергән әлеге хуҗалыкның бүген 28 мең гектар җире генә бар! Шуларның 16 мең гектарына бөртекле культуралар чәчелә. «Кырда 31 комбайн эшли. Ел саен яңа техника алу һәм төзелеш эшләре алып бару өчен 150 миллион сум акча сарыф ителә. 6 мең баш мөгезле эре терлеккә, 85 мең баш дуңгызга исәпләнгән фермаларыбыз бар. Аларга азык җитәрлек. Фуражларны үзебез җитештерәбез, – ди җитәкче урынбасары. – Егетләр ике сменада – иртәнге алтыдан кичке уннарга кадәр эшлиләр. Аларны ике мәртәбә ашаталар. Кирәкле запчастьлар белән тәэмин итеп торалар».

Бер комбайнерга 500 гектар җир туры килә икән. Әйе, «нагрузка» зур. Биредә ирле-хатынлы эшләүчеләр бер Сөнгатовлар гына түгел. Альбина белән Рәдис Төхвәтуллиннар да алардан калышмый. Без килгәндә, урып-җыюга төшкәннәренә атна чамасы гына узган иде әле. «Гектарыннан 40 центнер ашлык чыга, – дип куанып торган әңгәмәдәшем, бездән берничә адымда гына килеп туктаган комбайнга ишарәләп: «Әнә, килеп җиттеләр», – дип елмаеп куя.

Әле икенче елын гына кыр иңләгән өр-яңа комбайннан бер-бер артлы Рузалия белән Илгиз Сөнгатовлар төшә. «Хәзер Илгизнең кече энесе Илгизәр белән хатыны Наилә дә килеп җитә. Алар кырның теге башында ук эшли», – ди Расых Яфизов.

«Үзебез чәчәбез, үзебез урабыз»

Карашын каядыр еракка, иксез-чиксез киңлекләргә төбәп, Илгиз шулай ди. Урак өсте җитә башлауга алар кыл өстенә бастыра – чын мәгънәсендә көрәшкә чакыра торган шушы мизгел белән яшиләр шикелле.

– Комбайнга утыруыма сигезенче ел китте, – ди ул. – Үзебез чәчәбез, үзебез урабыз... Эшләгән кешегә эш бетми монда.

– Икмәген дә пешерәбез, – дип тә өстисе итә Рузалия. Ул әле икмәк пекарнясында да эшли икән. Төнге сменадан чыгып, туп-туры – кырга, иренә ярдәмгә килгән әнә.

– Авыр түгелме соң? – дибез, ишеткәнебездән хәйран калып.

– Авыр булса да, ике ай гына түзәрбез, сезонлы эш бит ул...

Ул арада Илгиз, хатынының чыгышы белән Мәскәүдән булуын, инде менә уналты ел бергә яшәүләрен әйтеп ала. Хәзер әнә үзләренең йортлары белән Буада яшиләр, ике малай үстерәләр икән.

Авыл егетенә кияүгә чыгып, Мәскәү кадәр Мәскәүдән авылга кайтып, җитмәсә, әле ирләрнең бик сирәге күтәрә алырдай эштә – комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән ханым, «кайтканыңа үкенмисеңме?» дигәч: «Яратканмын, димәк. Уналты ел бергә бит инде, – ди. Бермәл дәшми торганнан соң гына: – Язмыштыр. Сагынам Мәскәүне», – дип куя.

– Ничек таныштыгыз? – дим. – Мәскәү кайда да, Илгизнең туган авылы Исәк кайда! Аралар ерак бит...

– Мин аның туганы белән бер сыйныфта укыдым. Рузалиянең әнисе тумышы белән безнең авылдан, – дип сөйләп китә Илгиз. – Дүрт ел милициядә эшләгәннән соң, мине Мәскәүгә укырга җибәргәннәр иде. Алты ел кешедә фатирда торып укыдым. Шул вакытларда Рузалия белән таныштым.

– Кайчан да булса штурвал артына утырырмын дип күз алдына да китереп карамадым. Мин бит менеджерлыкка укыган кеше. Ә авылны бик яратам. Эштән бушасам, гел бакчада... Утыртам, сибәм, җирдә казынып гомер үтә. Бәлкем шуңадыр, кияүгә чыгып бер ел яшәгәннән соң, Илгиз: «Әйдә, авылга кайтып бер-ике ел эшләп киләбез», – дигәч, ике дә уйламадым. Шундук ризалаштым. Ике ел дия-дия уналты ел үтеп китте менә. Хәзер инде тамыр җибәрдек. Китәсе дә килми, шул ук вакытта сагындыра да. Җәй саен малайларны әти белән әни янына – Мәскәүгә җибәрә торган идек. Малайлар бабайлары белән гел бергә булды. Ул мәрхүм инде. Әнием Тәнзилә белән алар бәхетле гомер кичерделәр. Икесе дә ипле, сабыр булдылар.

Хатыннары – ирләренең ышанычлы ярдәмчеләре. Кирәк икән, алар штурвал артына да утыра.

Рузалия үзе дә аз сүзле, тыйнак... һәм бик ипле. Артыгын сөйләмәс, сүзен уйлап кына әйтер. Ул хәзер комбайнчы ярдәмчесе генә түгел, үзе дә штурвал артына утыра. Укыган да, таныкнамә дә алган. Димәк, киләчәккә планнары зурдан. «Илгизне аз гына ял иттерергә кирәк бит инде, һичьюгы чәй эчереп алырга. Андый вакытта үзем йөртәм. Бераз куркыныч, әмма күнегеп киләм инде», – ди ул үзе. Иртән килүгә эше фильтрларны өрдереп чистартудан, кабина тәрәзәсен юу-сөртүдән һәм башка шундый вак-төяк эшләрдән башлана. Ул гел ире янында. Үзе әйтмешли, бусы бит аның сезонлы эш. Башка вакытта ул Илгиз белән бергә чөгендер, кукуруз җыярга да йөргән. Кайда кушсалар – шунда, кыскасы. Эшсез генә тормаска. Яшьләр бит... тизрәк аякка басарга кирәк. Аннары... балаларны аякка бастырырга. Чәчү вакытында икенче сыйныфта укучы төпчек уллары Ленар әти-әнисе белән тракторга да утырган әле. Кемгә охшап шундый булсын инде ул?! Әлбәттә, әтисенә. Әнә бит Илгиз дә, әтисе Газиз абыйга ярдәмче булып, комбайнга 12 яшеннән утырган! Нәсел җепләре тарта, аннан беркая да качып котыла алмыйсың. Язмыш дигәнең дә шул инде ул...

– Урып-җыю беткәннән соң тракторга утырам, – ди Илгиз, киләчәккә планнары белән уртаклашып. – Безнең арттан буразнага ятып калган бодай сабакларын «төргәк»ләргә салалар. Ә без аларны, үгезләр асрый торган бик шәп фермабыз бар, шунда илтәбез, аннары җирне сөреп чыгабыз, ашламалар кертәбез. Фермаларга





салам, су, печән ташыйбыз. Кайбыч авылында сигез комбайн сыярлык цех төзеделәр. Кыш көннәрендә шунда комбайннарны карыйбыз. Бездә урак өсте кыштан ук башлана. Илгизәр белән безнең... Ул да хатыны белән эшли. Кайчак безне уздырып та җибәрәләр. Булдыра алар! Әнә, үзләре дә!

«Эше дә ошый, акчасы да ярыйсы», – ди алар.

Машинадан ашыга-ашыга төшеп, каршыбызга килүче Илгизәр белән Наилә безне кул изәп сәламли.

– Бик тоткарладык, эшеңне калдырдык, – дим Илгизгә. Ә аның исе дә китми: «Куып тотам да, узып китәм мин аларны», – ди ул шаяртуга күчеп.

«Бәбине әни карап тора»

Наилә өченче баласы белән декрет ялында. Ләкин бүгенге «сугышчан» кыяфәтенә карап, берәү дә аны ялда утыра торган кеше димәс. 19 яшеннән комбайнга утырган Наилә өчен елның бу фасылы үзе бер җитди имтихан. Илгизәренең бер каралгыдан икенче каралгыга кадәр тир түгүенә тыныч кына карап торамы соң ул?! Әнисен чакыртып алды да, җиде ае да тулмаган нәни кызчыгын аның кочагына салып, кырга – ире янына йөгерде. «Ирләр кайда – без шунда», – ди ул сораштыра башлагач. Икең бер җан булып яшәгәндә генә тормыш алга бара. Күрәсең, Сөнгатовлар бу хакыйкатьне күптән күңелләренә салып куйган. Күрәсең, аларның үрнәк алырдай кешеләре булган.

– Мин иртә кияүгә чыктым. Бер-бер артлы өч бала алып кайттым, – дип башлый сүзен күп балалы яшь әни. – Һәм берсенә дә үкенмим. Бер-беребезне аңлап, әйбәт яшибез.

Ул кияүгә чыгуының беренче елында ук, авылдашларын шаккаттырып, комбайнчы ярдәмчесе булып эшли башлый. Ире Илгизәрнең дә әле ул вакытта ярдәмче булып кына йөргән чагы. Балалар тапкан арада комбайн йөртүгә таныкнамә дә алып куя. Бүген ул, декретта булуына да карамастан, кирәк икән – комбайнчы ярдәмчесе, кирәк икән – комбайнчы. «Бергә эшләгәндә акчасы да, уңышы да бергә», – ди Илгизәр.

Ә уңышлары зур аларның. Былтыр хәтта уңыш җыюда яхшы күрсәткечләргә ирешеп, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының грантына ия булганнар. Уйламаганда-көтмәгәндә, гаилә бюджетына 100 мең сум акча керсен әле! Шул акчага өй түбәсен яптык, дип куанышалар. Илгизәр әнә «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән. Өлкән Сөнгатовлар шкафында күз карасыдай саклanган Мактау кәгазьләре, Дипломнар, саный китсәң, дистәдән артып китә. Без аларны Илгиз белән Илгизәрнең әти-әнисе – Газиз һәм Мәдинә Сөнгатовлар гаиләсенә килеп эләккәч күрдек.

«Минем киленнәрем»

– Алар минем ачык китап шикелле: эчкерсез, миһербанлы, – дип каршы ала безне ике килен-килендәшнең кайнанасы Мәдинә ханым. – Рузалия ул дәшми, сөйли башласа да, әкрен генә, таслап кына... Үз өйләренә күченгәнче, балаларның икесе дә гаиләсе белән бездә тордылар. Өйдә ыгы-зыгы, тавыш дигән нәрсә булмады. Килешеп, матур яшәдек. Хәзер дә шулай. Ике килен дә декрет ялында киңәнеп ятмады. Кайсы тугыз айдан, кайсы ике-өч ай дигәндә, ирләренә ярдәмче булып эшкә чыга торды. Эшләре авыр, сүз әйтмим, тик акчасы да әйбәт керә бит. Тагын кайчан шулай эшли аласың?! Уңышына, эшләвеңә карап, кайбер елларда икесенә 300 мең алган чаклары булды. Шуңа да малайларның





Фото: Ксения Богданова

берсе дә кредит та, ипотека да алмады. Барысы да үз көчләре белән, үзләре эшләп алган акчага.

Әниләре шулай дип куана. Шөкер, уллары эчмитартмый, тәмле телле. «Әни-әни», дип кенә торалар. «Авырып торам әле», – дисә, төн уртасында да килеп җитәләр. «Бөтен эшебезгә булышалар, – дип сүзгә кушыла әтиләре. – Мин дә кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә тырышам. Комбайн ватылдымы, трактормы, хәзер яннарына барып җитәм. Үзем дә гомер буе техника тирәсендә кайнашкан кеше ич мин».

Ул үзенең Татарстан делегациясе составында Венгриягә ике атналык укуларга баруы турында сөйләп ала. Әйтәм бит, комбайнчылар династиясе дип. Гәрчә әтисе белән әнисе ике малайны юрист итәргә тырышса да, укытып, махсус һәм югары белемнәр алып чыгарлык мөмкинлекләр тудырса да, берсе дә таныш булмаган ул сукмактан китмәгән бит әле. Илгизе дә, Илгизәре дә – республикага танылган менә дигән комбайнчылар. Алар үзара ярышып эшлиләр. «Куып тотам мин аларны», – дия-дия эшлиләр әнә. Егетләр үзләрен тапкан. Берсенең дә әле әти-әнисенә зарланып килгәне юк. Ә әти-әни, үз чиратында, аларга кулдан килгәннең бөтенесен дә эшли, ярдәм итә. «Сыерыбыз, бозаулырыбыз бар. Үрдәк-казларыбыз бар. Алтмыш буразна бәрәңге утырттык әнә. Машина алдык, мотоблогыбыз бар. Шуның белән чаптырып кына печәнгә менеп төшәбез, – дип санап китә Мәдинә ханым. – Балалар иткә, сөткә, бәрәңгегә тилмермиләр. Алар шикелле кешеләрне күргәнем юк иде әле. Шулкадәр ярдәмчел, игелекле», – дип, җитәкчеләрне дә мактап ала.

Мактарлык та шул. «Авангард»лылар бүген игенчелектә генә түгел, башка күрсәткечләр буенча да алда бара. Республикада гына түгел, илкүләм алганда да... Гомумән дә, кайбер күрсәткечләр буенча дөнья күләмендә алдынгы алар. Арттырып әйтү түгел, чыны шулай. Хуҗалык бүген Буа чикләрен үтеп, Чуашстанга чыккан. Аларның анда хәзер 400 гектар җирләре бар. Без китәргә җыенып торганда гына Илгиз: «Сигез комбайн шунда эшли», – дип әйтә куйды. Дөньяда – бер, дип мактаган дуңгызчылык фермасы да шунда икән.

Хуҗалыкны республикада гына түгел, ил күләмендә дә беләләр.

– Шушы сәгатькә (ә сәгать теле көндезге икене күрсәтә) күпме суктырдың инде? – дим.

– 360 центнер тирәсе, – ди Илгиз, – көн азагына ничек булыр тагы?

Әйбәт булыр. Яннарында «Ирләр кайда – без шунда», дип торучы эшчән хатыннары булганда бик әйбәт булыр. Расых Әмирҗанович әйтмешли, хатын-кыз эшләтә белә бит ул!





Бу дөньяда һәркемнең үз сукмагы, аркасында – һәркемнең үз биштәре. Сукмакларны да, биштәрне дә бер-берең белән алыштыра алмыйсың. Һәркайсыбызга – үзенеке! Йөгеңне күеп торып, артка таба борылып карыйсы яки барысын да онытып, алга йөгерәсе килгән чаклар – бихисап. Ә менә бүген, хәзер, бу мизгелдә яшәвеңне тою...
Нигә шулай сирәк ул?
Алар шулай яши. Нәкъ менә шушы көндә! Һәр шәфәкъның бары бер генә тапкыр булуын, аның башка кабатланмавын тоеп... Ходай биргән иң зур БҮЛӘКләренең кадерен аңлап, рәхмәтле булып.
Шулай, сынаулардан кеше тормыш тәҗрибәсенә баеп чыгарга тиеш... Илсөяр МӨФЛИХАНОВА кичергәннәр кемгәдер – сабак, кемгәдер өмет булып яңгырар.

БҮЛӘК

«Менә бу анализларны тапшырырсыз... Ә монысы УЗИга юллама... Анысын әле соңрак, ике атнадан гына...

Нәрсә хакында сөйли ул? Нигә һаман әйтми? Бер сүз дәшмәвемнең сәбәбен яңа аңлаган табиб кинәт миңа күтәрелеп карады:

– Әле берни дә белмисезмени? Сез йөкле, бала көтәсез!

Анализның нәтиҗәсен башкалар алдан регистратурадан белешә икән. Ә мин шалтыратмадым... Күз яшьләре – шатлыкның да юлдашы... Бу көнгә алып килгән юлым шактый озын булды шул...»

Барысы да инстаграмдагы бер профильдә табиб-неонатолог язмасына тап булганнан соң башланды. ЭКО ярдәмендә туган балалар турында язган иде ул. Алар нәкъ башкалар кебек дигән: үсеп җиткәч, үзләре нәсел калдырырга сәләтсез булалар дигән сүз – уйдырма. Кырык ел элек «пробирка»дан дөньяга килгән Луиза Джой Браун әнә күптән әни инде. Әмма мине язма үзе түгел, аның астындагы комментарийлар шаккаттырды. Үзеннән аерылып торган кешеләрне нигә кабул итә алмый безнең җәмгыять? Нигә аларга карата бу кадәр кырыс ул? Мин инде бу вакыт корсаклы идем: үземне түгел, үземнән бигрәк, ЭКО аша үтәргә мәҗбүр булган хатын-кызларны җәлләп, машинамда утырган килеш озак еладым ул көнне. «Инстаграмда үз блогымны алып барырга, барысын да ничек бар – шулай сөйләргә кирәк», дигән карарга да шул көнне килдем шикелле. Әни була алмау. Хатын-кыз өчен моннан да зуррак кайгы, әрнү бармы икән?! Аңа болай да чамасыз авыр, ә тирә-юнендәгеләр аның саен җанын талкыйлар: очраган саен гел бер сорау бирәләр: «Кайчан бәби алып кайтасың инде?» Миңа да бик еш ишетергә туры килде бу сорауны.

…Гинекологларның чираттагысына күренергә бардым. «Ашыгыч рәвештә операция ясарга кирәк», – дип, шул көнне сигезенче кеше итеп язып та куйды ул. Барысы да шундый тиз булды: кулымда әзер анализларым бар иде – хирург пычагы астына ятуымны сизми дә калдым. Әмма иң «кызыгы» операциядән чыккач башланды. Яныма табиб керде һәм башкаларның палатадан чыгып торуын сорады. «Кисталарыгызны алдык, аналык бизләренә кагылмадык. Аналык көпшәләрен дә тикшердек: алар уздырмый. Сез бала таба алмаячаксыз. Ярты елдан ЭКОга барырга кирәк булачак», – диде ул миңа. Хәлемне күз алдына китерәсезме? Мин бит әле яңа гына наркоздан айныган, шундый операция кичергән. Хирург пычагы астыннан чыгам да, терелэм дип өметләнгән. Ирем моңа өметләнгән. Һәм… шушы хәбәр. Салкын карга чыгарып бастырып, өстемә бозлы су коюю белән бер иде бу…

Аннары инде еллар буена сузылган көрәш башланды. Процедуралар, дарулар, гормональ препаратлар, лазер терапиясе, сөлек салу… Бөтенесен хәтерләмим дә. Ай саен могҗиза булыр дип көтеп яшәдем. Һәм ай саен өметем өзелде. Үземне никадәр кулда тотарга тырышсам да, барыбер авыр. Бер-бер артлы алты операция генә кичердем. Һәрберсе алдыннан табиблар: «Монысы – соңгысы. Аннары бар да әйбәт булачак», – дип вәгъдә итте. Һәм тагын барысы да яңадан кабатланды…

Эштән китәргә теләгәнемне чираттагы процедураларның берсендә ятканда аңладым. Хастаханәдә икәнемне дә беләләр, әмма эш буенча бертуктамый шалтыраталар. Һаман җавап бирергә, нәрсәнедер хәл итәргә кирәк – кулдан телефон төшми. Организмың турында уйламагач, аны сизмәгәч, сиңа сөлек салуларыннан ни мәгънә?! Ирем белән утырып сөйләштек тә уртак фикергә килдек: бала алып кайтырга телибез икән, карьерам турында онытырга кирәк.

Мин – гарәп теле белгече. Тәрҗемәче. Гарәп хәрефләре белән 5 яшьлек чагымда ук Әхмәт бабам таныштырган иде. Тугыз яшемә кадәр аның белән үстем. Бабам – минем әкиятчем, укытучым, илһамчым… Аның әтисе мулла була, сөргенгә сөрелә. Әхмәт бабамның күңелендә якыннары өчен курку гомерлеккә калган, күрәсең: ул үз балаларына дин турында сөйләмәгән, безгә, оныкларына гына ачылды. 12 яшьлек чагымда әниләр Сириягә өч айга укырга – тел өйрәнергә җибәрделәр. Группада иң кечкенәсе дә, телне бөтенләй белмәгәне дә мин генә идем. Башта еладым инде… Әмма имтиханнарны калганнар белән бергә тапшырдым! Аннан кайткач, курсларга йөрдем, үзебездә дә гарәп теле дәресе керә башлады. Мин мәктәпне тәмамлаган елны, әни урамда очраклы гына бер танышын очраткан һәм ул аңа: «Грант белән Мисырга укырга китәргә була. Илсөяр анда барырга тиеш», – дигән. Шулай итеп, киләчәгем хәл ителде… Биш ел Мисырда белем алып кайтканнан соң, югары уку йортларында гарәп теле укыттым. Тәрҗемә итүемне күреп, мәдәният министрлыгына, Президент Аппаратына төрле чараларга чакыра башладылар. Аннан – Президент Аппаратының Тышкы элемтәләр департаментына, Азия һәм Африка илләре секторына тәрҗемәче итеп эшкә алдылар.

Булачак ирем белән шунда эшләгәндә таныштым да инде. Җитәкчем иде Искәндәр. Мин департаментка килеп ярты ел узгач, алар хатыны белән аерылыштылар. Тагын ярты ел узгач, ул мине «күрде». (Үзе соңыннан шулай сөйләде: «Кабат гаилә корырга дип ниятләгән идем инде. Документлар белән яныма син кердең. «Нигә каяндыр читтән, еракτан эзләргә, менә бит янымда нинди кыз бар, дип уйладым», – диде.) Шулай итеп, без өйләнештек. Ә бераздан миңа: «Сез бала таба алмаячаксыз», – диделәр…

Күңелеңдә Аллаһы Тәгаләгә ышану булса, бу юлны узу җиңелрәк.

Искәндәр ЭКО ясатырга каршы иде. Интернеттагы форумнардан бу процедура хакында ул шактый укыган, ә анда ни генә язмыйлар?! Имеш, «пробиркадан» туган балалар үзләре дә табигый юл белән бала таба алмаячак, әни кешенең сәламәтлеге белән бәйле проблемалар башланачак – чәче, тешләре коелачак, яман шеш авыруы килеп чыгачак… Ә минем инде көчем беткән иде: табибтан табибка йөреп, операция ясатып, дару эчеп… «Йә ЭКО ясатабыз, йә башка берни дә эшләмибез, туктыйбыз – минем белән аерылыша аласың», – дидем.

Хатын-кызның бала таба алмавы хакында бездә кычкырып сөйләшергә гадәтләнелмәгән. Дөрес, миңа да бу хакта инстаграмда язу бик рәхәт түгел. ЭКО турында уйдырмалар байтак, ә уңай мисаллар юк диярлек икәнен аңлагач тотындым язуга. Нигә юкмы? ЭКО аша узып, әни булган хатын-кыз моны тизрәк онытырга тырыша. Ул бит хәзер бәхетле, аннан моңа вакыты да юк – иртәсе дә, киче дә бала янында уза. Ә форумнарда күбрәк ЭКО аларга көткән нәтиҗәне бирмәүчеләр утыра: бар дөньяга үпкәне, җандагы авыртуны каядыр түгәргә, чыгарырга кирәк бит. Миңа мөрәҗәгать итүче кызларның ЭКО белән бәйле сораулары бик күп. Әмма безнең сөйләшү ешрак «пәрдә артында» бара. Турыдан-туры сорарга күпләр кыенсына. Оялалар. Нигә оялырга, аңламыйм? Бала тапмас өчен мин менә үзем белән махсус бернәрсә дә эшләмәдем бит. Сәбәбен беләм, әмма анысын сөйлисем килми, миңа гына бәйләнмәгән ул. Язмышым, узарга тиеш юлым шундый булган, димәк… «ЭКО ясатырга җыенуыбыз хакында беркем белән сөйләшә алмыйм. Хәтта туганнар да аңламый», – дип язалар. Минем дә сөйлә, бүлешер кешем булмады. Диндәгеләр моны, гомумән, «Ходай эшенә кысылу» дип саный. Ничек алай була алсын икән ул?! Алайса протез, кардиостимулятор, ясалма сулыш алу аппаратыннан да баш тартыйк, хастаханәләрне ябыйк. Дөнья барлыкка килгәндә дару да булмаган бит. Аллаһы Тәгалә галимнәргә аларны ясау юлларын үзе күрсәткән ләбаса.

Фото: гаилә архивыннан

PRESSA

Әни булу өчен шулкадәр киртәләр уза алуыбыз өчен горурланырга кирәк безгә! Юк, башка хатын-кызлардан ким түгелбез. Хәтта өстенрәк тә әле! Бернигә дә карамыйча, ирләребез безнең белән кала. Димәк, яраталар, ялгыш кына балага узган өчен өйләнмиләр безгә.

Бала таба алмаган хатын-кызның ниләр кичерергә мәҗбүр булганын күпләр, мөгаен, чамаламыйдыр да. Бездә менә уйламыйча сорау бирергә яраталар. «Кайчан кияүгә чыгасың әле?» – дип, башта миннән беренче тапкыр кияүгә чыкканчы сорадылар. Югыйсә студент кына идем әле. Аерылышкач: «Тагын кайчан чыгасың?» – дип сорарга керештеләр. Аннан инде: «Нигә бала алып кайтмыйсыз? Әллә теләмисезме?» – дияргә тотындылар. «Бик телим, әмма таба алмыйм, миндә менә шундый-шундый диагноз», – дип җавап бирә башладым. (Мондый җавап ишеткән кеше ул сорауны башкаларга тагын бирерме икән?) Үземнән бигрәк, бу сорауга җавап бирергә авырсынган кызлар өчен шулай дия идем. Нигә урынсыз сораулар яудырырга, нигә башкалар тормышына тыкшынырга? Яшьләр өйләнешкән генә: бәлки әле бала табарга теләмиләрдер, ниндидер башка планнар корганнардыр, укыйсылары киләдер, сәламәтлекләре начардыр... Һәм, гомумән, туй узуга бала туарга тиеш дип кайда язылган? Мондый кагыйдә барын мин үзем белмим.

Балагызга нәрсә бүләк итәргә белмисезме? Вакытыгызны бүләк итегез!

Бала таба алмауның сәбәпләре күп инде аның.

Әмма бу очракта физик хәлдән бигрәк, рухи халәтнең мөһимрәк икәнен кызларга да аңлатам. Табиблар үзләре дә шулай ди, әллә нинди диагнозлар белән, өмет бөтенләй юк, дигәндә дә узучылар бар, диләр.

Гаилә баланы кабул итәргә әзерме, юкмы – моннан да күп тора. Искәндәр белән безнең мөнәсәбәтләр шунда ук көйләнмәде. Әни белән дус кызым: «Икегез ике якка китәсе җиңел ул, башта араларны җайлар өчен көрәшеп кара», – дип киңәш биреп тормаса, мөгаен, ярты елдан инде аерылышкан булыр идек. Ярый әле ул чакта ук узмаганмын, бала бит барысын да катлауландырыр иде дип, соңыннан сөендем дә. Без бит аннары баласыз да бергә яшәргә риза, әзер булган хәлгә килеп җиттек. (Күңелеңдә иреңә (хатыныңа) карата үпкә сакламас өчен, бер-береbelән сөйләшергә кирәк. Нәрсәдер ошамый икән, азрак тынычлангач, мин аны Искәндәргә әйтәм. Хаклы булмыйм икән, гафу үтенәм. Үзе кайчан да булса аңлар дип йөрү, читләтеп әйтү дөрес түгел бүгенге заманда. Һәркайсыбыз каядыр ашыга, кулыбыздан телефон төшми – гел нидер хәл итәбез, башка нәрсәләр хакында уйларга вакытыбыз да юк бит безнең.)

Күп хатын-кызлар: «Кияүгә чыкканмын икән, минем дә балам туарга тиеш», – дип саный. Кешенеке бар бит, диләр. Психологик яктан үзләре исә моңа әле әзер түгел. Шуңа да ул гаиләгә бала килергә ашыкмый. Аралашканда кайберләреннән хәтта: «Ә сез чынлап та бала табарга телисезме соң?» – дип тә сораганым бар. Кемдер җаваплылыктан курка, авырлыктан.

Көтелгән шатлыкка ирешү өчен хатын-кызга... тынычлану, энергиясен башка юнәлешкә борып җибәрү дә җитә бугай кайчак. Эштән киткәч, мин үзем фотосурәткә төшерү белән чынлап торып мавыга башладым. Бик кызыксам да, моңарчы вакыт җитми иде. (Һәр көнне иртәнге алтыда куе каһвә ничек кирәк булса, бу шөгыльсез дә шулай яши алмыйм!) Аннан француз теле өйрәнергә керештем. Монысы да – мәктәп елларыннан ук килгән хыялым. (Әхмәт бабам: «Син җиде тел белергә тиеш», – дия иде миңа. Алты телдә сөйләшәм, аралашам, җиденчесе нинди булырга тиешлеген генә хәл итә алмыйм әле.)

Ә агачтан нидер эшләү – күптәнге хоббием. Иске җиһазларны реставрацияләргә ярату исә әнидән күчте бугай. (Без өйләнешкәндә Искәндәрнең өендә дизайнер ремонты ясалган иде. Әмма минем өчен ул өйнең җаны юк кебек тоелды. «Иске-москыны җыю», – дип кенә караган иде ирем хоббиема, хәзер исә үзе дә мавыга. Башта әбисенең әнисеннән калган өстәл кайтты безнең өйгә, аннары – кайнанам бакчасындагы буфет, әнинең апасы диварында эленеп торган көзге... Һәркайсының тарихы бар. Алар өйдә бөтенләй башка төрле мохит тудыра. Кызганыч, күпләр аларны үзләренең интерьерына ничек кертергә икәнен генә белми. Югыйсә аның бер авырлыгы юк. Иске җиһазларга яңа сулыш өрергә дип күп китерәләр – остаханәм бушап тормый. Подносларны да башта туганнар, дуслар өчен генә ясый идем, инде заказлар килә. Кызыксыну булгач, мастер-класслар үткәрә башладым. Без хәзер Югары Осланда, әнием йортында яшибез. Өебезнең идәннәре, түшәме, ишекләр, җиһазлар – барысы да миңа күргәзмә материал булып хезмәт итә.)

ЭКОга керергә чират җиткәндә, шулай итеп, мин барысын да үз агымына куйган идем: булса – әйбәт, булмаса, димәк, шулай язган. (Искәндәр дә шулай уйлаган: «Бер тапкыр гына ясатып карыйбыз да, булмаса, аннары тәрбиягә бала алабыз», – дигән.) ЭКОны бер тапкыр ясатудан бик сирәкләр балага уза. Безгә исә шундый бәхет елмайды! Миңа ике эмбрион урнаштырганнар иде. Аларны Муса белән Мәрьям дип йөрттем. Сигез атналык чакта берсе генә калганын әйттеләр. Улым туса, бабам исемен кушармын дия идем, үзеннән-үзе Муса булып китте менә.

Баланы бик җиңел күтәрдем. Тугыз ай буе канатланып очтым гына! «Миңа бит бу бәхетне син бирдең!» – дип, Ходайга көн саен рәхмәт укыдым. Әни булуны күрмәячәкмен, белмәячәкмен дигән уй белән килешеп беткән идем бит инде... Соңгы көнгә кадәр рульдә йөрдем. Бала бүлмәсен ремонтладым. Түтәлләр ясап, нидер утырттым... Иң бәхетле чорым булды бу!

Гадәттә, ЭКО ясатучылар баланы алдан ук ярып алдырырга ризалашалар. Ә мин: «Үзем табам», – дидем. Әмма бала зур һәм дөрес ятмый булып чыкты.

Ун сәгатькә сузылган тулгаклардан соң, операциягә алып кереп киттеләр...

Боларның барысы аша узмасам, нинди әни булыр идем икән, белмим. Күп нәрсәләргә башкача карыйм. Балага кычкыру, кул күтәрү турында уйлый да алмыйм: аны кочагыма алганчы үткән юлым гел күз алдымда. Әлбәттә, бөтен нәрсәне дөрес кенә эшләп бетереп булмый, андый әни кеше юктыр да. Әмма бик күп нәрсә эчке халәтебездән тора. Ә бала моны сизә. Әле бассейнга бардык та, тренер: «Күр, улыгыз судан ничек курыкмый, чөнки сез аны суга кертергә курыкмыйсыз», – диде. Әни булу шатлык кына китерсен иде дип телим. Мусам – безгә Ходай бүләге! Аның исән калуы да могҗиза булды. Өмет аз, калса да, үсеше тоткарланачак, диделәр. Аллага шөкер, ул яшьтәшләреннән калышмый, хәтта алдарак та бара.

Соңгы вакыт безгә гел бер сорау бирәләр: «Мусагыз зур инде, 2 яшь тулды. Кайчан икенчесен алып кайтасыз?» – диләр. Әйе, мин дә икенче балам тууын, зур гаиләм булуын телим. Тик кайдан алырга аны? Кайсы кибеттән? Ходай безгә болай да шундый зур бүләк бирде, ә мин үрелеп карап: «Безгә дип анда тагын нәрсә булса да әзерләдеңме?» – дип сорыйммыни?! Матур булмас бит... Квота буенча икенче ЭКОга чират килеп җиткән иде, баш тарттым.

Искәндәр берара: «Артык иркәләп баланы бозмабызмы?» – дип борчылды. Ярты ел элек кенә әнине югалттык: яратуның никадәр кирәклеген хәзер тагын да күбрәк аңлыйм... Күңелдә Мусаны тәрбияләү белән бәйле нindидер икеләнү туса, аның сүзләрен искә төшерәм: «Син әйбәт әни! Горурланам!» – дия иде. Аның аркасында гына инстаграмдагы блогымны алып барам. «Сиңа язарга кирәк», – дип гел әйтеп торды, миндә ышаныч уятты. Һәр язганымны укып барды – иң беренче аңа җибәрә идем. Ул бер тапкыр да «әйбәт» дип кенә җавап бирмәде, һәрвакыт яңа, ихлас сүзләр тапты. Аның мактавыннан гына бозылып китмәдем бит. «Әни мине яратты» дигән уй исә шундый рәхәт! Ни генә булса да, ярату белән яшәү, сынауларны кичерү җиңелрәк... Һәр операциядән соң янымда әни булды. Урындыкта утырып төн кичте, хәләл ризык ташыды. Ә Искәндәрне ничек якын итте, яратты ул! (Иремнең туган көне алдыннан булган сөйләшүебезне искә төшерәм.

Тормышымның максаты – гел нинди дә булса максат белән яшәү.

– Әйдә, аңа көймә бүләк итәбез!

– Әни, аның бит катер аласы килә...

– Катерны киләчәктә үзе алыр. Ә хәзер йөзмәскәмени аңа? Хыялланa бит!

– Әни, аның бер моторы гына да күпме тора!

– Әниеңнең нервыларын чыгарма. Бар, подносларыңны юн. Анлык кына эшләрбез!

Әни белән бергә күтәргән заводына шул көймәдә йөзеп бара әнә хәзер, катер алырга акча эшли.)

«Син бит Президентны, премьер-министрларны, шәехләрне, илчеләрне тәрҗемә иттең. Ә хәзер – ашарга пешерүче, хуҗабикә, әни... Менә нинди метаморфоза», – ди Искәндәр.

Инстаграмымдагы блогны укыганнан соң: «Сезгә карап, ЭКОга барырга тәвәккәлләдем, рәхмәт», – дип яза кызлар. Нинди генә хәлләр сөйләмиләр! Еларга яратмыйм, әмма ул хатларны укыгач, яшьләремне күп вакыт тыя алмыйм... Искәндәргә сөйлим дә: «Шул бер рәхмәт өчен булса да язарга кирәк сиңа!» – ди ул миңа.

Гөлнур САФИУЛЛИНА



PRESSA

«ЛӘЙЛӘНЕ ТЫҢЛАРГА КИРӘК»

КЫЗЛАР МАТУР БУЛЫРГА ТИЕШ. Минем кебек.

Ә малайлар әтиләре кебек булсыннар. **МЕНӘ БЕЗНЕҢ ӘТИ ЧЫН «КРАСАВЧИК».** Әнвәр белән Гомәр дә шундый бит: әтигә охшаган.

КЫЗЛАРНЫҢ БАШЫ ЭШЛӘМИ ИНДЕ АЛАРНЫҢ. Малайларныкы да.

ҖӘЙНЕ БИГРӘК ЯРАТАМ ИНДЕ. Җәй көне су коенырга, су белән уйнарга була. Матур күлмәкләр кияргә була.

Җәй көне кояш та бар, болытлар да бар. Кояшны бик яратмыйм, ул минем башымны кыздыра. Җәй көне яңгыр яуганны яратам. Юешләтә инде ул, тик барыбер **ЯҢГЫР ЯУГАНДА, УРАМДА ЮЕШЛӘНЕП ЙӨРМИСЕҢ БИТ ИНДЕ.**

Су анасының чәче минеке кебек озын. Тик мин чәчемне кистем, күзгә төшеп интектерә. **КАРАБОДАЙ АШАСАҢ, ҮСӘ УЛ.**

Әти белән әни мине бик ярата. **МИН БИТ БЕР ГЕНӘ КЫЗ!**

МИН, ҮСКӘЧ, ТАБИБ БУЛАМ. Кешеләрне дәвалаячакмын. Мин булмасам, аларны кем дәвалар?

МИН биергә яратмыйм, **ҖЫРЛАРГА ЯРАТАМ.**

Торт, **ҖИЛӘКЛЕ ТОРТ БИГРӘКЛӘР ДӘ ТӘМЛЕ ИНДЕ,** аны әни дә ярата.

МИҢА 4, 5, 6, 7, 8 ЯШЬ!

Туган көнемә чәчәк, торт кирәк. **Ә БҮЛӘК ИТЕП УЕНЧЫК АЛЫП КИЛСЕННӘР.**

УЕНЧЫК БӘЛЕШ – ИҢ ЯРАТКАНЫМ.

БӘЛЕШКӘ БӘРӘҢГЕ, ИТ, СУГАН САЛАЛАР. ТӘМЛЕ БУЛСЫН ӨЧЕН ШИКӘР ДӘ КУШАРГА КИРӘК!

Авылда көнбагыш ашап утырганда, безгә таба сыер йөгерә башлады. Сөзәргә дип килә иде бугай. Курыктым инде, елый яздым. Сөзмәде әле ярый, котылып калдым. Аның каравы, **БҮРЕДӘН, АЖДАҺАДАН, КОНДЫЗДАН КУРЫКМЫЙМ.**

ЭШЕМ КҮП МИНЕМ. Ашарга пешерәм, өй җыештырам, идән сөртәм, малайларны (Әнвәр белән Гомәр) карыйм. Авылда булганда, бозаулар карыйсы, аларны бәйлисе бар. Безнең бозаулар түгел инде алар, шулай да аларны карап торырга кирәк. Нишләп кенә бетәргә кирәк менә?
ӘНИ БУЛГАЧ, ТАГЫН ДА КҮБРӘК ЭШЛИСЕ БУЛА ӘЛЕ.

КУНАКЛАР КИЛЕП КИТКӘЧ, ЭШ КҮП КАЛА ИКӘН УЛ.

АШАГАНДА СОХАРИНЫ ЧӘЙГӘ МАНЫП АШАРГА КИРӘК. Югыйсә тешеңне сындырасың. Аннан соң бабай кебек буласыңмыни?

САЛКЫН СУДА МИКРОБЛАР ҮЛМИ, шуңа күрә кайнар суда юарга кирәк.

АГАЧЛАР ЗУР БУЛЫП ҮСӘЛӘР, ЧӨНКИ АЛАР КҮП АШЫЙЛАРДЫР.

АГАЧ БАШЫНА МЕНСӘҢ, ОЧЫП КИТМИСЕҢ, ЕГЫЛЫП ТӨШӘСЕҢ.
Зур агачлардан таудан шуган кебек, шуып уйныйсым килә.

Ә мин зурмы? **ЗУР ҮСКӘЧ, МИН МУНЧАНЫ ҮЗЕМ ЯГАЧАКМЫН.** Аннан соң: «Әти, әни, Әнвәр, Гомәр! Мунча әзер!» – дип чакырачакмын.

Әти, син молодец! Беседканы бик матур төзедең, тик **ТӨНЛӘ ДӘ ЭШЛӘСӘҢ ТИЗРӘК БУЛЫР ИДЕ.**

P. S. Бу санның «Тормыш кагыйдәләре»н туплаганда, героинябызны фотога рубрика кысаларындагыча махсус урындыкка утыртып төшермәдек, чөнки нәни кызчыкның әле үз дөньясында үз гаме белән яши торган чагы. Белмәгәннәр өчен: Ләйлә – җырчылар Ландыш Нигъмәтҗанова һәм Фәрит Таишев кызы.

Фикерләрне Ландыш ӘБҮДӘРОВА туплады.

Ләйлә ТАИШЕВАның тормыш кагыйдәләре





ТАТАРНЫҢ БАР ДУНАЕ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Кем өчендер ул иң беренче чиратта – Мирвәли («Өч аршын җир»), кемгәдер һаман да Газиз («Хуш, Назлыгөл»), Фигаро («Шау-шулы көн яки Фигароның өйләнүе»), Сәяр («Әни килде»)... Гөргери («Гөргери кияүләре»)! Шук, кешелекле, мөлаем бу керәшен агаен кайсыбыз хәтерләми! Хәер, ул уйнаган рольләрнең барысын санап чыгу мөмкинме икән?! Күп бит алар: Тукай («Тукай»), Бәхтияр («Бәхтияр Канкаев»), Шәмсетдин («Кол Гали»), Камали («Банкрот»), Нурислам («Хушыгыз»), Ногман («Мәхәббәт турында сөйләшик»), Алексей («Илгизәр + Вера»)... Әңгәмәдәшебез – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, республиканың Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге Дәүләт премияләре иясе Наил ДУНАЕВ. Иң беренче щепкинчыларның берсе. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты профессоры (дистәләгән талантлы шәкертләре өчен ул иң элек – остаз!). Тәрҗемәче (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында ул тәрҗемә иткән унлап пьеса куелганын беләидегезме?) Тагын... Хәер, юк, калганын үзе сөйләсен әле.



ТАМЫРЛАР Дунай фамилиясе Ак патша заманнарыннан ук килә, дип, әтинең сөйләгәне истә калган. Бу болай килеп чыккан. Тимри дигән крестьянның (безнекеләрне элек Тимринекеләр дип йөрткәннәр) улы Константин патша армиясенә китә. Бик озак хезмәт итә, хәбәрләре Дунайдан килә. Аның сабые Данила (минем бабай була инде): «Атаң кайда?» – дип сорагач, горурланып: «Дунайда», – дип җавап бирә торган була. Ул заманда авыл халкы өчен ят булып яңгыраган бу сүз нәселгә шулай берегеп калган.

Безнең Әхмәт авылында мәчет тә, чиркәү дә бар иде. Авылның яртысы – керәшен, яртысы – мөселман татарлар. Ярдәмләшеп, кунакка йөрешеп яшәделәр. Дөрес, элегрәк үзара өйләнешү юк иде, хәзер күп инде. Мин – атаклы умартачы Бал Ибан малае. Әти нәрсәгә тотынса, шуны булдыра ала торган оста куллы иде: итеген дә үзе басты, бүреген дә үзе текте, өебезне дә үзе салды... Ясаган умарталары да җыйнак, шкатулка кебек ялт итеп тора иде. Хрущев заманында крестьянга биш умартадан артык тотарга рөхсәт ителмәгәч, эчтән бүленгән озын умарталар ясады әти. Авыл җитәкчеләре: «Иван бер умартада берничә баш умарта тота икән», – дип, аны тикшерергә килделәр. Кайдан тишсәң, шуннан очып чыга инде алар дип, әти умарта түбәсенә төртеп күрсәтте. Берни аңламадылар... Бишебез дә әтигә булышып үстек: безнең өстә ике чүнник – колхозның 150 баш умартасы һәм икенче аланлыкта үзебезнең 30-40 баш умарта иде.

Коеп куйган чибәр булмаса да, туган-тумача әнигә «Матур түти» дип дәште. Аңа бар да тартылалар иде. Шуңадыр, безнең өйдән кеше китеп тормады, табыннан ризык өзелмәде. (Килен булып төшеп, беренче тапкыр кайтканда хатыным: «Сездә конвейер кебек икән», – дип, башта моңа гаҗәпләнгән иде, аннары күнекте.) Үзе зур гәүдәле булмаса да, киң сулышлы, моңлы, көр тавышлы иде әни. Юкка гына аны гел аш-суларга, мәҗлесләргә чакырмаганнардыр. Театр артистлары гастроль вакытында бездә кунакта булдылар, шунда әнинең һәм сеңелләренең өч тавышка җырлаганнарын әле дә сагынып сөйлиләр.

Җырак әби дә безнең авылда яшәде. (Бездә әнинең әнисен шулай «җырак әби» дип атыйлар.) Бик мәрхәмәтле җан иде, рәхмәт төшкере.



БАЛАЧАК Юклык заманда үскәнгәме, бүтән сәбәптәнме – мин Пыкрау бәйрәмен сагынып искә алам. Бу бәйрәмгә Пыкрау тәкәсе суела иде. Әни берьюлы дүрт төрле бөккән (бездә аны тәкә диләр) пешерә: чөгендер кушылган киндер орлыгыннан, тары белән кабактан, ит белән әчегедән, ә берсен иттән генә. Балачакның иң тәмле бәйрәме булып шул истә калган.



УКУ Башлангыч сыйныфны – туган авылым Әхмәттә, җидееллыкны – өч чакрымдагы Кадер авылында, унъеллыкны җиде чакрымдагы Түбән Биш авылында укыдым. Урта белем алырга авылдан бер мин генә бара алдым. Ни кызганыч, яшьтәш малайлар тормыш авырлыгы аркасында укуларын дәвам итә алмады. Аларның барысының да әтиләре сугыштан кайтмаган иде...

Безнең авылның мәктәбе мәчет бинасына урнашкан иде. Кызыл кирпечтән салынып, манарасындагы ярымаена кадәр кисеп төшерелмичә сакланып калган ике катлы бик мәһабәт мәчет иде ул. (Татарстанда манарасы гына түгел, ае да киселмәгән өч мәчетнең берсе!) Аны Мәннан хаҗи дигән бай салдырган булган. Ае әле дә исән.

Элек кышын кар-буран, салкыннар күп була иде бит. Андый көннәрдә без, Кадергә йөреп укучылар, басу капкасы төбендә җыелышабыз да сөйләшәбез: «Сүз бер булсын, буран, юл юк, барып булмады», – диярбез». Беркөн шулай өйгә кайтып кердем. Әти кереш җәя белән йон тетеп ята. «Нигә мәктәпкә бармадың?» – ди. «Юл юк, суык», – дим. Тунны салып элеп куйдым: туннан да, минем аркамнан да бөркелеп пар күтәрелә... Әти: «Бар, мич башына мен, бик туңгансың шул, – ди. Үзе әнигә күз кыса. – Җылынгач, йон тетәргә төшәрсең...»



МӘХӘББӘТ Без – тирә-як авыллардан җыелган егет-кызлар Түбән Биш авылы мәктәбендә урта белем алабыз. Минем алдымдагы партада Кабан-Бастырык авылы кызы Зина утыра. Көннәрдән бер көнне ул Алабугада китапханәчегә укучы ахирәтеннән хат алды. Хат эчендә кечкенә генә фото да бар икән. Бөтен класс мәш килеп шул фотоны карый. Фотокарточка, кулдан-кулга йөри торгач, миңа килеп җитте. Һәм... нәкъ шул минутта дәрес башланырга кыңгырау шалтырады – фото миндә калды. Карыйм – кыз чибәр! Тәнәфескә чыгуга, фотоны бүрәнә ярыгына кыстырып куйдым. Шулай итеп, ул «юкка чыкты». Зинадан ул кызның адресын алып, Алабугага хат та язып карадым әле соңрак. Бик көтсәм дә, җавап килмәде...

Менә инде мәктәпне дә тәмамладык. Имтиханнарны уңышлы тапшырып, Мәскәүгә, М. С. Щепкин исемендәге театр училищесына укырга китеп барам. Юлда очраштык: нәкъ минем кебек үк йөк машинасы кузовына утырып, Зина авылга кайтып килә икән. «Татый да Мәскәүгә китте, аны озатырга бардым», – дип кычкырып узды ул. Әчкә җылы керде: Мәскәүне зур шәһәр диләр дә анысы, тик кем белә?! Ярый, укулар башланды. Миңа бит инде теге сорау тынгылык бирми: Таня кая укырга керде икән? Китапханәчегәдер инде. Беркөнне Роберт Батулла белән җыендык та, китапханәчеләр әзерли торган институтка киттек. Эзләп таптык. Татьяна Батаева дигән кыз, әлбәттә, шушы институтка кергән! Аның кайда яшәгәнен ачыклау авыр булмады. Очраштык... Булачак хәләлемне беренче кат шунда күрдем. Дөресен әйтим, теге кечкенә фото алдамаган – кыз чынлап та чибәр иде. (Сүз уңаеннан: безне таныштырган ул «шедевр» әле дә исән – саклыйбыз.) Ә Таня мине инде ике тапкыр күргән булган икән. Беренчесендә – Борды авылы Сабан туенда. Аңа мине Зина күрсәткән булган. Икенче тапкыр – Зәйгә практика үтәргә килгәч, үзешчәннәрнең йомгаклау концертын караган, анда исә мин дә катнашкан идем. Соңыннан бу хакта ул үзе сөйләде.

Фото: Ксения Богданова

Таня укуны бездән бер ел алдан тәмамлап Казанга кайтты, Ленин исемендәге китапханәгә эшкә урнашты. Тормыш бер дә җиңел башланмады. Хезмәт хакы аз, яшь белгечләргә вәгъдә ителгән фатирлар бирелмәде. Гаиләлеләргә генә булыр, дигән сүз чыкты бервакыт. Без бит барыбер өйләнешәчәкбез, дип, Таня белән ЗАГСка гариза бирергә киттек. Пропискагыз юк, дип кире бордылар (фатир булмагач, кайдан булсын инде ул?!) Өстәвенә, минем паспортның срогы да чыккан икән... Театрда бер бүлмәдә – без, икенчесендә Туфан белән Нәҗибә яшәде. Паспортны рәтләп, пропискага кереп, икенче тапкыр ЗАГС ишеген ачканда, без инде менә-менә ишәергә җыена идек. Улыбыз мин гастрольдә чакта туды. Таня миңа: «Әти, дөньяга килүем белән котла, улың Владик», дип телеграмма суккан иде...

Хәләл җефетем дә минем кебек, үзе сайлаган һөнәргә тугры калды. Татарстан китап палатасында директор булып эшләде, диссертация яклады, доцент, профессор булды, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының деканы, проректоры дәрәҗәсенә күтәрелде.

Бүген театрда нәрсә уйналасын белсә дә, мин спектакльгә чыгып киткәндә хатыным гомер буе: «Бүген нәрсә була?» – дип кабатлый. Ул сүзне ишетү миңа рәхәт. Ә кайткач, һәрвакыттагыча: «Спектакль ничек үтте, тамашачы бар идеме?» – дип сорый. Миңа тагын рәхәт...



УҢЫШ Урта мәктәпне тәмамлагач, «кем булырга» дигән сорау алдында калырга туры килмәде. Май аенда мәктәпкә Мәскәү Югары театр училищесына укырга чакырган белдерү элделәр. Укытучылар да, сыйныфташлар да: «Син шунда барырга тиеш», – диделәр... Үземнең елга капитаны буласым килә иде, тик Горький шәһәренә ничек чыгып китәсең – русчаны белмим. Әти исә минем үзе кебек умартачы булуымны тели иде. Ул аны теле белән өзеп әйтмәсә дә, сөйләүләреннән аңлашыла иде. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, умартачыларга дәрес бирүче зур белгеч, үзенең остазы Иван Иванович Иванов кебек зур җитәкче итеп күрәсе килә иде. Ләкин театр училищесына баруыма әти дә, әни дә каршы килмәде.

Сәхнәгә шулай итеп очраклы рәвештә килдем. Кем белә, бәлки, очраклы да булмагандыр... Мин укыган Түбән Биш авылында үзешчән сәнгать бик көчле иде. Авылдашларга спектакльләр куябыз. Әдәбият укытучысы булып яңа гына диплом алган мишәр кызы Мәрвәрия апа Җиһаншина кайтты. Казанда театрга йөрүләрен сөйли, ә «Бишбүләк» спектакле турында сөйләп кенә калмый, уйнап күрсәтә, җырлый! Театрга мәхәббәт шул вакытта уянгандыр.

Ә театр бик сихерле җир бит ул: бер эләктердеме, мәңге дә ычкындырмый.

Әхмәт Фәйзинең «Тукай» спектакле безнең – щепкинчыларның диплом эше иде. Без аны Казанга кайтып, Г. Тукайның 75 еллыгы көннәрендә Г. Камал театры сәхнәсендә, театр артистлары белән кушылып уйнадык. Программада: «Тукай ролендә – Николай Дунаев» дип язылган иде. Кайбер тамашачыларга бу бик сәер тоелган. «Ничек инде, Тукайны рус кешесе башкарамыни?» – дигәннәр. Режиссерлар: «Исемеңне үзгәртеп языйкмы әллә?» – дигәч, каршы килмәдем. «Фамилиямә генә тимәгез», – дидем. Шулай итеп, «Наил Дунаев» булып киттем...

Кайберәүләр артистның һөнәре бик җиңел дип уйлыйлар. Көн дә уен, имеш. Шул уен артында күпме хезмәт ятуын башларына да китермиләр. Сәхнәгә юл җиңел түгел, аңа юллар урау. Баштагы биш елда үз йөземне табарга тырышып, шактый авыр эзләнү чоры кичердем. Сәхнәдә чын-чынлап яши башлавым, тамашачы җылысыннан, сулышыннан аерып торган «пәрдә»дән арынуым театрга баш режиссер булып Марсель Сәлимҗанов килгәч башланды.

Шушы еллар эчендә төрле пландагы, характердагы йөзләгән образ иҗат ителгән. Рольләрнең зурларын да, кечкенәләрен дә уйнадым. Күбрәк классик рольләрдә уйнарга туры килде. Бер яктан, бу яхшы, ләкин, икенче яктан, тамашачы бит кәмит уйнаучыларны ярата, аларны күбрәк белә, күбрәк хәтерли. Уйнаган барлык рольләрем дә күңелгә якын булды дип әйтә алмыйм, ләкин мин алар булып яшәргә тырыштым, уйладым, сөйләдем... Сәхнәдә үзеңнең кем икәнлегеңне бөтенләй онытырга, өр-яңа тормышка, мохиткә күчәргә кирәк. Шунда гына ул уен түгел, ә яшәү була! Ролең – күлмәк түгел, спектакль беткәч, аны салып, элгечкә элеп куя һәм оныта алмыйсың. Ул инде синең тормышың. Драматик артистларны мин тормыш ыгы-зыгысыннан өстенрәк торалар дип саныйм. Югыйсә бүген – Фигароны, иртәгә «Кол Гали»дә – Шәмсетдинне, ә берсекөнгә «Кыю кызлар» комедиясендә чатан Вәлине уйнап булыр идеме?! Әмма рольләрнең шушындый төрлелеге – актер өчен бәхет ләбаса!



ДУСЛАР Без, щепкинчылар, кирәк чакта һәрвакыт бер-беребезгә ярдәм итеп яшибез. Районадашым, мәктәптәшем, Мәскәүдәге сабакташым Рабит Батулланы, мәсәлән, дустым дип әйтә алам. Торган аралар да якын, күңелләр дә якын аның белән... Ринат Таҗетдинов кеше серен саклый белә. Туфан, кызганыч, мәрхүм булды инде – аның белән дә дуслар идек.



АКЧА Безне бит бай булу бик үк әйбәт түгел дип тәрбияләделәр. Гел шуны тукып килделәр! Әйләндек тә капитализмны сүктек, һаман аларны хурладык... Хәзер менә бөтен дөнья акча эшләргә омтыла. Күп акча! Гаҗәпләнмибез дә... Ә безнең буында андый теләк булмады шул. Бүген: «Акчаң бармы?» – дип сорасалар, мин: «Әйе, бар», – дип җавап бирәм. Элеккеге белән чагыштырам да, әлбәттә, «юк» дия алмыйм. Миңа бит хәзер күп кирәкми инде... Сез әйткәнчә, каяндыр күп акча ишелеп төшсә? Бизнес ачарга җыенмыйм. Булмас та иде ул миннән. Хәер, мин генә түгел, безнекеләрнең күбесе тотынмас иде бу эшкә. Бәлки, иркенрәк фатир алыр идем. Машина... Юк, аңа да кызыкмадым. Рәхмәт инде, 80 еллык юбилеема Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Ford Focus дигән машина бүләк итте. Татар артисты өчен зур

дәрәҗә! Равилгә дә, Ринатка да бүләк итте ул машина. Тик беребез дә рульгә утырмады. Мондый хыял булса, кеше кебек бер машинага гына без дә җыйган булыр идек акчаны.

Авыл кешесе өчен мин бит инде күпкә ирешкән булып саналдым: Мәскәүгә киттем, укыдым, Казанда урнаштым... Авылга кайтканда, олы юлда төшеп калам да, бакча артыннан җәяү генә өйгә керәм. Авылдашлар белән кич утырганда берсе кактырып-суктырып кына сорап куя синнән: «Нәрсә, машина белән кайттыңмы?» Үзе белеп тора югыйсә! Нәкъ Шукшинның «Срезал» хикәясендәге Глеб Капустинның кунакка кайткан авылдашын – фән кандидатын чеметеп-чеметеп алуы кебек... Йөрисең, йөрисең, машина да ала алмадың диюе. Байлыкка кызыкмадык шул...



МАВЫГУ Балык тотарга хирыс булган кеше утыра сезнең алда. Бигрәк тә балыкка кышын йөрергә яратам. Бу чир белән мине Хәкимыч (мәрхүм режиссерыбыз Марсель Сәлимҗановны шулай дип йөртә идек) агулады. Чынлап та, чир бу, аңардан берничек котылып булмый. Бөтен буш вакытны ала! Ул болай башланды: Ленинградка күчеп киткән ТЮЗ артисты Каменицкийның кышкы чалбарларын кидертте дә, аның балыкка йөри торган тартмасын сөйрәтеп, Хәкимыч мине Мишә елгасына алып китте. Калын бозны тишеп, шул тишеккә кармак төшереп, балык тотуларын күреп шаккаттым. Ул тишектән балык тотып булуына ышанмаган да идем башта. Елның теләсә кайсы вакытында балыкка йөрү – иң яраткан шөгылем хәзер. Мин тиз бирелүчән кешедер инде... «Без бер-ике балык эләктергәндә, син ун кило тотасың, әллә балыкларның телен беләсең», диләр. Үзем балыкны ашарга да яратмыйм, күбрәк өләшәм генә.

Бакча белән мавыгу да бар. Мичурин булмасак та, бер алмагачта берничә төрле сорт алма үстерәбез. Мине белгәннәргә футбол җанатары булуым да сер түгел.



БАЛАЛАР Хатын белән бер ул үстердек. Улыбызның күптән инде үз гаиләсе бар. Шөкер, тату яшиләр, һәрвакыт безгә дә ярдәм итәргә торалар. Үсеп, өлгереп килгән мәлендә бер-беребезне аңламаган бер чор булып алды. Аннан узды. Хәзер безнең аралар бик якын.

Владислав университетның ВМК факультетын тәмамлады. Диплом алуы туксанынчы еллар башына туры килде. Ул эшкә урнашкан завод, озакламый таралып, юкка чыкты. Инде нишләргә, дип торганда, бер танышы: «Эчке эшләр министрлыгында компьютерлар урнаштырырга җыеналар», – дип, шунда барып карарга тәкъдим итте. Ике куллап алдылар. Берзаман карыйм – полковник булган бу. «Кайчан бирделәр?» – дим. «Былтыр», – ди. Әйтеп тә тормаган... Киленебез Люция – мөселман кызы. Алар бергә укыдылар, хәзер дә бергә эшлиләр. Берсендә Люция безгә бакчага килгән, бик кәефсез. «Миңа майор дәрәҗәсе бирделәр», – ди. «Соң, сөенергә кирәк бит!» – дим. «Аны әбиләргә генә бирәләр», – ди... Хәзер подполковник булды инде әнә. Ике кыз үстерделәр. Алинәбез ире Искәндәр белән Чаллыда яши. Кызлары бар. Барысы да шуның тирәсендә бөтерелә. «Иркәләп бозып бетермәсәгез ярый», – дип, әбиләре бик борчыла. Диана юрфакны тәмамлады, анысы да кияүгә чыкты инде.

Оныкларым өчен мин дәү әти түгел, ә бабай. «Дәү әни», «дәү әти» сүзен беркайчан яратмадым. Әти белән әнинең кечкенәсе булмый... Дәү әни ул – шәһәрнең картаясы килмәгән хатыннары уйлап тапкан сүз. Үзем турында тагын «кырыс бабай» дип әйтә алам. Оныкларымны, балаларымны кыланмыйча, төчеләнмичә яратам.



КУРКУ Актерларның: «Сәхнәгә чыгудан курыкмыйм», дигән сүзләренә мин ышанмыйм. «Ролем барып чыгармы, юкмы?» дигән сорау минем үземне менә гомер буе куркытты. Актер һәр спектакльне чиста биттән башлый ул. Һәр яңа уйнаган роле белән имтихан бирә. Аны гел «са» дигән шарт фигыль озата: драматург әсәр язса, ул театрда куелса, роль сиңа бирелсә, ул эшең барып чыкса, халык яратса... Нигә менә кайбер артистларны «салкын», диләр? Халык алдына чыкканда дулкынланмаса, эчтән калтырамаса, салкын була инде ул. Роле техник яктан эшләнсә дә, җылылыгы залга барып җитми – тамашачы исә моны шунда ук сизә.

Ә бүген мине ниләр куркыта? Күптән пенсия яшенә җиттем – каланчамнан башка төрле чаңнар кагалар хәзер... Кайчан да булса теге дөньяга китәсе бар бит: карт кеше ялгыз калудан шүрли башлый икән. Ялгыз калгач, ничек булыр икән дип уйландыра. Дөрес, кем алданрак китәр – анысын белгән юк, билгеле. Безнең әти белән әни – гап-гади авыл кешеләре – пар аккошлар кебек яшәделәр. Берсеннән-берсе тора да алмас кебек иделәр. Әни үлде дә, әти ялгыз калды. Ул өйдә берни эшли белми иде: юа да белми, пешерә дә... Савыт-сабаны өеп кенә куя иде. Ул чакта авылга кайтыр өчен Бигеш аэропортына оча идек. Билет бәясе 8 тәңкә тора. Кассир кызлар мине танып бетерделәр: чиратта басып тормыйм – атна саен билет калдыралар. Авылга кайтып, әтинең өен җыеп, савыт-сабасын юып киләм. Кыш көне Түбән Камада яшәүче сеңлем аны үзенә алып китә. Яратмый иде әти шәһәргә барырга. «Ул тагаракта ничек юынасың?!» – дия иде. Әнидән калуны ул бик авыр кичерде. Берсендә шкафтан әнинең күлмәкләрен алып куймакчы булам. Әти: «Тимә!» – дип шундый итеп кычкырды... Әле дә тавышы колагымда яңгырый...



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Сентиментальлек күп инде миндә... Кайбер артистлар елаган булып күренер өчен күзләренә вазелин сөртәләр. Ә мин, спектакльдә җанга тия торган урыннар булса, үземне тыя алмыйм... «Бичура» спектакле вакытында драматург Мансур Гыйләҗев белән режиссерыбыз Фәрит Бикчәнтәев: «Бүген дә яше шулай агармы икән?» – дип, мине күреп карап тора торган булганнар. Соңыннан әйттеләр. Дөрес, артык нечкә күңелле булу тормышта кайчак миңа комачаулый да. Әмма сәхнә өчен аның булуы барыбер әйбәтрәк... Гаделсезлекне авыр кичерәм. Андый чакта дәшми кала алмыйм.



Китәсе килми синнән!

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Алтмышынчы елларда шигъриятькә бөтенләй яңача – көтелмәгән нюанслары, киләчәкне алдан күрә белгән тирән фәлсәфәсе, күңел кылларына күбәләк канаты кебек кагылып узган лирикасы белән килеп керде ул. Яшьлек, кайнарлык, кыю фикерләр. Гадәти булмаган сүз-гыйбарәләр, метафора-образларның аҗагандай ялтырап китүе... Ул шигырьләр – җете төсләре белән балкыган картина, гаҗәеп фотосурәт йә әллә нинди сихри музыка, давыллы симфония сыман. Аңарда гына – «күңеле тулган» болытлар, һавадагы торналар чылбыры, толымланып салынып төшкән күк сагышы, ботакларда – көянтә-кар, сөлге – төсле җил булып җилферди... Студентлар карт профессор лекциясендә кача-поса Фәйзуллин шигырьләрен укый. Илһамландыра. Сокландыра. Шаккаттыра. Исеме Евтушенко, Вознесенский, Рождественскийлар белән янәшә...
Инде ярты гасыр узган, ә ул һаман югарыда, биектә. Ул – заман шагыйре. Яраталар, тансыклап, эзләп табып укыйлар.
Шагыйрь, мөхәррир, депутат, делегат, лауреат, җәмәгать эшлеклесе... Иделләрне аркылыга-буйга йөзүче, Кавказ, Альп, Карпатларга күтәрелүче, илләр-кыйтгалар гизүче... Көрәшче, Җиңүче... Шәхес! Гомер калейдоскобында ул әнә шулай балкый.
Гомер калейдоскобы дигәннән... Тиздән ул укучыларын, киң җәмәгатьчелекне «Гомер калейдоскобы» китап-альбомы белән сөендерер. Фотолар, шигырьләр, җырлар, хатлар, истәлек-хатирәләр, вакыйгалар, кадерле кешеләр... Без ул «калейдоскоп»ны башкалардан бераз алданрак (корректурада гына булса да) күреп алкышладык инде! 11 яшьлек Фәйзуллин Равилнең кульязма китабы, университет еллары... Әтисе Габдрахман абыйның Әмәт тавындагы алкалы каен төбенә урнашкан өе берзаман шагыйрьләрне үзенә сыендырачак, әнисе Әминә апа коймаклары белән чәй эчә-эчә, шагыйрь егетләр бәхәсләшәчәк... Ленинград, Мәскәүләрне яулау, армия хезмәте, сенсациягә тиң «Нюанслар иле»... 23 яшендә беренче китабы дөнья күрә... 23 яшендә СССР Язучылар берлегенә кабул ителә... 25 яшендә Әлмәт Язучылар бүлеген җитәкли... Дан-дәрәҗәләр. Иҗат. Уңышлар. Мәхәббәт. Гаилә. Фотоларда – өлкән улы Алмаз, оныклар... Кече улы Газизгә дә инде 17...
Бүген матур юбилее көннәрендә Равил абый Фәйзуллинның шигырь томнарын актарып, дөньябызны онытып утырабыз, рәхәт бер халәттә җанга якын шигырьләрен кайта-кайта укыйбыз. Шагыйрьгә котлауларыбызны, чиксез рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Эльмира ЗАКИРОВА

* * *

Беренче саф хисне
булмас та яңартып,
шулай да мендәрне
иплә әле кабартып!

Әйдә, кемдер йөрсен
гайбәтләр таратып...
саулыкта сөелү –
байлыктан мең артык!

Тырышсаң буладыр
караны агартып.
Кояшны, Сөюне
булмый ул каралтып!

Җәй белән саубуллашу

Таңда күргән татлы төштәй
үтә бәхетле көннәр!
Искечә сентябрь керде –
сәгатьләп сула гөлләр...

Кемнәрнең сагышын сөйли
торналарның чылбыры?
Кайда безнең сихри төннең
чикерткәләре җыры?

«Кояш булса да, җил!» – диеп,
Изүне төймәләдең.
Ярда йөзтүбән елый күк
балыкчы көймәләре...

Әллә җилдән, әллә гөлдән
тибрәнә пәрәвезләр.
Кашкарыйларга карыйлар
синең боеккан күзләр.

. . . .
Аерыласы килми җәйдән!
Китәсе килми синнән!
...Килер җәйләр бәхетен теләп,
дога укыйм эчемнән.

Әгәр миңа ышанмасаң...

Әгәр миңа ышанмасаң,
«Ул яратамы мине?» дип,
җилләрдән сорап кара!
Алар да, минем шикелле,
«Шуны да белмисеңмени?» дип,
чәчеңнән тарап торыр.

Әгәр миңа ышанмасаң,
«Ул миңа тугрымы?» дип,
күкләрдән сорап кара!
Болытлар, минем шикелле,
«Шуңа шикләнәсеңме?» дип,
мөлдерәп карап торыр.

Әгәр миңа ышанмасаң,
шул ук сорауларны биреп,
үзеңнән сорап кара!
Үзең мин булып кара!

...Күңелең тулы яшь булып та,
күлеп, елмаеп кара!

Иясез шатлык

Уйный-оча күбәләкләр –
җанлы чәчәкләрмени!
Урманнарга, болыннарга
Шатлык чәчкәннәрмени!

Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Җирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып!..

Һәр көнне җиңү итәргә
кеше көч каян алсын?
Әй, килә гомер кичәрлек
кемгәдер таянасы!

Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Җирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып!..

Күбәләк кунган чәчәкләр
матур да, горурлар да.
Кемгәдер кирәк булуың, –
бәхет бит ул дөньяда!

Мин дә куна алыр идем
кемгәдер аклык булып!
Җирдә күпме җаннар йөри
иясез шатлык булып...

* * *

Бар нәрсәдә синең төсмер:
син – үләндә, яңгырда.
Сине күрәм дулкыннарда,
тургайлар тулы кырда.
Син – кәгазьдә, төнбоекта,
керфектән тамган тирдә...
Болытта да чагылышың! –
Йа Хода, бөтен җирдә –
син,
син,
син...
Күңелемдә шигырь тажы.
Ачып баксам – анда да син!
Кайда да син, кайда да син!
...Тик
үзең генә юк янда.

Этюд идиллия

Кешеләр менгән Айга.
Ә без менә җайга
бу борынгы җирдә,
тамырланган илдә,
үзебез корган өйдә
тәрәз юабыз.
Шундый бездә йола:
язлар житү белән,
халык өйләр юа.
Йөзләрдә – көләчлек,
табигатьтә – яшьлек!
Әле Кояш яңа,
әле ләйсән ява!
Кызлар су ташыйлар
йөгерә-чаба.
Кыска итәкләргә
шук тамчылар тама...
Кем чыгарган йола?
Язлар житте исә,
халык өйләр юа.
Юа бар җирен дә, –
Калдырмый җеген дә!

Кешеләр Айга менгән.
Ә без җирдә менә
тәрәз юабыз
синең белән бергә.
Тыштан мин су сибәм,
эчтән син юасың.
Мин көлемсерим дә,
ә син елмаясың.
Гөрләвекләрмени
өлгеләр, рамнарда!
Күрәмсең, чистара!
Чистара! Тагын да
сафлана шикелле
икебезнең ара...

Житсен киче генә,
йолдызлар балкышып
тезелгәч күгенә,
нәни улыбызны
уртабызга алып,
карарбыз тәрәздән,
бу айга таң калып.

Бәлки, син...

Бәлки, син – минем җырланмас
иң гүзәл җырымдыр?
Бәлки, син – минем чыгалмас
иң данлы юлымдыр?

Бәлки, син – минем меналмас
иң биек күгемдер?
Бәлки, син – күтәралмас
гомерлек йөгемдер?

Бәлки, син – минем беркайчан
кул житмәс кошымдыр?
Бәлки, син – үзем аңламас
бәхетем алкышыдыр?

...Ул – син!

Утларда янам, утларда!..
Яндыручысы ул – син!
Янып бетмәс өчен, Ходай
җанга сабырлык бирсен!

Рәхәттән шашам, рәхәттән!..
Шаштыручысы ул – Син!
Очып китмәс өчен, Ходай
әзрәк авырлык бирсен!

Август

Җәй – җәядәй!
Киерелгән соңгы чиккә!
Җирдән – Күккә,
яшеллектән – зәңгәрлеккә...

Зеңли үләннәр.
Дым кимегән саен – авазлар нечкә...
Иртәнге томан сарыла керфекләргә.
Чәчәкләр тулышкан.
Тажларының һәрберсендә
ким дигәндә берәр кояш!
Чалгы кискән җиләкләрдә
шәфәкъләр каны.
Балыклар, сикереп, Иделдә салават
күпере ясыйлар.
Игеннәр өстендә рәшәләрнең
саубуллашу биюләре.
Эсселектән кайный ми.
Чикерткәләр кызышканнар:
дерелдәшеп бу сайраудан
аварлар күк.
...Канат ныгыткан яшь сыерчыклар
очышлар ясый кыйбла ягына.

PRESSA

«Сөембикә» журналында Альбина Гайнуллинаның дебюты. Үзе белән үзе таныштыра, өр-яңа хикәясен тәкъдим итә.
«Мин 1982 елның буранлы кыш айларыннан. Шуңадырмы, ябалаклап яуган ап-ак карларны, җәяүле бураннарны бик яратам. Нур бөркелеп торган якты кешеләргә тартылам. Үзем авыл баласы: Әгерҗе районы Шаршады кызы.
2011 елны гаиләбез белән Казан шәһәренә килеп төпләндек. Авыл мәктәпләренең ябылуы китәргә мәҗбүр итте. Тормышыбызны төптән үзгәртеп, яңадан башлау бик кыю, тәвәккәл адым булды. Бик авыр кичердем бу галәмәтне. Бүгенге көндә урта белем бирү системасында булган тынгысызлык, туган телебезнең ятимлеге, үксезлеге җанымны борчып, күңелемне әрнетеп тора.
Икътисадчы белеме алсам да, күп еллар шул өлкәдә эшләргә туры килсә дә, үзем бүре баласыдай шигърият урманына каерылып торам. Матурлыкка мөкиббән булудандыр ул. Бала чагымнан рәсем ясау, фото, шигырь язу белән мавыга идем. Соңгы вакытта хикәяләр язам».


Альбина ГАЙНУЛЛИНА

ИСЕМСЕЗ

(Хикәя)

Исемсез бер күзен генә кысып ачкан килеш дөньяны күзәтә. Гаять зур бит ул дөнья, бигрәк тә менә шулай, керфекләр арасыннан, ярым ачык күз белән караганда. Син менә шушы кысык күз ярыгына сыеп бетәсең, син бүтән юк, ә ул шундый зур, шундый киң. Бер ярыкка да, бер акылга да сыя торган түгел. Бигрәк тә эт акылына. Ул гаять көчле, кодрәтле! Мәрхәмәтенә ирешсәң, алдыңа сөяк ташлар. Нәфесеңне тыя алмасаң, тозакка эләгерсең. Тозак бәласе – гомер бәһасе! Бары бер гомер. Арзанмы, кыйммәтме, һәркем үзенчә бәяли, һәркемнең үз үлчәме. Күпләрнең бит исемнәре бар, хәтта токымнары да. Аларның гомерләре кыйммәтрәктер, мөгаен. Үз токымын белмәгән кадерсез урам этенең гомере кыйммәтме икән? Үз токымыннан баш тарткан йортсыз адәмнең, гаиләсез ялгыз башның гомере ни бәя икән?!

Буылып йөткергән тавышка колакларын торгызып торып утырды эт. Кеше канлы төкерекләрен какырып төкерде, тагын ютәлләп алды. Башлыгы астыннан тузгып таралган чәчләре, укмашып, гел Исемсезнең йоннарына охшап калган. Кеше керләнеп беткән йон свитеры өстеннән элгән юеш сырмасын салып, чык тамчыларын кагып төшерде дә кабат өстенә киде.

Эт белән кеше куыш тапкан аланга таң яктысы белән машина тавышы таралды. ГАЗель фараларының яктысы, күзләрне камаштырып, алан киңлегендә биеште. Шул яктылыкка машинадан урта яшьләрдәге ерык авызлы бер ир сикереп төште.

– Монда гына булырмын дигәнең кырык чакрымга сузылды, ахирәт. Исәнме? – дип, якын туганнардай күрешергә кулын сузып килеп тә җитте теге адәм.

Таныды ул машина хуҗасын. Җәй башында кыргый этләр авызыннан йолып алган төнге урам тоткыны. Мескеннең тере җире калмаган иде, тереләй эт ризыгына әйләнә язган. Ул мәхшәрне күрү белән теге этләр өстенә беренче булып Исемсез ташланды, сыртларыннан гына селкеп ташламакчы иде. Ләкин ул хәшәрәтләр күп һәм җүнсезләр, көчле, тук та...

Кан исенә тагын да котырынып, мескен ирне талаган этләр Исемсезне дә аямады. Бер яманы бугазына ук ябышты. Шунда, зур күсәк тотып, ярдәмгә Кеше дә килеп җитеште. Үзенең этен аралапмы, бәлагә тарыган бәндәне коткармакчы булыпмы, бар көченә кизәнеп, этләр төркемен кыйнарга кереште. Ниһаять, котырган җанварлар, шыңшып, кайсы кая таралды. Ләкин коткарылган бәндәнең җирдән күтәрелерлек рәте калмаган иде инде. Тәнендә ярасыз җир юктыр кебек, кай төшенә кагылсаң да, шарлап кан ага. Урамда үлеп ятмасын дип, Кеше яралыны хастаханәгә кадәр үз иңендә сөйрәп барды. Ул үзе дә урамда үлеп, җир өстендә исраф булып ятудан гаять курка иде. Тиешенчә җеназа кылып, ясин чыгып озатучы булмаган тәкъдирдә дә, җир өстендә аунап ятмаска иде дип борчылды ул.

Хастаханә каравылчысы, тиз арада дежур табибларны табып, эт авызыннан алып калган ирне хирургия бүлегенә озаттырды. «Коткаручыларны» да каравылчы тиз генә җибәрергә ашыкмады. Яралы кешене Исемсез талаган дип уйлады ул.

– Алладыр дип әйтәм, ул миннән алдан кешегә ярдәмгә ташланды. Үзенең дә исән җирен калдырмадылар бит... – дип, этнең кан саркып торган яраларын күрсәтә башлады Кеше.

– Мондый токымлы этне каян алдың соң син, агай, бу бит чын овчарка. – Эткә карап, эре генә, «Сидеть» диеп боерган булды каравылчы. Маэмай шунда ук буйсынды.

– Бу бит өйрәтелгән чын овчарка! Каян алдың син моны? – дип, сабыйлар кебек ихлас гаҗәпләнеп, соравын кабатлады каравылчы.

– Алмадым, үзе тагылды. Токымлы дип тормаганнар, кирәге калмагач, урамга атканнар. Урам эте ул да, мин дә. Башка сүзең булмаса, начальник, китик әле без моннан... – Кеше шлагбаумга таба атлады.

– Тукта, ашыкма әле. Начальник түгел мин сиңа, Марс абзаң булам! Синең атың ничек?

– Кеше – минем исемем. Калганы мөһим түгел.

– Ярый. Аңлашылды. Ә этеңнеке?

Каравылчының көр-тук тавышы, таза гәүдәсенә килешеп, гөрелдәп тора.

– Ул да исемсез... – Нидер эзләгән төсле, як-ягына карана Кеше. Сабагын оныткан укучы кебек, тотлыгыбрак сөйли. – Исемсез аның кушаматы.

– Кара әле, энем, син бит бомжга бер дә охшамагансың. Күптәнме урамда?

– Түгел. Өч-дүрт ел гына...

Авыр уйлар хастаханә тирәсен караңгылыгы белән чорнаган төн эченә түгелде. Эх, шул уйларга берәр төрле укол салып, дәваларга иде үзләрен. Менә һәркайсын тотасы да, авырттырып, олы гына бер энә белән кадыйсы бит! Күзләреңнән кайнар яшьләрең коелып төшәрлек итеп, шул зәһәр уйларның барысына да укол салып чыгасы. Файдасы тимәс идеме?..

– Син теге чакта нигә киттең? – дип, чакырылмаган кунак төпченә башлады. Үзенең авызы шыксыз ерык, ертылып киткән диярсең. Йөзендә, этләр талаган төннән мыскыллы сәлам булып, тегелгән җөй эзләре җыерылып ята.

– Җавап алырга килдеңме? Ничек эзләп таптың?

– Юк инде, рәхмәт әйтергә дип килүем иде. Мин сине җәй буе эзләдем. Марс абыйга монда гына булырмын, шушы тирәдә йөрим мин дип киткән булгансың. Безнең «бу тирә» – фатирдан тукталышка кадәр... Бу шул минем коткаручыммы инде? – Кунак елмаеп euкә ымлады.

– Әйе, үзе! – дигән булды Кеше.

– Рәхмәт сезгә, дуслар. Ярдәмгә килмәсәгез, талап үтерәләр иде. Сез килгәндә аңымда идем әле. Этеңнең тегеләр өстенә ыргылганын да күрдем. Башта курыктым, шушы хәерсезләргә кушылып мине таларга килә дип уйладым. Теге этләр белән сугыша башлагач кына эшнең нәрсәдә икәнен аңладым.

Исемсезнең колак артларын кашып алды кунак.

– Яраларың төзәлдеме әле, друг?!

Эт колакларын торгызып, койрыкларын болгап куйды. Аның дәртләнеп китүен ирләр үзләренчә аңлады. Кунак буш кул белән килмәгән. Машинасыннан ипи, тәмәке алып килде. Термоста кайнар чәе дә бар. Танышларыннан шушы тирәдә зур эт белән бер бомж йөри дигәнне ишеткәч, эзләп килүе икән.

– Кара әле, кем диим соң үзеңне... Көннәр суытып килә, ни эшләргә исәп соң? Болай урамда кыш чыга алмассыз бит.

– Синең анда ни эшең бар?

– Эшем юк та, сезнең алда бурычым бар. Эчмәсәң, кышка урнаштыра алам үзеңне. Малайлар бер абзыйга шәһәр читендәге бакчасына каравылчы кирәк дигән иде. Этең белән үзеңне эшле-куышлы итә алсам, азрак бәхилләгән төсле булырмын.

– Минем документлар юк бит.

– Аларга документ кирәк түгел. Ризамы?

– Эш белән торыр җир ярап торыр иде шул. Ләкин овчарканы калдырмыйм.

– Юк! Аны калдырмыйбыз! Әйеме, друг?!

Исемсез дәртләнеп өреп куйды.

– Кара әле, туган. Атың кем, абый дип дәшимме, энем буласыңмы?

– Юныс дип кушканнар иде бугай. Яшькә килгәндә, бер тирәдер без.

– Димәк, Юныс туган! Риза. Мин Риза булам, – дип куанып көлеп җибәрде кунак. – Аллага шөкер, таныштык та! Утыр машинага. Миңа кайтабыз хәзер, ашапэчеп, мунчалар кереп чыгабыз да теге абзыйга барып кайтырбыз.

...Бомж турында сүз чыккач, бакча хуҗасы берара шикләнеп торган иде дә, Юнысны нәселле овчарка белән күргәч, көлеп җибәрде.

– Бомж, дип котны алдыгыз, егетләр. Нинди бомж булсын... Торыр җире булмаган бөтен кеше бомж булса, безнең ил, гомумән, зур бомжатник инде!

Түләү мәсьәләсендә дә бакча хуҗасы отты. Юныска артык акча кирәк түгел, бары кышлау урын белән аз-маз тамак ялгарлыкка бернинди шартсыз риза булды ул. Аның бөтен курыкканы урамда җан-тәслим кылып, тәне туфракка иңдерелми калуы иде. Ипләп кенә үтенечен Ризага да җиткерде.

– Кит әле! Карчыклар сүзе сөйләп утырасың монда.

– Мин әйттем, син ишеттең. Әллә ирләр бу җиргә мәңге килә дип беләсеңме?! Безнең дә карчыклардан артык җиребез юк. Алар яшенә дә җитүең икеле.

– Яшь турында... Анысы белән килешәм. Ишеттем, үтенечеңне аяк астына ташламам. Ләкин иртәрәк әле бу хакта уйларга, иртәрәк. Сүз бирәм, туган, динебез шартларын үтәп, соңгы юлга шәригать кушканча озатырбыз сине. Ләкин син дә башка бу хакта уйламаска, сөйләшмәскә сүз бир.

– Килештек. Үлемнән куркасыңмы әллә? – Юнысның мыскыллы усал елмаюы да үлем хакындагы уйлар кебек куркыныч, шыксыз шул.

PRESSA

– Курку да түгелдер инде ул. Яшисе килә бит, туган. Кара әле, синең карчыгың исәнме? Балаларың бармы синең, Юныс? – дип, Риза сүзне башка юнәлешкә бормакчы булды. Ләкин әңгәмә килеп чыкмады.

– Бу хакта куеп тор. Исән түгелләр, – булды җавап.

Күпме чакрымнар, еллар кичсәң дә, авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрсәң дә, үзеңнән кача алмыйсың икән. Хатирәләр, кылган хаталар, үкенечләр төялгән авыр йөгеңне бер юл чатында да ташлап калдырып булмый. Баш чүмечен ачып, аның хәтер казанын тимер кашык белән кырып-кырып чистартсаң да, каядыр тирәндә, күкрәк, йөрәк түрендә каладыр кебек ул тамчы-тамчы хәтер. Үч иткәндәй, аның балан кебек ачылары калып, күмер төсле кайнарлары бәгыреңне көйдерә. Шул хәтер тамчыларыннан дәва булсын иде. Шулардан котылырлык берәр чара!

...Розалиядән дә чибәр кыз булмагандыр авылда. Биленә тиң кара калын толымнары, бөдрәләнеп, кемнәрнең генә хыялына үрелмәде икән. Ул аларны олы апалар кебек әле баш өстенә өеп, матурлап куяр, әле икегә бүлеп төсле тасмалар белән үрер, йә гел һуштан яздырып таратып җибәрер. Ирләр күзен иркәләгән төз сыны, авыз суларын корытып йөргән авыл малайларының төшенә кереп саташтыргандыр.

Менә шул асыл кош Юныска гашыйк булуын игълан итмәсенме. Ике ел йөргән егетен бер көн салмыш килгән өчен ташлап, кеше күзенә бер дә аек күренмәгән сугыш чукмары, холыксыз Юныска алыштырды да куйды авылның йөзек кашы. Әниләре, туганнары үгетләгән саен, Юнысның дуамаллыгы, тупаслыгы хакында сөйләгән саен, Розалия үз сүзендә ныграк торды. Никах укытып, кияүгә чыгарга ашыкты. «Сәбәбе бардыр әле. Чаялыгы белән уеннан уймак чыгаргандыр бу бала, гөнаһысын яшерерлек мөмкинлеге дә бар, егете дә алам дип торганда, кавышсыннар», – дип биреште ата-ана. Бирнәләр хәстәрләп, никахлар укытып, авыл читендәге яңа йортка башка чыгарып куйдылар үзләрен.

Юныс та авыл егетләренең борынына чиерткәненә канәгать булды. Шулай итеп, Дошман малае да гаилә корып җибәрде. Авыл картлары гына уфтанып: «Хәерлегә булсын инде», – дип, яшьләр тарафына тештел тидермәскә, Дошман малае хакында ялгыш сүз куертмаска тырыштылар. Холкын беләләр.

Яшь кәләшне ире яратмады түгел, ул аны ошатып алды. Үзен кире кагып, кызларын башкага биргән гаиләдән шулай үч алуы иде Юнысның. Аның бөтерчек сылуын Мулла малаена кияүгә бирделәр. Яман хәбәр колагына ирешүгә, егет, атын җигеп, Айсылуларга чапты. Ата-ана, туган-тумача туй мәшәкатьләре белән йөгерешә. Юныс кызның әтисе янына килде:

– Сәлим агай, Айсылу белән бала чактан яратышып йөргәнебезне беләсез. Кызыгызның кулын бу көздә сорарга ниятләп йөри идем. Әткәй белән авыл башында йорт салып куйдык, туйга дип малларны ишәйттек.

– Йорт дисең инде алайса. Яхшы. Авылыгызда кызлар бетмәгән, алып кайт та тор! Минем Дошман йортына килен төшерерлек кызым юк.

– Сәлим агай, Айсылуның үзеннән сорыйк, аңа нинди тормыш кирәк икән?

– Атасы әйткәне кирәк булыр минем кызга!

– Сәлим агай, нинди калым түлим? Нәрсә дисәгез, шуны китерәм! – Бу сүзләрдән соң картның тәмам ачуы кабарды.

– Мине кыз сата дип белдеңме әллә? Олак моннан! – дип, Юнысны куып чыгарды кызның әтисе.

Егетенең килгәнен ишетеп, Айсылу атылып кына чыкмакчы иде дә, кечкенә гәүдәсе әнисе кулыннан ычкына алмады шул. Аны тавышы чыкмасынга авызын-кулын бәйләп базга яшерделәр. Янә егет йортка бәреп кереп, эзли-нитә калса, кыз юк инде, тю-тю.

Шуңа күрә Юныс Мулла байлыгына кызыккан Сәлим картка, кызын кызгана белмәгән Сәкинә карчыкка, җебегән чебеш Айсылуга үч итеп авылларының иң гүзәл, иң күркәм сылуына өйләнергә ашыкты. Розалия ташлаган егет умартачы Сәлимнәр нәселе булганын белгәч, егетнең нияте тагы да ныгыды...

Бакча тормышы җае белән генә ялганып китте. Көннәр суыткач, хуҗалар сирәк килә торган булды. Хәер, аларның килүе Юныска артык кыенлык та тудырмады. Ул үзенең кечкенә каравыл өендә, вак-төяк эш белән мәш килеп, килүче-китүчеләрне күрмәде дә диярлек. Үзе дә кеше күзенә артык күренеп йөрмәскә тырышты, ахры, аның бу ягы бакча хуҗасына да бик ошады. «Җәйгә дә калдырырга кирәк бу кешене. Бер арада иплән сөйләшәсе булыр», – дип, күңелендә бер ният яңартып куйды бакча хуҗасы.

...«Шәһәрдән шәһәргә йөрүләрнең ноктасы шушы булырга охшаган. Шулкадәр гөнаһлы була торып, Аллаһы Тәгаләм ник бу кадәр игелек күрсәтә икән үземә» диган уйлар тынгылык бирми иде Юныска. Аның ризык та, баш өстенә түбә дә сораганы булмады Ходайдан. Ул бары тик соңгы сәгате җитеп, җаны күкләргә ашкан чакта, гәүдәсенең җир өстендә исраф булып ятмавын, тиешенчә җеназа кылып озатуларын гына үтенде. Тормыш белән андый хушлашуларга лаек булмаган тәкъдирдә, һич югында туфракка иңдерелүен, шушы тәненең, гәүдәсенең җансыз килеш җир өстендә тузып ятмавын ялварды ул. Күкләрнең шулай игелек күрсәтеп гөнаһлы җаныңны җәзалавы әллә... Читен икән ул үз гаебеңне тоеп, кешеләрнең күзенә туры карый алмый яшәүләре.

Ютәле генә тынгы бирми менә. Дүрт ел буе теләсә кайда кунып, туңып йөрүләрнең нәтиҗәседерме. Әллә әнисе әйтеп килгән каргыш дигәне шулай эчтән, күкрәк турыннан акрынлап кимерәме? Кем каргады икән Юнысны?! Розалияме, әллә теге бәдбәхет Мәгъсүмме? Әллә шуларның ата-аналары күз яше тоттымы икән... Үзенең әнисенеке генә булмасын, Ходаем. Калганына Юныс түзәр. Үз әнисе генә каргамасын.

Тагын кара җиргә ак ямаулыгын чигеп кышка кереп бара табигать. Ишегалдын киң итеп көрәп, карны бакча ягына ташый Юныс. Ай яктысында, кеше булмаганда эшләп гадәтләнгән. Үзенең артык тавышы да чыкмый. Бары шул ютәле генә.



Ап-ак бакча юлына күмер кисәкләредәй кан тамчылары тәгәри. Көрәк эзеннән шомарып калган кәгазь төсле тигез сукмакны яндырып, кызыл чокырлар уя. Соңгы арада Юнысның кан төкерә-төкерә ютәлләвенә борыныннан кан китүләр, кан косулар кушылды. Көннән-көн көчәя барган бу зәхмәт, тәүлекләрне түгел, сәгатьләрне санап куйган диярсең...

Розалиянең яңагына сугып җибәргәч тә, яңа явып үткән беренче кар өстенә тамчы-тамчы алсу мәрҗәннәр тәгәрәде. Хатынның күз яшьләре белән кушылып, кайнар кан тамчылары күпереп торган йомшак карны эретеп, ишек катында шыксыз кара эзләр калдырды. Авылның асыл кошын Дошман малаена кияүгә чыгарга ашкындырган хак сәбәпләр ачыкланды.

Зөфаф киче мәхшәр төненә әверелде. Кәләшенең саф булмавына төшенгән ир котырды. Башта идән буйлап типкәләп тәгәрәтте хатынын. Соңыннан чәченнән сөйрәп торгызып, җавап таләп итте. Үзенә кирәген ишетте. Кар өстенә яланаяк, юка бер күлмәктән чыгарып ташлады. Ул төнне Розалия мал абзарына кереп кунды. Ярый әле маллары бар иде. Икенче көнне үк хатынын кире илтмәкче иде Юныс. Кире уйлады. Аның саф кыз булмавы хакында бары бер кеше белә. Менә шул имгәкнең авызын гына томалыйсы.

Атна-ун көн узгач, авылда умартачы Сәлимнәр нәселеннән Мәгъсүм атлы егет югалган икән дигән хәбәр таралды. Имеш, күрше авылга барган җиреннән аты, буш чана тартып, капка төбенә кайтып туктаган. Егетне тере килеш тә, үле гәүдәсен дә табучы булмады.

Розалия иренә бу хакта сүз кушарга курыкты. Бу эштә Юнысның каты кулы уйнаганын сизенде ул. Ләкин ни дә булса сорарга, төпченергә батырлыгы җитмәде. Иренең сырма җиңендәге кан эзләрен сабын белән генә түгел, кайнар күз яшьләре белән юды яшь хатын. Үзенең ялгышын, төзәтеп булмаслык хата кылганлыгын шунда төшенде ул. Ике ел йөргән егете, бер көн салмыш килеп, бөтен дөньяның астын өскә әйләндерде дә куйды бит. Башта Розалиянең чаялыгы аркасында туган имеш-мимешләр белән теңкәсен корытты. Ник көнләшә иде ул. Кабат тәмам тилереп, кызның өстенә ябырылды. Саф иде Розалия, саф кыз иде. Вәгъдәләшеп йөргән егете алдында тамчы гына да гөнаһысы, гаебе юк иде. Ләкин Мәгъсүм вәхшиләрчә кыланды: күз яшьләренә буылып, ертылган киеме белән җәберләнгән тәнен ничек тә булса яшерергә азапланган кыз баланы мәсхәрәләп көлде.

Ул төнне Розалия бакча артлап ялгыз яшәгән Гайшә карчыкның бусагасына кайтып егылды. Әбекәй барын да аңлады. Төн уртасында мунча өлгертеп, Розалияне өшкереп юындырды. Шунда икенче көнне әти-әнисенә дөресен генә сөйләгән булса... Кызганды аларны Розалия. Юныска кияүгә чыгып оятын яшермәкче булды. Артка юл юк инде. Ничек булса да алга таба яшәргә, Юныс белән тормышын көйләргә кирәк. Ни генә дисәң дә, Розалиянең никахлы ире бит ул.

PRESSA

Киленнең бәхетеннән кайната белән кайнанасы ипле, йомшак кешеләр булып чыкты. Сәмәт картка Дошман кушаматы да теленә күрә генә тагылып калган икән. Бабай дошманнар турында, сугышта булган имеш-мимешләр хакында мәзәк рәвешендә әкәмәтләр сөйләргә оста, көр күңелле бер зат булган.

Исемен җисеменә туры китереп, авыл кешесен хәйран калдырып, Дошман нәселе Юныс та буй җитте. «Ата-анаңа бер дә охшамагансың, җен алыштырган бала», – дип, авыл карчыклары тирги иде үзен. Өлкәннәр әйткәнә бер колагыннан ничек керсә, икенче колагыннан шулай төшеп кала торган булды. Бары әнисенең күз яшьләреннән генә курка иде ул. Әнкәсен фәрештә урынына күрә иде сабый. Егет булгач та анасы алдында теле дә ипле, үзе дә гамьле кешегә әйләнә иде.

Розалиянең башына тагын бер кайгы төште. Ничә ел буе бала таба алмый йөдәде ул. Баштарак ире кыйнаганнан карыны төшәдер дип фаразлады. «Аякларыма, кулыма сук, башымны төй, Юныс, эчемә генә тимә, зинһар», – дип, иренең аякларын кочаклап үкседе хатын. «Теләсәң ни эшләт, чәчемнән сөйрә, берүк карыныма гына кагылма. Хатының кысыр дип көләләр бит. Бер ул булса да табыйм инде үзеңә», – дип ялвара торгач, иренең аңына барып җитте, ахры, бер мәл кул күтәрүдән тыелды Юныс. Карашы белән көйдерде, берсеннән-берсе усал сүзләр белән телде бәгырен, ләкин кагылмады бүтән. Ә бала тумады. Розалия йөккә уза, ләкин күтәрә алмый. Иң озак күтәргәне алты ай чамасы булгандыр. Үле туган ир баланы күз яшьләренә буыла-буыла кайнанасы белән алмагач төбенә күмделәр.

Кинәт бер-бер артлы картлар авырый башлады. Урын өстендә озак ятмады гөнаһсыз җаннар, бер ел эчендә, чиратлашып, фани дөньядан китеп тә бардылар. Менә шуннан соң көн бетте хатынга. Юныс бәйдән ычкынган кыргый җанвар төсле кыланды. Хатынның кара көймәгән җире калмады. Сафлыгын җуеп иргә барган кысыр хатын исеме күтәрү шул кыйналулардан да авыр булгандыр аның үзенә. Һичьюгы, ата-анасы, авыл кешесе белә күрмәсен, гайбәтен сөйләп туганнарының җанын көйдермәсеннәр иде дип теләде ул. Никадәр мәрхәмәтсез кыланса да, Юныс гаиләдән гайбәт сөйләрлек бер сүз чыгармады. Хәтта үзенең ата-анасына да хатынына булган салкынлыгының сәбәбен аңлатмады. Шуңа күрә Розалия иренең әнисенә бөтен дөресен үзе сөйләп бирде. Улын гаепләп, рәнҗеп китә күрмәсен дип, үзенчә акламакчы иде инде Юнысны.

Бу мәхшәр бер дә бетмәс, үлми котылып булмастыр дип уйлап йөргәндә, бер көн өйләренә Айсылу килеп керде. Юныс эштә. Розалия кеше күзенә күренергә куркып өйдән чыкмый, каралты арасында йорт эшләре белән мәшгуль.

– Хәерле көннәр. Керергә мөмкинме? – дип, ягымлы тавыш йорт хуҗасын өнсез калдырды. Авыл башында, Айсылу белән яшәргә ниятләп салынган йортта үткән бәхетсез елларының санын югалткан хатын кунак көтми иде. Розалия һушына килгәнче, Айсылу түргә узып өлгергән.

– Танымыйсыңмы? Юныс өйдәме?

– Озакламый кайтыр. Ни йомыш? – Хатынның тавышы тамак төбеннән коры гына киселеп чыкты.

– Мин синең яныңа килгән идем, Розалия. Таныйсыңмы мине?

– Ник танымаска! Син таныганны, ник мин танымаска тиеш соң әле, Айсылу? Миннән ни кирәк сиңа?

– Син, Юныска кияүгә чыкканчы, Мәгъсүм белән очрашкан идең. Безнең абыйның югалуы хакында да ишеткәнсеңдер дип уйлыйм. Гәүдәсен дә табып җирли алмадык. Аңлыйсыңмы?! Аның белән нәрсә булганына төшенәм... – Айсылу җитди булырга тырышса да, куллары калтырый, тавышы өзелеп-өзелеп китә. Үзе карашын тәрәзәдән алмый. Юнысның кайтканын көзли, ахры. Ләкин бер дә курыкканга охшамаган.

– Төшенгәч соң. Нигә килдең?

– Абыйның кылганы өчен синнән гафу үтенергә килдем, барысын да беләм.

– Миңа синең гафу үтенүең кирәкми. Юлыңда бул.

– Абый синең алда гаепле, Розалия. Ләкин Юнысны да аклап булмый. Абый хакына түгел, аның картаеп беткән әнисе хакына сорыйм, ирең кылган гамәле өчен җавап бирергә тиеш. Ярдәм ит миңа.

– Юк. Айсылу, башыңа бәла эзләп йөрмәвең хәерле булыр. Кит син моннан.

Розалия ашыгып, ире кайтканчы кунакны озатмакчы итеп сөйли. Каршысында басып торган кечкенә буйлы ябык хатын аңа кызганыч, мескен булып тоелды. Аның дөреслек эзләп йөргәнен Юныс белсә, ни эшләтер икән. Үзен дә, нәселен дә юкка чыгарырга мөмкин. Уйлап эш итми бит ул, күзе тонган. Тәмам үгеткә күчеп:

– Сүземне тыңла. Монда килүең беренче һәм соңгысы булсын, Айсылу. Өстәмә кайгылардан саклан син. Аллаһы Тәгалә барысын да күреп, белеп тора, тиешле җәзасын һәммәбезгә дә бирер. Кит, тизрәк кит моннан.

– Розалия, син куркасыңмы?

– Минем курка торган күлмәгем тузган инде. Ә синең балаларың бар. Мәгъсүмнең анасы турында түгел, улларың хакында уйлар идең!

Айсылу чыгып китте. Хушлашмады. Карашы белән йорт эчен күзләп чыкты да, Розалиянең әйткәннәренә күнгән төсле чыгып китте.

Ул көнне Юныс йоклый алмады, төнозын саташып чыкты. Төшенә әнисе елап керде. «Балакаем, чыннан да җен алыштыргандыр сине», – дип елый. Кочып юатасы килә үзен, һич якын китерми. «Канлы кулларың белән кагылма миңа. Бар, юын. Гөнаһыңны юарга кирәк, балам», – дип китеп бара. Ничә көн рәттән саташканын, йоклый алмавын күреп торган хатыны түзмәде, кабат кыйналасын белсә дә, сүз кушарга ниятләде.

– Айсылу килгән иде, – дип ярып салды ул. Бу сүзләр иренең башына күсәк белән органдай тәэсир итте.

– Кайсы Айсылу?

– Умартачы Сәлим кызы. Абыйсының гәүдәсен ничә ел эзлиләр инде...

– Син нәрсә дидең? – Юнысның карашы таркау, тавышы төксе.

– Әйтмәдем бер сүз дә. Әниең төшеңә юкка керми. «Адәм баласының мәете җир өстендә исраф булып ятарга тиеш түгел. Шартын китереп җирлисе иде бичараны», – дип, исән чагында да бик өзгәләнде ул.

– Тагын шул балык башы...

– Юныс, анаң хакына дим. – Розалия иренең янына ук килде. Бергә яшәлгән гомер дәверендә беренче тапкыр күзләренә туры карап, иңнәренә кагылды. – Һичьюгы, аның кайдалыгын әйт. Мәетен зиратка илтеп күмсен туганнары.

– Теге чакта Сәлим агай кызын миңа биргән булса, бу хәлләрнең берсе дә булмый иде. Әнкәйнең күпме күз яшен койдырдылар, нәселләрен корытасы!

– Әйе, алар хаталангандыр. Ләкин анаңның яшен түктерүче син үзең! Тәнемдәге ул яраларны яшереп бетерерлек ялган булмагандыр дөньяда. Әле сыер сөзде дидем, чыбыкка төртелдем, таеп егылдым, тегендә яндым, монда бәрелдем дип гел ялганлап, чынбарлыктан аларны сакларга тырыштым. Әти-әниең килеп кергән саен, көн эссе булуына карамый катлы-катлы киендем. Вәхшилегеңне нәрсә белән дә булса акларга тырыштым. Ә ул елады. Мескен, кичерүемне сорап, чәчләремнән сыпыра-сыпыра әллә ниткән догалар укып елады. Авырым төшкән саен, миннән дә ныграк ачынып, әниең елады. Айсылуга карап тордым. Аның да күзләре гел әниеңнеке төсле икән. Шулай ук мөлдерәмә тулган. Чәчләрен дә, әниеңә охшатып, ике якка үреп салып, яулык бәйләгән. Абыйсының гәүдәсен җеназа кылып соңгы юлга озата алмауларына өзгәләнәләр. Йөрәгеңдәге мәхәббәте ачы нәфрәткә әверелүенә түзә алмый елый ул. Юныс, Мәгъсүмнең кайдалыгын син генә беләсең!

Розалиянең тавышы сөйләгән саен көчәя бара. Еллар буе үзен тыеп торган хатын, шашкан төсле ачынып, ярсып вөгазь җебенә вакыйгаларны тезә, кылынган хата-ялгышларны күтәреп, яраларны актара. Аның үз яралары төзәлмәслек җөйләр хасил иткән инде, ул күптән яшәүдән ваз кичеп, тән асрауга күчкән. Бәлкем, ул теге төнне үк, ике елдан артык яратышып йөргән кешесенең мәрхәмәтсезлегенә түзә алмый үлгән булгандыр... Бүген бу хатын авыртуны да, куркуны да белмәс тере мәеткә әверелгән. Шуңа күрәдерме, ул кыю. Җанварга аның вәхшилеге хакында сөйләү ансат түгелдер дә, бу дөньяга адәм баласы булып туганын исенә төшерү мөһим шул. Йә бүген Розалия Юнысның дошман түгеллеген, ә Кеше булуын, анасының газиз улы булуын дәлилләр, йә бу аның соңгы тапкыр җиһанга оран салуы. Курка торган күлмәкләр тузган. Әти-әниләр күптән зиратта көтеп ята үзен.

Юныс танымаслык булып үзгәрде. Айсылуның әнисенә охшаганлыгы турында ишетүе тетрәндердеме аны, анасының көн дә төшенә кереп саташтырганы миңгерәүләндереп җибәрдеме. Розалиягә дәшмәде ул. Аны бөтенләй күрмәс, ишетмәс булды ир. Теге Мәгъсүм белән ни эшләргә соң? Унбиш елдан артык колхоз гаражының каравылчы йорты идәне астында ята бит. Анда җирләрлек нәрсә дә калмагандыр инде. «Яшергәнеңне тапмасыннар дисәң, күз алдына куй», – дигәнне карчыклардан ишетеп калган Юныс. Кирәкмәгәне шулай хәтеренә чорналып барды аның. Мәгъсүмне дә авылга алып кайтып, ташландык гараж йортының идән астына күмеп куйды ул. Шул тирәдә гел сасы ис килә дип зарланды авыл халкы. Бер-ике эт, мәче үләксәсе таптылар. Начар иснең чыганагын шуларга юрадылар.

Хатирәләргә бирелеп, төшләрендә әнисе белән саташып берәр айлап йөрде Юныс. Розалия иренең кинәт үзгәреп китүен үзенчә юрады. Котырып йөри торгач, акылына берәр зыян килгәндер дип уйлады.

Бер төндә авыл колхоз гаражы яна дигән куркыныч хәбәрдән уянды. Бәхеттән, янгын гаражның бер почмагындагы ташландык каравылчы йортында гына булып чыкты. Икенче көнне янгын калдыклары арасыннан кеше сөякләре таптылар. Авылда Дошман малае Юныс югалган дип тә сөйләделәр. Табылган кеше сөякләрен аның җәсәде булгандыр диеп фаразладылар.

Бары Розалия генә Юнысның исәнлеген, гараж йортының янып китү сәбәбен белде. Күрше авылдан Айсылуны чакыртты хатын.

Бу хәлләрдән соң ярты ел да тормады, йөрәк өянәгеннән Розалия дә дөнья куйды. Айсылу аны ахыргы көннәрендә тәрбияләп, бәхилләп соңгы юлга озатты. Көндәшенең әйберләрен җыештырганда аның еллар дәвамында алып барган көндәлеген тапты. Саргайган дәфтәр битләрендә бу гаиләнең бөтен фаҗигасе, күп серләрнең җан өшеткеч хакыйкате ярылып ята иде.

«Җен алыштырган бала, ничек дәваларга соң аны?! Әнисенең карашыннан, бигрәк тә күз яшеннән курка иде эчендәге шайтан. Тынып кала иде. Ул иблискә каршы торырдай ике фәрештә булган җир йөзендә. Берсе әнисе. Икенчесе – тәүге мәхәббәте, ике тамчы судай әнисенә охшаган күрше авыл кызы Айсылу. Алар янында ул Кеше иде. Фәрештәсеннән аермаган булсалар, аның Кеше булып калырга өмете бар иде. Һичьюгы, иблисен тыярдай сафлык, пакьлек кирәк иде аңа. Ни кызганыч, мин аның эчендәге шайтанын уятучы, җенен котыртучы гына булдым. Иблисне тыярлык сафлыгым урланган иде шул. Талап алдылар аны! Сафлыгымны гына түгел, бөтен җанымны, бәхетемне, кешелегемне талап алдылар. Үкенечле булды бу гомер. Дәваларга кирәк Юнысны, коткарырга кирәк. Анда Кеше югалмаган, күзләреннән күрдем. Буш карашында бәхетсез Кеше шәүләсе бар... Коткарырга кирәк Юнысны», – дип язылган иде көндәлекнең соңгы битенә.

Тагын кар ява. Буранлап, усалланып килә быелгы кыш. Башына ак яулыгын каплап, бүлмәсендә ут яндырмый гына төнне күзәтә Айсылу. Хатынның йокысын качырып ыңгырашкан җил авазы, катланган тәрәзәләр аша авыру кеше тавышына охшап, күңелне өшетә. Кемдер тәрәзә артында авыртуына түзә алмый, ютәлли-ютәлли ыңгыраша диярсең. Беркемне дә чакырмый, ярдәм дә сорамый үзе. Җен алыштырган тәненә төшкән каргышны кабул итеп, күкрәк турыннан көйрәгән җанын түкермәкче булып, Кеше йөткерә төсле. Аңа бу дөньядан бары тик фәрештәсенең бәхиллеге генә кирәк. Дару да, дәва да эзләми инде ул.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Сугыш тәмамланганда миңа 5 яшь иде. Ул еллар, авылыбыз Енопайга исән-сау кайткан фронтовиклар әле дә күз алдымда тора.

Мөкип абый безгә туган тиешле иде. Сугыш башланыр алдыннан ул чик буе хәрби училищесы курсанты була. Алгы сызыкка да беренче булып алар баса. Күп тапкырлар яралана. Баш сөягенең яртысы диярлек ясалма сөяккә алыштырылган иде аның.

Безнең әти дә (*фотода*) сугыштан 1945 елның декабрендә кайтты. Әти белән Мөкип абыйның кайтуы хөрмәтенә зур итеп мәҗлес кордылар. Икесенең дә күкрәге тулы орден-медаль. Алар миңа уенчык шикелле тоелалар иде.

Тагын бер туганыбыз – Галимҗан абый әсирлектә булса да, туган авылы Енопайга исән-сау әйләнеп кайта. Әсирләрне иллешәрләп-иллешәрләп атып үтергәннәрен сөйли торган иде. Галимҗан абыйга да эләгә дошман ядрәсе. Бәхеткә, ул үлми, яралана гына. Үзебезнекеләр ягына чыгып, кабат фронтка керә.

Авылыбызга фронтовиклар күп кайтты. Ләкин берсе дә орденнарын тагып йөрмәде. Алар шул кадакчүкеч тартмасына тутырылган килеш теләсә кайда күгәреп ятты. Бу ирләргә илне кабат күтәрергә кирәк иде, орден кайгысы булмады.

Күрше Калтай авылында да фронтовиклар күп иде. Сугышта уң аягын калдырып кайткан Аҗмухан абый колхозда эшли алмагач, итекче булып көн күрде. Бер кулсыз кайткан Муллаш абый, сул кулы белән язарга өйрәнеп, счетовод булып эшләде. Гыйззәт абый сугыштан күзсез кайтты. Яралануларын, әсирлектә булуларын кычкырып сөйләп йөрергә ярамады. Сталин заманнары иде шул. Кырда ике башак белән тотылсаң, биш ел төрмә. Басуда череп ятса, ятсын, халыкка гына булмасын.

Сугышка кадәр әтием үз авылыбызда «полуторка» машинасында шофер булып эшләгән. Сугыш башланган көнне аны төнлә белән килеп алалар. Без – дүрт бала, әтинең киткәнен дә белмичә, идәндә йоклап калганбыз. Әтигә Ленинград фронтында катнашырга туры килә. Бер бәйрәмдә Канәфи абыйга сөйләп торганын ишеткәнем булды: «Без Ладога күленнән Ленинградка снарядлар, солдатлар ташыйбыз, ә аннан исә балаларны, карт-карчыкларны алып чыгабыз. Боз ярылып, никадәр кеше боз астына китте шул вакытта». Әти үзе дә берничә мәртәбә су астына китә. Ленинградтан соң аны Омск каласына – танк мәктәбенә укырга җибәрәләр. Берлинга кадәр барып җитә әти. Штарград шәһәрендә төшкән бер фотосы да саклана әле миндә.

Әтинең сугыштан кайткан көнен дә аз гына хәтерлим. Аны 28 чакрымдагы район үзэгеннән Тәгъри апа ат белән барып алды. Әти ике чемодан күтәреп кайтып керде. Ул арада өй тутырып халык җыелды. Әнинең ул алып кайткан Америка консервасыннан аш пешергәнен беләм. Аннары ниндидер сәдәфләр, булавкалар, сабын, әнигә дип алган күлмәк белән пальтосы бар иде. Әни ул пальтоның әллә ни куанычын да күрмәде. Көне-төне колхоз эшеннән кайтып кермәгән хатын аны киеп кая барсын инде? Тагын унлап көмеш кашыгы, чәнечкесе булуы истә. Мине иң кызыктырганы – немец офицерының кинжалы иде. Без уйнагач, әти аны каядыр алып ячерде. Соңыннан белдем, милициягә илтеп тапшырган икән.

Без укыганда Енопай урта мәктәбе татар мәктәбе иде. Рус телен без алтынчы класстан гына өйрәнә башладык. Өч укучыга – бер китап, өйдә дәрес әзерләү юк... Мәктәптән соң, 1959 елдан 1962 елга кадәр проходчик булып эшләдем. Аннары Томск шәһәрендә хәрби училищены, университетның тарих факультетын тәмамладым. Өч мәртәбә дәүләт полигонында сугышчан расчет белән ракета җибәрүдә катнаштым, өлкән лейтенант исеме алдым. Укуымны Мәскәү хәрби академиясендә дәвам итәсем, немец телен өйрәнәсем килде. Без бу факультетта алты гына офицер идек. Аның берсе мин – сигез балалы ярлы гаиләдән, 10 классны чабаталы килеш татарча укыган егет.

1971 елдан тормышымда авыр чор башланды – гаделлек эзләвем җитәкчеләргә ошамады. Политбүлек, КГБ юлларын күп таптаттылар. 3 нче курстан академиядән китәргә мәҗбүр булдым. Хәтта ике бүлмәле фатирымнан да чыгардылар. Мин бу вакытта гаиләле, икенче балабыз ай ярымлык кына иде.

Моннан соң кайларда гына эшләргә туры килмәде, кемнәр белән

генә аралашмадым. Хәтта Германиядә дә яшәп алдым. Шунда Вильгельм Уленхот исемле Вермахт солдаты белән таныштым. Ул 1922 елгы. Сталинград сугышында катнашкан. «Ул вакыт 40 градуслы салкыннар булды. Барыбыз да паникада. Ризык китерә алмыйлар. Ягарга утын юк. Бетләдек... Берсендә разведкага җибәрделәр. Яланда бер рус солдаты белән кара-каршы очраштык. Икебезнең дә кулда пистолет. Ләкин беребез дә атмады, һәркем үз юлы белән китте. Кайчак, командирлар югында, штыкка ак флаг бәйлибез дә, каршы як солдатлары белән күрешәбез. Ач икәнне белеп, рус солдатлары ипи, сало бирә».

Бу сугышта әниемнең биш абыйсы һәлак булган. Эзләрен табарга бик теләсәм дә, таба алмадым.

Кайда да татарлар турында күбрәк сөйләргә тырыштым. Тормышым ничек кенә авыр булса да, беренче чиратта халкыма булышырга омтылдым. Томск өлкәсендә мин концерт куймаган бер генә авыл да калмагадыр.

Мадрид ГАТИН.
Томск шәһәре.



1953 елда Үзбәкстанның Нәмәнган медицина училищесына укырга керүеннән санасаң, 60 елдан артык инде Саимә Имам кызы ак халаттан. Сиксәненче язын да Азнакайның балалар хастаханәсендә ак халаттан каршылый ул.

Балачагы бик авыр уза Саимәнең. Әтисенең бар мөлкәтен, яши торган өен тартып алып, кулак тамгасы тагалар. Аптырап, Донбасс якларына да барып карый ул. Сугыш башлангач, беренче көннән үк фронтка киткән әтиләре 1941 елның ноябрендә үк яу кырында башын сала.

Колхозның каравыл өенә сыенган Саимә, энесе, әнисе, әбисе көч-хәл җан асрыйлар. Башлангыч һәм җидееллык мәктәпне яхшы тәмамласа да, 4-5 чакрымдагы Азнакай мәктәбенә йөреп, укуын дәвам итә алмый – нәрсә киеп барсын, өстенә дә, аягына да юк бит... Колхоз рәисе Хөсниямал апа, моны белеп алып, кызны идарәгә чакырта. Аны Тәтешкә агротехниклар курсына җибәрү уен әйтә. «Туу таныклыгыңны монда калдырасың, шунсыз син монда кире әйләнеп кайтмыйсың!» – ди рәис. Кызның: «Ансыз мине кем укырга алыр, кем яшәргә кертер икән соң», – дигәненә каршы, «кулак калдыгы, син әле бәхәсләшеп торасыңмы?» дип, бик каты ачулана.

Икенче көнне өйдәгеләр белән саубуллашып, авылдан чыгып китә Саимә. Барыр юлы ерак – Ташкент, Нәмәнганнарны үтеп, Янгы Курганга кадәр. Анда әнисенең бертуган сеңлесе Мотыйга апа яши. Ишетеп белүенчә, җизнәсе укымышлы кеше, сугышка кадәр Үзбәкстан мәгариф министрлыгында җаваплы хезмәт башкара. Әмма... сугышта әсирлеккә эләккәннән соң, җизнәсенең үзенә дә монда сан калмаган икән шул.

Ятимәне кочак җәеп каршыламасалар да, хастаханәгә санитарка итеп урнаштыралар. Монда шунысы ярый: зәмһәрир кышлар үзәккә үтми, калын киемнәр кирәкми. Алай да Татарстанда калган туганнары сагындыра, әнисе бер дә күз алдыннан китми. Алардан күчкән тырышлыгы бар кызның – 1 сентябрьдән Нәмәнган медицина училищесына укырга керә. Аны кызыл дипломга тәмамлагач, Андижанга медицина институтына җибәрәләр. Алган стипендиясен, җәйләрен мамык кырларында эшләп тапкан акчаларын кушып, Татарстанда калган әнисенә дә ярдәм иткәли. 1962 елда институтны да кызыл диплом белән тәмамлый. Гаҗәп түгел, Саимәнең туганнары арасында фән докторлары да бар. Биология фәннәре докторы, профессор Ринат Зәкиев та шушы нәселдән. Саимәгә дә аспирантурада калырга тәкъдим итәләр, ләкин ул әнисен уйлап, җиң сызганып эшкә тотына – Термез шәһәренең онкология диспансерына билгелиләр аны. Ә тагын бер елдан туган ягына, үз халкына хезмәт итәргә кайтып китә.

Берничә елын хатын-кызлар консультациясендә акушер-гинеколог булып эшли. Бу елларны икенче институт тәмамлауга тиңли ул үзе. Шулай булмый ни: Татарстанда бердәнбер Социалистик Хезмәт Герое исемен йөрткән Газифә Хәсәншина һәм РСФСРның атказанган табибы Люция Гомәроваларның кул астында эшли бит. Бераздан яшь табибәгә яңа профильдә укырга тәкъдим итәләр. Шулай итеп, оториноларинголог булып китә ул. Ике дистә елдан артык олыларны да, балаларны дә тамак-борын чирләреннән дәвалый, катлаулы операцияләр ясый. Мин үзем дә 1971 елда аңардан операция ясаткан кеше буларак, гомерем буе рәхмәтле булдым.

Саимә Имам кызын тирә-як шәһәрләрдә дә яхшы беләләр. Лениногорск шәһәре зураеп, табиблар җитми башлагач, 1973–1985 елларда гаиләләре белән шунда да яшәп алалар, балалар үстерәләр. Тормыш гел шома гына бармый. Инде рәхәтләнеп яшәргә, оныклар сөяргә дигән көннәрдә генә киленнәре вафат булып, ятим калган 3 яшьлек оныклары Маратны да үзләре карап-тәрбияләп үстерә. Алай да Саимә апа тормышыннан бер дә зарланмый. «Максатыма ирештем нинди мәхрүмлекләр күрсәм дә, тормыш төбеннән күтәрелеп, Кеше була алдым. Шундый авыр елларда да исән калып, халык табибы була алуым үзе бер могҗиза. Кешеләрнең җылы карашын тоеп яшәүдән дә олырак бәхет юк», – ди горурланып Саимә Имам кызы Якупова.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.
Азнакай шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

БӘХЕТКӘ ЮЛЛАР УРАУ

«ЯРЫЙ ӘЛЕ АЕРЫЛГАНМЫН...» ТАНЫЛГАН АЛЫП БАРУЧЫ, РЕЖИССЕР ЗАМИРӘ РӘҖӘПОВАНЫҢ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРДӘ ЯЗГАН БУ СҮЗЛӘРЕ НИНДИДЕР БЕР ДУЛКЫННЫ КУЗГАТЫП ҖИБӘРГӘНДӘЙ БУЛДЫ.

Күпләр үзләре арасындагы мөнәсәбәтләр турында уйланды, аларга читтән күз салды... Замирәне хатларга күмүләре, аңа эч серләрен ачулары, сораулар яудырулары – шуңа да. Хатын-кызның бәхете, бәлки, вакытында тәвәккәлли белүдәдер? Тормышны үзгәртим дисәң, нидер эшләргә кирәк. Хатын-кыз исә менә шуңардан курка да. Гомерләрне икегә бүлә торган бу кискен карарга килү Замирәгә дә җиңел булмаган. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.





Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Хатын-кыз бик озак түзә ала инде ул. Әмма түзүнең дә чиге булырга тиеш бит.

– Кеше ниндидер карарны бер чиккә килеп җиткәч кенә кабул итә ул... Һәркемнең дә комплекслары балачакка барып тоташа, диләр. Без әтисез үстек. Ижевск шәһәрендә эшләгән вакытта әнием шунда хезмәт итүче үзбәк егете белән таныша. Бер-берсенә шунда ук гашыйк булалар: әти әнине үзе белән алып китә. Миңа – 2, сеңлемә 1 яшь булганда әни авылга кунакка кайта һәм... кире китми. Чит-ят җирдә рәхәт булмагандыр инде... «Әниегез шырпы кебек кенә калган иде», – дип сөйли иде дәү әни. Әти кайтып алмый, әни кире бармый. Аерылганда нибары 24 яшь була аңа. Сорап килүчеләр дә булгандыр, әмма ул үзенә башка кешене якын җибәрмәде, кабат кияүгә чыкмады – безне ялгызы гына үстерде. Кыз балалар янына үги ата, чит ир китертәсе килмәде бугай...

Әти юклыгын сиздем дип әйтә алмыйм – мин аны белмим дә бит, әмма тулы гаилә турында хыяллану бар иде. Азып-тузып йөрмәдем, моның белән хәзер мактанмасалар да, кияүгә кыз килеш чыктым. Әни тәрбиясе! «Йөземә кызыллык китермәгез!» – дип үстерде ул безне.

Фәриткә чыкканда миңа 26 яшь иде. Шашып яраттым дип әйтә алмыйм. Кияүгә чыгарга кирәк, ялгыз калам дип курыкканмындыр, күрәсең. Әмма мин язмышка да ышанам. Язмыш булгандыр... Аның хатын аерганын белә идем. Ә ике тапкыр өйләнеп аерылган булуын иртәгә никах дигән көнне генә ишеттем. Инде туй көне билгеләнгән, кунаклар чакырылган иде. «Әйе, шулай. Тик мин моны сиңа әйтергә курыктым, сине югалтасым килмәде», – диде ул миңа. Ничек кичермисең – мине югалтмас өчен алдалаган бит! Минем хакка!

Хәзер уйлыйм, араны өзәргә аңа кадәр дә берничә җитди сәбәп булган, нигәдер аларга игътибар гына итмәгәнмен. Берсендә шулай икәү кибеттә йөрибез. «Син бара тор, мин хәзер киләм», – диде дә, ниндидер киштәләр арасында калды бу. Көтәм, һаман килми. Карыйм, беренче хатынын очраткан да, аның белән сөйләшеп тора икән... Мин хәзер бөтен ир кешене Максим белән чагыштырам. Ул булса, кулымнан тотар иде дә: «Янымда гына басып тор», – дияр иде. Безне таныштырыр иде: «Бу – булачак хатыным», – дияр иде... Фәритнең кемлеге хакында бу очрак бик күпне сөйләгән, тик, әйткәнемчә, яшьлегем белән аңламаганмын. Ир-ат күреп үсмәгәч, аның нинди булырга тиешлеген белмим бит. (Әниләр – дүрт кыз туган, аларның һәрберсендә – икешәр кыз: йорт тулы кыз бала иде бездә!) Нибары өч ай гына очраштык: бу вакыт эчендә аны үзем өчен ачып та бетерә алмаганмын. Ә ул шундый илтифатлы, игътибарлы иде...

Октябрь аендамы икән, әллә декабрьдәме, хәзер инде хәтерләмим, икенче хатыны шалтыратып: «Син дә белеп тор, мин бәби алып кайттым. Балам Фәритнеке», – диде. Аязым исә февральдә туды. Балаларның аермасы нибары ике-өч ай гына. Димәк, ул минем белән очраша башлаганда әле хатыны белән яшәгән, безнең никах алдыннан гына аерылган... Авырлы хатынын ташлаган. Шуларны уйлыйм да, хәзер исем-акылым китә. Менә кайда ул Санта-Барбара! «Шулай килеп чыкты инде...» – дип кенә аңлатты ул. Тагын ышандым! Җүләрлек димичә, ни дисең?! Нигә мин боларның барысын гафу иттем, белмим. Гаиләм тулы булуын, баламның әти белән үсүен бик тели идем шул...

Бер ел әйбәт кенә яшәдек. Аннан башланды... Мин гел әйтәм, хыянәт – ул ис кебек һавада очып йөри дим, барлыгын сизәсең, кулга тотып күрсәтеп кенә булмый. «Йөрисең бит», – дим Фәриткә, ә ул: «Юк, уйлап чыгарасың», – ди. Ялгышмый идем, интуициям көчле минем. Аннан Аяз туды, тагын ике-өч ай кешечә яшәп алдык. Шуннан соң инде ачыктан-ачык йөрүләр башланды. Иртәнге дүрттә-биштә кайта да, өс-башын алыштырып, юынып кабат чыгып китә... Исемә төшсә, хәзер дә дертләп куям. Тормыш түгел, җәһәннәмдә яшәү иде ул. Мин аны бер генә хатын-кызга, хәтта дошманыма да теләмим. Сине хатын-кыз буларак үтерә, түбәнсетә, юкка чыгара торган нәрсә бу. И-и, ул чактагы чарасызлык... Җан әрни, авырта – нишләргә белмисең... Ирең кайта, син аны көтеп торасың, өең җыелган, ашарыңа пешкән – мин бит пешеренергә яратам. Утырып ашый, җыена һәм: «Минем барасым бар», – дип, тагын чыгып китә. «Кая барасың?» – дим. «Таксовать итәм», – ди. «Йөрмә» диюемне тыңлап та тормый. Ничек тотып каласың аны?! Сәбәбе дә бар бит: «эш эзлим» дип чыгып китә.

Хатын-кызның бәхете – зирәклектә. Ул күп нәрсәне ишетмәскә, күп вакыт дәшмәскә тиеш.

Аязга 1 яшь тулды. Акча бөтенләй юк! 700 сум пособие нәрсәгә генә җитсен?! Телевидениедә яңа сезонга әзерләнгән чак иде, Миләүшә Ләбибовна Айтуганова: «Бирегез мәйдан» дигән яңа реалити-шоу ясарга җыенабыз, эшкә чык», – диде. Улымны әнигә кайтарып куйдым да, балага бакчадан урын алу артыннан йөри башладым. Ул чакта хәлемнең нинди булганын күрсәгез... Ябыктым, 48 килограммга гына калдым. Камера каршына басам, фикерләремне туплый алмыйм, бертуктаусыз елыйм. Режиссерыбыз Наилә Сабитова әрләп тә карый, җәлләп тә... Бакчага юллама алу өчен икебезнең дә эш урыныннан белешмә сорадылар. Сорап-сорап та алып кайтып бирмәгәч, иминиятләштерү агентлыгына үзем киттем. Шунда эшкә урнашырга теләгәнен белә идем. Җитәкчесе өлкән яшьтәге бер абзый мине шунда ук таныды, «Мәдәният дөньясында» тапшыруы аша хәтерли икән. «Ирем сездә әле эшләргә җыена гына, ләкин миңа бу белешмә бик кирәк, ясап бирегез әле», – дим. «Фәрит инде бездә өч ай эшли, шуның кадәр хезмәт хакы

ала», – дип җавап бирмәсенме. Ул әйткән хезмәт хакы хәтта бүгенге көн өчен дә бик күп! Ә мин, баламның кулына тоттырырга бернәрсәм юк, дип, кайсы көнне урамга да чыкмый идем. Сабый бит, аңламый, берсенең алмасын, икенчесенең согын тартып ала. Әниләреннән уңайсыз... «Мин сине бик хөрмәт итәм. Сүзем, бәлки, авыр булып та ишетелер, әмма әйтмичә булдыра алмыйм. Ирең монда бер хатын белән чуала. Син китмә, көт. Алар хәзер кайта», – диде ул миңа. Эшләре янындагы бакчада көтеп алдым боларны. Икәү киләләр. Миннән өлкәнрәк бер хатын. Дөрес, киенгән, бизәнгән, ясанган. «Хатының чибәр икән, Фәрит», – ди. «Сезнең хакта алай дип әйтә алмыйм», – дидем. Ирем югалып калды – нишләргә белми. «Ярый, барысы да аңлашылды, без аерылышабыз», – дидем дә китеп бардым.

Хәсрәтне сәфәрдә, юлда вакытта кичерү күпкә җиңелрәк.

Ул чакта сиңа терәк булырдай кешеләр янында бар идеме? Иң кирәк киңәшне кем бирде?

– Әйткәнемчә, яңа проект әзерлибез. Ә мин эшли алмыйм, гел елыйм. Миләүшә Ләбибовна үзенә чакыртып алды. «Ни булды?» – ди. Хәлемне аңлаткач, ул миңа болай диде: «Син хәзер бер нәрсә турында гына уйлыйсың: өйгә кайтсын, аны ташласын иде дисең. Әйе, кайтачак ул. Мондый кешеләр кайтмый калмый, чөнки ниндидер кискен адымнар ясарга җөрьәт итмәячәк, куркачак. Югыйсә сине елатып та йөрмәс иде, «башканы яратам» дип, араны гына өзәр иде. Кайтачак һәм сезнең гаиләдә вакытлыча тынычлык урнашачак. «Теге хатынны җиңдем», – дип куаначаксың: ирең алдында ике юл иде бит, ә ул сине сайлады. Әмма синдәге бу эйфория озак дәвам итмәячәк – аны күралмый башлаячаксың. Холкың шундый, беләм – үч алырга керешәчәксең. Соңрак «миңа барыбер» дигән чор житәчәк: кайда ул, кем белән, нишли – исең дә китмәячәк».

Мондый ситуациядә калган кайберәүләргә үзем дә шуны әйтәм хәзер. Әйе, ул кайтты һәм мин теге этапларның барысын да уздым. Тик ул чакта түгелгән күз яшьләрен, үпкәләр, йокысыз төннәрне тиз генә онытып, гафу итеп булмый иде шул. «Башкалар гомер буе да күрмәгәнне, син ике елда күрдең», – дия иде әни. Елый-елый хәтта аңымны югалтканым булды. Күз яшьләрем диңгез булып җыелгандыр... Шалтырата да: «Мин таксовать итәм, клиентны Баулыга илтәм», – ди һәм юкка чыга, телефонын сүндерә. Икенче көнне: «Актанышка кайтарам», – ди. Бернинди клиент юк икәнен белеп торасың югыйсә! Йоклый да алмыйсың, ашый да... Хәтта баланы да уйламыйсың. Андый чакта хатын-кызның халәтен нинди сүз аңлата икән? Чарасызлык, үзеңне артык, кирәксез итеп тою, өметсезлек... Дөньяда – гамь, бернәрсәдә ямь юк. Үлүең артыграктыр кебек...

Бакчадагы теге очрашудан соң да ике еллап дәвам итте әле безнең бу тормыш. Бала бар бит, яшәргә, түзәргә кирәк, барысы да көйләнер дип тырыштым.

...Кичке як иде. Миләүшә Ләбибовна: «Хат җибәрдем, почтаңны кара әле», – дип шалтыратты. Фәрит һәрвакыттагыча ноутбукта утыра – эш эзли. «Тиз генә почтамны ачыйм әле», – дим. Күзем төште – танышулар сайты, ябарга онытлкан.

Укый башладым... Әллә ничә хатын белән берьюлы очрашып йөргән. Очрашып кына да йөрмәгән... Ә мин көне-төне эшлим. Көндез – телевидениедә, кич – концерт, банкетлар алып барам. Машина кредиты, фатир өчен түлим, баланы каядыр йөртәм... Калганы ун минут эчендә булды. Сыер дуласа, аттан яман диләр бит әле. Фатир ишеген киң итеп ачып куйдым. Өермә кебек идем. Бөтен йорт ишеткәндер. Ни булганны аңларга да, каршы әйтергә дә өлгерми калды ул.

Фатирыбыз җиденче катта иде. Кухня тәрәзәсеннән күренә: икенче көнне иртәдән кичкә кадәр тәрәзәгә карап утырды. Җәлләвемне көтте бугай. Бер-ике тапкыр «кер» дип әйтергә дә омтылдым. Аннан: «Замирә, бу бит кабатланачак», – дим. Көне буе үз-үзем белән талашып йөрдем. Әни мине 24 яшендә ялгыз калып, шушының өчен үстергәнме? Бәхетсез булсын өченме? Мондый әти янында бала кем булып үсәр?

Бер туристлык агентлыгы җитәкчесенең туен алып барырга тиеш идем. «Гонорарны йә акча, йә путевка белән түлим», – диде ул миңа. Гомергә диңгезгә барганым юк иде. Фәритне чыгарып җибәргән кичне аңа шалтыратып: «Путевка алам», – дидем. Әллә ике, әллә өч көннән дус кызым белән җыенып юлга чыгып киттек. Мондый хәлгә калган хатын-кызларга гел әйтәм: «Өйдә елап ятканчы, кая да булса барыгыз», – дим. Диңгез минем дә борчуларымны юып төшергән кебек булды. Бөтенләй икенче булып кайттым.
Бу кешегә беркайчан кире әйләнеп кайтмыйм дип. Һәм, гомумән, башка кияүгә чыкмыйм, бөтен ир-атлар да бертөрле дип.

Җиңеләеп калдым, өстемнән тау төшкән кебек булды. Ипотекага фатир чиратым килеп җитте, ремонт башладым. Тормышым җайлана төште. Миләүшә Ләбибовна миңа гел: «Син, мөгаен, үзеңнең кешең белән түгелдер. Берәүнең энергетикасы башкаларга – әйбәт, ә сиңа начар тәэсир ясарга мөмкин», – дия иде. Әйе, шулайдыр. Хәзер уйлыйм, ул бит начар кеше түгел, бары тик мин аның кешесе булмагач, Фәрит тә үзен минем янда рәхәт тоймагандыр, шуңа безнең гаилә тормышы барып чыкмагандыр. Әйе, аның холкы да йомшак иде, бу гамәлләре йомшаклыгы аркасында да килеп чыккандыр. Кайбер нәрсәләрдә үзенә «юк» дия алмый иде. Югыйсә хатын-кыз буларак өйдә бөтен комфортны тудырган идем. Мактанып әйтүем түгел, минем өйдә ир-атларымның носкиларына, эчке киемнәренә кадәр үтүкләнгән. Әле бер дус кызым: «Бу синең хакта», – дип, телефоныма бер мәзәк җибәргән. Бер ир иптәшенә: «Хатынымнан аерылдым», – ди икән. «Нигә?» – ди тегесе аптырап. «Бертуктамый

тәртип салып торуыннан арыдым, – ди ир. – Төнлә су эчәргә генә торам, кире ятам дип килсәм – инде урын җыелган».

Үтүкләнгән носки белән ирләрне тотып торып булмый. Мин аны хәзер яхшы аңлыйм. Бу хакта сүз чыкканда: «Сине яратулары гына кирәк», – дип җавап бирәм. Ярата икән, ашарга вакытында пешкәнме, идән юылганмы, кәстрүлләр урынына куелганмы – ул берсенә дә карамый. Өйнең җыештырылган булуы әйбәт, әлбәттә, әмма бәхетле тормыш өчен иң мөһим аргумент түгел.

Мин үземне идеал хатын-кыз дип әйтмим. Андыйлар булмый да. Холкым – бал да шикәр генә түгел. Әмма үткәннәр миңа шактый сабак бирде. Максимга мин артык сораулар бирмим. Ул – музыкант: төнге бердә дә, икедә дә кайтырга мөмкин. Әмма шунысы ошый, ул алдан әйтеп куя: «Төнге 12 дән 2 гә кадәр чыгышым, җавап бирә алмавым бар», – ди. Шуңа күрә тәгаен беләм – бу вакытта ул инструмент артында, сөйләшә алмый. Туганнан туган сеңелкәшләргә дә әйтәм: «Күбрәк ирек биргән саен, аны үзеңә ныграк бәйлисең», – дим. Каядыр үзе генә барырга җыенганда: «Ярый, бар», – дип, тыныч кына калсаң, әллә ничә кат шалтыратачак әле ул сиңа. Белмим, бәлки Макс шундыйдыр.

Яшь кызлар кайчак ирләре белән үпкәләшәләр дә, әниләренә кайтып китәләр, килеп тезләнә әле ул каршыма, диләр. «Ә тезләнгән ир кирәкме соң сиңа?» – дим. Үз ireңнән нигә чүпрәк ясарга? Сине, баласын яраткач, килә инде ул, тезләнә... Ирне алга тезләндерер хәлгә җиткерергә ярамый, туктый белергә кирәк – алтын урталык бар бит ул. Психология буенча бер китаптан шундый киңәш укыган идем. Ирең нәрсәнедер үзе теләгәнчә эшләргә тели икән, әйдә, аныңча булсын, диелгән иде анда. Моның өч отышлы ягы бар. Беренчедән, ирең алдында әйбәт булып каласың. Ул хаклы булып чыга икән, бик яхшы – сез бит дөрес карар эзләдегез. Ә карар дөрес булып чыкмый икән – ул гаепле, син бит башка вариант тәкъдим иткән идең. Кыскасы, тагын син әйбәт.

Аерылышканнан соң ярты елдан очрады миңа Макс. Берәүне дә эзләп йөрмәдем, ир кайгысы юк – яралар яңа иде бит әле. Әмма аның шундый гадәте бар, уйлый икән – эшли. «Минеке буласың», – дигәч, көлгән генә идем. Барыбер аныңча булды – үзенеке итте... Инде очраша башлагач, ярты елдан соң сорыйм: «Мине яратасыңмы?» – дим. «Белмим», – ди бу. Үпкәләдем... «Ярату бар, гашыйк булу бар – мин әле аларның үземдә кайсы икәнен белмим. Бер елдан әйтермен», – ди. Ел узды. Мәскәүдә идек. Концерт алдыннан паркта йөрибез. Кинәт Макс шунда: «Мин сине яратам», – диде... Ул аны елга бер-ике тапкыр гына әйтергә мөмкин: берсен – «яратам, котлыйм», дип, минем туган көндә, икенчесен – «яратам, рәхмәт», дип, үзенекендә. Минут саен «яратам» дияргә кирәкми дә. Узган кыш әнә нинди карлар яуды – чыгуыма машинам чистартылган. Ярату – синең хакта кайгыртудыр ул.

Үткәнгә кайтып, нәрсәнедер үзгәртергә, төзәтергә мөмкин булса...

– Фәриткә кияүгә чыгар идемме икән, белмим. Әмма ул очракта Аязым булмас иде... Шуның өчен генә дә үткәннәрне гафу итәргә мөмкиндер. Бик сирәк кенә очрашабыз – бала бар бит. Фәрит хәзер Мәскәүдә яши, дингә килгән. «Теге вакытларда мине шайтан котырткан инде», – ди, гафу үтенә. Бик үкенәм, дип тә әйтә. Без аерылышкач, дүрт ел буе бер хәбәре булмады аның. Тормышымда Макс барлыкка килгәндә улыма 3 яшь иде. Ул аңа бик тиз ияләште. Балалар бакчасыннан үзен Макс алган көннәрне бик сөенә иде. Ике балабызны да бертигез күргән өчен мин иремә бик рәхмәтле. Аязның хоккей белән шөгыльләнгәнен белеп, кайчак таныш-белешләр арасында: «Безнекенең дә уйныйсы килә дә, йөртергә авыр бит», – дигәннәрен ишетәм. Ә Макс иртәнге сәгать биштә торып, Аязны хоккейга илтә. Һәр көнне! Кемдер үз баласын да йөртергә иренгән вакытта. Югыйсә икебез дә рульдә. «Мин Данил белән калып торам. Аязны тренировкага син илтеп кайт», – дип әйтә ала, тик алай әйткәне юк.

Максим Аязны читкә какса, миңа бик авыр булыр иде...

Иремне бик яратам. Аның да үземне ратуын сизәм. Әмма әлеге сынауларны үтмәгән булсам, мөгаен, бүгенге бәхетемнең кадерен аңлап бетермәс идем.





Фото: www.pixabay.com

«СЫРОЕД»ЛАР СЫР АШАМЫЙ

ЭЛЛИНАНЫҢ БИШ ЕЛ ИНДЕ ПЕШКӘН РИЗЫК АШАГАНЫ ЮК.



Лилия ГӘРӘЕВА

Беренчегә – помидор, икенчегә – кыяр аның. Көнлек рационы яшелчә белән җиләк-җимештән генә гыйбарәт булса да, көче ташып тора үзенең. Юк, вегетариан түгел Эллина Красильникова. Ул – чи ризык кына ашап яшәүче.

Пешерүне таләп итми торган ризык ашаучылар белән вегетарианнар арасында аерма зур. Соңгылары иттән, балыктан, кайчак сөт-май, йомыркадан ваз кичсәләр дә, рационнарында ботка, шулпа, таба ашлары – гомумән, кайнар ризыклар бар. Әле алай да мондый кешеләргә бертөрле кызыксынып та, гаҗәпләнеп тә карыйбыз. Эллина исә боткалар да, камыр ризыклары да, ит тә, балык та кулланмый.

«Әлеге яшәү рәвешемә барысын да уйлап һәм аңлап килдем. 35 яшемдә үк организмым шактый таушалган, төрле чирләрдән интегүче ханым идем инде мин, – ди ул. – Көн дә башым чатный, муеным сызлый, буыннарым авырта. Дәваланам дип, дарулар эчәм... Ә алар бер

җирне дәваласа, икенче җирне зарарлый. Көз җитте исә салкын тия, грипп эләктерергә генә торам...

Әнә шулай интегеп яшәгән мәлемдә «үле» ризыкларның зарары турындагы мәгълүматка юлыктым. Миңа нәкъ менә шушы система кирәк икән лә! Болай туклануга күчәргәме, күчмәскәме дигән сорау тумады да хәтта. Экспериментлар яратам мин. Чи ризык белән туклануның хикмәтен үземдә сынап карыйсым килде.

Башта ит ризыклары ашаудан тыелдым – вегетарианлыкка күчтем. Ике елдан пешкән ризыкларны бөтенләй дә кулланмый башладым.

Дөресен әйтим, баштарак бик кыен булды. Гел ниндидер берәр тәмле әйбер ашыйсым килә иде. Тәмгә бәйлелек әнә шулай бик акрынлык белән генә чигенде. Ярты еллап барды әле бу халәт. Организмым да шактый авыр кичерде бу үзгәрешне. Моңарчы да ит ашамавым үземне җиңәргә, яңача туклану системасына яраклашырга ярдәм итте.

Тозлар утыра, дип сөйләсәләр дә, кеше организмында шуның кадәр тоз туплана дип белми идем. Болай туклануымның беренче айларында ук организмдагы бөтен артык тоз чыгып бетте. Тоз хәтта тән тиресе аша да чыга, тәнемә тоз ышкыган кебек йөри идем. Алты айдан соң әйтеп бетергесез җиңеллек барлыкка килде, көчем артты, кулым белән агач та ега алырмын кебек тоела башлады. Организм бөтен көчен «үле» ризык эшкәртергә сарыф иткән, ә аңа алмашка үзенә берни дә алмаган икән. «Тере» – пешмәгән, кыздырылмаган ризык организмда бик тиз, 20-30 минут эчендә үзләштерелә. Мондый ризыклар сәламәтләндерә, яшәртә, дәвалый, хәтта гомерне дә озынайта. Чи ризыкларда яшәү энергиясе, тере аура була. Һәм ул аны кулланган кешегә дә күчә. Пешкәне исә ашказанында өч-алты сәгать тора. Бу вакыт эчендә ул әчи, чери, газлар бүленеп чыга. Мондый «үле» ризык ашау кешенең иммунитетын бетерә. Шуңа да бүген «тылсымлы төймә»сез яши дә алмыйлар.

Бер елдан мин салкын тиюнең, томау төшүнең, тамак шешүнең нәрсә икәнен оныттым. Баш авыртуы да үзеннән-үзе юкка чыкты. Иң мөһиме – буш вакытым барлыкка килде. Гәрчә ирем белән ике улым гадәти туклунучылар, көн дә ризык әзерләми булмый. Алар өчен әллә нәрсәләр пешерсәм дә, ул ризыкны авыз итеп карау теләгем юк.

Ләкин бар да шома гына барды, дисәм, дөрес булмас. Чи ризыкка күчеп ел ярым үтүгә, кисәк кенә ябыга башладым. Тик ни хикмәт, көчем әүвәлгечә күп иде. Шулай да кирәгеннән артык ябыгу мине хафага салды. Димәк, организмда нәрсәдер көйле түгел. Арыклыкны бетерү өчен рационыма «үле» ризык – кибет каймагы өстәп карарга булдым. Мин ашый торган күп кенә чи ризыклар белән дә яхшы яраша ул. Рационга каймак кушканнан соң, авырлыгым нормальләште.

Хәзер болай туклана башлавыма биш елдан артты. Шактый тәҗрибә тупладым, баштарак нинди хаталар ясаганымны да күрәм. Ул хаталарны мин генә түгел, шушы системаны сайлаган күпләр ясый. Чи ризык белән туклунучыларның күбесе чынлап та фәкать чи ризык белән генә туклану яклы, шулай гына дөрес була дип уйлыйлар.

Төрлечә экспериментлар ясаганнан соң, үзем өчен чи ризык белән туклануның дөрес вариантын таба алдым. Моны организмым үзе сиздерде. Соңрак дөрес юлда булуымны күп еллардан бирле шушы системаны өйрәнгән Максим Садовник хезмәтләреннән дә укып белдем. Ул өч төрле туклану төре бар ди. Беренчесе – сәламәтләндерә торган. Болар, әлбәттә, чи ризыклар. Алар организмны гади генә чирләрдән түгел, аллергия, диабет, хәтта яман шеш кебек, дәвага бирешми дип саналганнарыннан да дәвалый.



■ Эллина Красильникова: «Элеккеге кешеләрнең дә чи ризыкка өстенлек бирүләрен беләм. Шуңа да бүгенге чирләр булмагандыр. Моннан 100, хәтта 50 ел элек кенә дә кешеләрнең тәм тоюы башкачарак, хәзерге кебек бозылмаган булган бит. Ул вакытта кешелек табигый тәмнәргә өстенлек биргән».

Ашарга әзерлисе булмагач, вакыт та күп кала икән.

Икенче төре – «төзелеш материалы» булган ризыклар куллану. Өченчесе исә – ләззәт бирүче ризыклар. Боларга төрле баллы тәм-том, шоколадлар керә. Аларны авыз иткәч, организмда шатлык хисе барлыкка килә. Кисәк кенә баллыдан баш тарту бик кыен. Озак еллар буена чи ризык белән генә туклунучыларны гел күзәтәм. Алар сәламәт тә, көчләре дә ташып тора, ләкин күзләре бик боек, кайчак хәтта усал да. Чөнки алар үз-үзләрен мәхрүм иткән шушы кечкенә генә ләззәтне башка бернәрсә белән дә алыштыра алмый. Моны аңлау тиз генә килми әле. Кешенең, аңышмастан, башта үзенә, аннары башкаларга ачуы килә.

Икенче төргә – «төзелеш материалы»на керүчеләр – үле ризыклар. Сезнең чи ризык белән генә туклунучыларны күргәнегез бармы икән? Әйе, алар сәламәт, җиңел, ләкин шулкадәр арыклар. Болар барысын да дөрес эшлибез дип уйлый, хәтта үз тәҗрибәләрен уртаклашып, семинарлар да уздыра әле. Тик бу мәгълүмат тәҗрибәсезләрне ялгыш юнәлешкә алып кереп китә.

Дөрес тукланмаганда, организм үзенә яшәү өчен бирелгән функцияләрен башкара алмый. Мәсәлән,

хатын-кызлар авырга узмый, сөяк составы үзгәрә. Моның сәбәбе билгеле – кеше әлегә бу этапта «үле ризык»тан башка гына яши алмый. «Үле ризык» организмга «төзелеш материалы» булып хезмәт итә. Әйе, ул аны чүпли, күзәнәкләрен тыгылдыра, ләкин әлегә нәкъ менә ул гына организмда фундамент ролен башкара. Организмның күзәнәкләре «үле», авыр ризыкны резервка туплый. Күп күләмдә кулланганда, мондый ризык кешене симертә, чирләр кузгата. Ләкин бер дә ансыз гына булмый. Кешегә яшәү өчен күп ашарга кирәкми. Барысы да дөрес микъдарда булырга тиеш.

Һәр кеше үз үсеш этабын кичерә, һәркемнең үз теләге, үз кичерешләре. Чи ризык белән тукланам дип кенә башкаларны да шушыңа өндәргә ярамый. Ә менә бу хакта дөрес мәгълүмат бирү – анысы инде башка эш.

Организм эчке резервларын сарыф итеп бетергәч, үзен «ашый» башлый.

Чи ризык белән генә тукланырга әзер булмаганнар да организмны чистарту, сәламәтләндерү өчен бер-ике ай шушылай туклана ала. Үзеңне җиңел итеп тою өчен шушы вакыт аралыгы да җитә.

Көндәлек рационым бик тә гади. Баштарак уылган чи кишер, чөгендер, банан, көнбагыш һәм чикләвектән тора иде ул. Банан тамакны шәп туйдыра. Ә чикләвек һәм көнбагыш төше – аксым чыганагы.

Хәзер мин көн дә бертөсле тукланам, чөнки ниндидер тәмнәргә тартылу инде бөтенләй бетте. Көн саен җиләк-җимеш, алма, груша ише әйберләр ашыйм. Аш һәм ботка урынына помидор, кыяр кулланам. Кайчак бик сирәк кенә пешкән дөге дә булгалый. Чөнки, әйткәнемчә, организмга «төзелеш материалы» да кирәк. Чи яшелчә, чи җиләк-җимеш ашагач, алай күп эчәсе дә килми. Карлыган, чия яфракларыннан чәй пешереп эчәргә бик яратам. Ләкин күбесенчә чиста су эчәм.

Минем чи ризыклар белән генә туклануымны белгән кешеләр, бик гаҗәпләнә. «Алай яшәп буламыни? Бәрәңгесез ничек торасың?» – диләр. Дөрестән дә, мин итсез дә, башка ризыкларсыз да торырга тиз өйрәндем, ә менә бәрәңгедән баш тарту кыенрак булды. Тора-бара күнектем, хәзер бу ризыкларның берсенә дә исем китми.

«Сәламәтлек матрицасы» дигән төшенчә бар. Табигатьне, үз организмыбызны берни белми дип уйлап, без ялгышабыз. Организм үз-үзен терелтә дә, яшәртә дә ала, аңа комачауламаска гына кирәк. Ә бүгенге туклану системасы белән без аңа ярдәм итмибез, аяк кына чалабыз. «Үле» ризыктан организм үзенә кирәкле витаминнарны, микроэлементларны ала алмый. Күзәнәккә үз-үзен саклар өчен болар шулкадәр дә кирәк югыйсә.

Чи ризык белән тукланучылар хәзер көннән-көн арта. Күпләр мода итеп тә иярә. Ләкин мода өчен генә дип болай озак тукланып булмый. Кеше шушы системаны аңлы рәвештә кабул итәргә тиеш».



Югары категорияле
табиб-диетолог
Юлия КИСЕЛКОВА

Кешенең организмы уникаль. Ул теләсә нинди ризыкка көйләнә ала. Алыйк вегетарианнарны, алар ит ашамый, ләкин үзләрен яхшы хис итәләр бит.

Шулай да мин, табиб һәм традицион медицина вәкиле буларак, кеше катнаш тукланырга тиеш дип саныйм. Көндәлек рационыбызда яшелчәсе дә, чи азык та, шулай ук терлектән генә алына торган продуктлар да булырга тиеш. Һәр ризыкның үз файдасы. Ит белән балыкта аминокислоталар, аксымнар – организмга бик кирәкле «төзелеш материалы» бар. Бер генә үсемлек тә мондый төр аксым белән тәэмин итә алмый. Терлек майларын куллануны чикләргә дисәк тә, безгә анысы да кирәк. Әлбәттә, процент нисбәтен саклау мөһим. Рациондагы майларның бер өлеше – терлектән алына торган, бер өлеше үсемлек мае булырга тиеш.

Бөтен кешегә дә чи азык белән генә ризыкланып яшәү килешми. Ашказанында яки эчәклектә җәрәхәт, ашказаны асты бизе ялкынсынуы – панкреатит, шикәр чире бар икән, бу рәвешле тукланырга гомумән дә ярамый, чөнки чи яшелчәләр, нигездә, тупас клетчаткадан гыйбарәт.

Мондый төр туклану балаларга да туры килми. Аларның организмы аксым – «төзелеш материалы»н күп таләп итә. Аны үсемлекләрдән генә җитәрлек күләмдә алып булмый. Шулай ук авырлы һәм бала имезүче ханымнарга да бу рәвешле туклану зыянлы.

Пешерелмәгән ризыкларны кулланганда паразитлар эләктерү куркынычы да бар. Бигрәк тә каклаган ит, балык, кайнамаган сөт ише ризыклар хәтәр.

Сүз дә юк, чи яшелчә, җиләк-җимеш белән тукланунның файдасы бик күп. Мондый ризыкта холестерин юк. Димәк, күзәнәкләр, кан тамырлары тыгылмый, киләчәктә инсульт һәм инфаркт янамый. Болай тукланучылар артык авырлыктан да интекми. Һәм бу күп кенә чирләрдән профилактика да булып тора. Мәсәлән, диабеттан, хәтта яман шештән дә. Ә бит күп чирләр майлы ризыкны, камыр ашларын чамадан тыш кулланганнан килеп чыга.



Һадиева Эльвира

Казан дәүләт университеты

Кияүдә, кызлары Нәсибә Әкинне үстерәләр.

Карьера: шагыйрә

Тормыш шигаре:
«Һәр яңа көннең үз сөенече була».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Очрашулар ае

Шушы айларда иң нык хәтергә уелып калган вакыйга – авылга кайтып, ниһаять, укытучым Миләүшә апа Гарифуллина белән очрашу. Бу очрашуның әһәмиятен сүз белән генә аңлатып булмыйдыр ул. Рәхәт, бик җылы иде... Аннары легендар язучы (язучы гына түгел, җырчы, сәясәтче, композитор, сценарийлар авторы, шагыйрь) Зүлфү Ливанели белән очрашырга насыйп булды. Кыскасы, иң зур сөенечләр очрашуларга кайтып кала.

Казанның Казакъстан түгеллеген белделәр

Чемпионат Казанны «тәртипкә салды». Урамнар чистарды, пөхтәләнде, ай буена халыкның кәефе күтәренке булды. Үзем, кайнарланып, футбол өчен җан атучылардан түгел. Яраткан шәһәремнең күзгә күренеп яхшы якка үзгәрүенә сәбәп булды бу чемпионат. Казанны чит илләрдә беләләр хәзер. Казакъстан белән бутамыйлар инде элекке кебек. Парклар, бакчалар, скверлар күп. Күбесендә таш, асфальт, бетон җәелгән. Алар урынына яшел чирәм дә түшәргә өйрәнсәләр...

Эмодзи көне дә бар икән

Элек озын-озын хатлар язганнар, без үскәндә «смс»лар яза идек, хәзер төрле мессенджерлар аша гына хәбәрләр алыша башладык. Ул кыска хәбәрләрне төрле «смайлик»лар белән бизибез. Баксаң, аның исеме бүтән икән – эмодзи дип атала. «Эмодзи» сүзе японнарның «картина» һәм «символ» сүзләреннән килеп чыккан һәм, билгеле инде, Япониядә барлыкка килгән. Хәзер сүзне язып тормыйбыз, смартфоннарда эмодзиларга гына басабыз.
Аларның көне дә бар икән. 17 июльдә Эмодзи көнен бәйрәм итә башлаганнар. Ә иң кызыгы: эмодзиларны яшьләр генә түгел, ә әбекәйләр дә куллана башлаган. Булдыралар диясе генә кала!

сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

Ашыгабыз да кабаланабыз...

Үз-үземә вакыт таба алмый йөрим. Кулыма китап алып укымаганга да инде ике-өч ай бардыр. Тормыш куу, каядыр ашыгу гадәти була бара. Тагын әле әти-әнине ялга алып барасы килә... Кызганыч, быел да насыйп булмады. Аллаһ насыйп итсен, исәнлекләреннән аермасын иде.

Киресенчә булса, дөресрәк түгелме?

Бу җәй чемпионат белән генә узмады шул. Күңелсез хәбәрләр ишетелеп кенә тора. Инде сәяси, икътисадый яки социаль өлкәдәге проблемалар турында укымаска тырышам, шулай да колакка чалынмый калмый. Колакка чалыну түгел, шәһәр буйлап барганда ук күзгә бәрелә. Мәсәлән, бензин бәяләре.
Җәй башыннан алып, атна саен артып тора. Әйтерсең лә, байларның фонд биржасындагы акцияләре... Ә менә авылда сөт җыю бәяләре төшә икән. Киресенчә булырга тиеш бит.

«Канлы якшәмбе»нең җан өшеткеч кайтавазы

1943 елның 11 июлен Польшада «канлы якшәмбе» дип искә алалар... иде. Волыньда һәм Көнчыгыш Галичинада канлы вакыйгаларны тарихчылар моңа кадәр украин милләтчеләренең поляк крестьяннарына карата геноциды итеп бәялиләр иде. Ул вакытта, төрле чыганаклар буенча, 35 меңнән 100 меңгә кадәр Польша кешесе җәзалап үтерелгән. Күптән түгел Польша президенты Анджей Дуда әлеге җинаятьне этник чистарту дип бәяләде. Мондый сүзләрне җиде кат үлчәп сөйләргә кирәген белмиме әллә? Этник чистарту дигәндә, нәрсәне күздә тота ул?



«БӨТЕНЛӘЙГӘ КИЛЕГЕЗ...»



Мәдинә АВЗАЛОВА

ЯЛГА ҖЫЕНДЫК ҖЫЕНУЫН. ӘММА КАЯ БАРАСЫБЫЗНЫ ГЫНА БЕЛМИБЕЗ ӘЛЕ. ДИҢГЕЗГӘ ИКӘНЕН ГЕНӘ БЕЛӘБЕЗ. БЕЗГӘ ДИҢГЕЗ КИРӘК.

Юлга кузгалганда, күзебез кая төшә, күңел нәрсәгә тарта – шунда, дигән идек тә, «якындагы» дигән Анапа яныннан да узып киттек. Тора-бара теләкләр дә үзгәрде. Меңләгән чакрым араны тилмерә-тилмерә үт тә, диңгездән башкасын күрмә, имеш. Юк, алай булмый. Кырым бит ул бай тарихлы як. Кем генә аяк басмаган да, кем генә яшәми хәзер анда! Атлаган саен – музей, әйләнеп баккан саен без – туристларны хәйран калдыра торган тамаша.

Беренче туктаган урыныбыз – Приморск шәһәрчеге. Хуҗабыз – моннан ике дистә чамасы еллар элек каты җир тетрәүләрдән соң Әрмәнстаннан килеп урнашкан Людвиг үзендә калырга кыстый. Без: «Судакка!» – дигәч: «Анда бик кыйммәт, калыгыз монда, пляжы да әйбәт, әйберләре дә арзан...» – ди. Алда безне озакка сузылган серпантин – бормалы юллар көтә. Кул сузымында гына урнашкан диңгездә коенып меник тә, юлыбызны дәвам итәрбез. Пляж, чыннан да, чиста, ял итүчеләр дә әллә ни күп түгел сыман. Күргәнемә сокланып, тәэсирләнеп, яр буенда йөргән арада, шушы якларның танылган шагыйрәсе, Кырым язучылары берлеге һәм Көнчыгыш Кырым рус язучылары берлеге әгъзасы, Николай Гумилев исемендәге Бөтенроссия әдәби премиясе лауреаты Галина Яковлева белән дә танышып алам. «Мы сидим, прижавшись тесно; Ты вдова, а я невеста; И поем о женской доле: Я – о счастье, ты – о боли», – дип сөйләп китә 80 яшьлек шагыйрә. Әмма аңа бирәү дә бу яшьне бирми. «Диңгез буенда үстем, диңгездән башка яши алмыйм», – диюенә карап, аның ни өчен шундый яшь күренүен чамаларга була. Тылсымлы су менә нишләтә! «Әйдәгез, минем белән Феодосиягә, – ди шагыйрә, минем журналист булуымны белеп алгач, – анда бүген Марина һәм Анастасия Цветаевага багышланган зур кичә». Без аңа рәхмәтләр әйтеп, юл уңаенда калган беренче диңгез шәһәрчеге белән саубуллашып, сәяхәтебезне дәвам итәбез.

Баш әйләндергеч бормалы юллар, уң якта – арлы-бирле чабышкан машиналарны тын гына күзәткән серле таулар, ә аста – упкын... Судакка илтә торган туры юлга чыккач, алда булачак маҗараларны күз алдына китереп, күңел киеренкелеге үзенә бер рәхәтлек, сөенеч белән алмашына. Ниһаять, ниһаять... без ике яклап кипарислар үсеп утырган гаҗәеп дөньяга килеп әләгәбез. Дөрес, бу якларга беренче генә килүем түгел. Студент елларында Ялтада берәр ай яшәгәнебез искә төшеп куя. Ул чагында көн-төн стадионда булган без – спортчыларга көньяк шәһәрнең матурлыгын карап йөрергә вакыт тими дә иде. Шулай да аның әкияти бер почмагы хәтердә калган. Анысы турында бераз соңрак...

Судакка кергәндә безне бер кеше туктата. Татарча исәнләшеп, татарча сөйләшә башлавы белән ул безне шундук үзенә каратып куя. Ничектер үз кешеңә күбрәк ышанасың бит. Үз артыннан ияртеп, Судакның тар урамнары буйлап йөртә торгач, машинасын тимер капкалы ике катлы бина янына китереп туктата. Йорт хуҗасы да – Кырым татары. Риза әфәнде Ниметуллаев хатыны Зәмирә белән капка төбенә үк чыгып, якын туганнарын көткәндәй каршы ала.

Без тукталган Әхмәт хан Солтан урамында кырым татарлары яши икән. Гомумән, Судакта – кырым татарлары. Алар турында нинди генә легендалар яшәми. Нәсел тамырлары Чыңгыз хан, Алтын Урдага барып тоташа дип тә, тел, тарих һәм мәдәни яктан төрек милләтенә барып тоташа дип тә сөйлиләр. Бер урында гына утыра белми торган милләт итеп күрсәтүче мәгълүматлар да җитәрлек. Судакка да әйләнә-әйләнә кайтканнар, имеш. Аларның кайчандыр биредән куылган халык булуын да онытмыйк. Ул чакларда кайсы кая таралышкан, дөресрәге, качып киткән Кырым татарлары, вакытлар үтүгә янә үз ярларына кайтып урнаша.

Туган җирнең кадерен белү өчен еракка китеп кара икән. Без моны Татарстан читен узуга ук аңладык.

«Кайсы адәм дә әйбәт»

Без яшәгән йортка каршы үз кибете, үз пансионаты белән көн күреп ятучы Искәндәр Фафаровның әнисе Әминә ханым шулай ди. Бераз гына читкә тайпылып, тарихка кереп китүебезнең сәбәбе дә – Әминә ханым. Казан татарлары, ягъни безнең белән гәп куертуны ул мәртәбә саный. Әле татарчага, әле төрекчәгә, әле русчага күчеп, үзе әйтмешли, «бер соз белән» генә язмышын әйтеп бирә. Минем белән озаклап сөйләшергә вакыты юк аның. Ул үзе Иске Кырымда яши икән. Бирегә улы Искәндәргә булышырга килә. Әнә хәзер дә мин аны кухняга «өстәлләрне чистартырга» чыккан җирдән «тотып» алдым.

– Машалла, машалла, мин эшли торырмын, сөйләшә торырмын, – ди ул елмаеп. – Монда ничек яшибезме? Һәм ул сөйләп китә.

Язмышы, балачак һәм яшьлек еллары әлеге дә баягы Кырым тарихы белән бәйләнгән булуын шундук абайлап алам. Аның әти-әнисе дә, Кырым татарларына көн бетәч, дүрт баласы белән Таҗикстанга чыгып киткән. Шуннан – Үзбәкстанга... «Күрмәгән калмады инде, – ди Әминә ханым, күз яшьләрен сөртеп. – Аннары Азәрбайҗан кешесенә кияүгә чыктым. Искәндәремә булышам хәзер. Ул – минем бердәнберем».


Өч оныгы бар икән: икесе Симферопольдә – югары уку йортында укыйлар. Кайчандыр бухгалтер, ревизор булып эшләгән ханым сату эшенең бөтен нечкәлекләрен белә. «Шушы йортны хосусыйлаштыра алсак, җилкәдән тау төшәр иде, – ди ул уфтанып. – Улым ничә мәртәбә барды инде документларын күтәреп, борып җибәрәләр. Үзебез җиткергән йорт лабаса».

– Бар да яхшы булыр, – дим, әңгәмәдәшемне тынычландыра башлап. – Кырым хәзер Россиянеке. Ә Россиянең – үз законнары.

Әминә ханымнан чебурек рецепты

■ «Аның бернәрсәсе юк, – ди ул, кызыксына башлагач, – суга аз гына тоз, уксус белән сүндерелгән сода, бер-ике кашык каймак салып, он белән әйбәтләп басасың да, янмый торган майсыз табада ике яклап кыздырасың. Ә эченә фарш саласың. Суганны күп итеп салырга онытмагыз! Тәмле була».

Фото: автор



Җылы-чиста диңгезе, биек тау башына менеп кунаклаган ак болытлары, шау чәчәктә утырган акацияләре... һәм гасыр төзелешенә тиң Кырым күпере...

Аның куллары бер дә тик тормый. Шул арада ул: «Пешерә белсәң, бик тәмле, кунаклар ярата», – дип, үзләре милли ризык дип атаган чебурек әзерләргә керешә. Ә мин карап торам. Шул арада пешеп чыккан кайнар ризыкны Әминә ханым кулыма тоттыра. Тәмле, чыннан да тәмле. (Кайткач пешереп карадым да, камырына сөт белән көнбагыш мае кушсаң, тагын да тәмлерәк була, дигән фикергә килдем.)

Сөйләшү ахырында гел тел очында тынгысызлап торган соравымны бирәм: «Яшәүләре хәзер әйбәтме, элек яхшырак идеме?» Ул мине шундук аңлап ала. Сәясәткә артык кереп китмичә генә: «Безнең өчен кайсы адәм дә әйбәт. Сугышмасын гына...» – ди, сүзне читкә борып. Бер белмәгән кешегә күңелендәгесен ярып салу, әйтәсе сүзен курыкмыйча әйтә алу хәленә җиту өчен вакыт кирәк аларга.

«Туристлар исәбенә яшибез»

Ял иту сезоны башланып кына китте. Ә диңгез буенда күпме халык... Пляжга иртәрәк төшеп, урын алып калмасаң, эш харап. «Лежаклар» куелган урынга кертмиләр. Анда аның кешесе дә юк үзе. Бер уйласаң, дөрес түгел инде. Ял итүченең артык акчасы юк бит. Күбесе безнең шикелле үз машинасына төялеп килә. Акчасы булган кеше самолетта оча һәм Кара диңгезне түгел, Урта, Кызыл диңгезләрне сайлый. Диңгез күрәм дип, 2100 чакрым араны (әле бер якка гына) узган кеше өчен тиене дә кадерле. Бензин бу якларда кыйммәт. Бер литры кайда 47 сум, кайда 48 сум тора. Безнекеләр соңыннан исәпләп чыгардылар: бару-кайту 12-13 мең тирәсе чыга. Барыбер гаилә белән барганда, арзанга төшә инде. Ә бездә – Татарстанда аның бәясе 40 сум да 50 тиен! Татарстаннан чыгып китүгә үк сизәсең бу аерманы. Ярый, боларын һаман да шул экономия, барырга уйлаучылар өчен киңәш-фәлән дигәннән әйтүем генә.

Судак белән Ялта арасы

Тозлы диңгез суында туйганчы коенып, катамаранда йөреп кинәнгәннән, кул сузымында гына башланган текә тауларга менеп төшкәннән соң, Судакның һәм аннан 100 чакрым арада урнашкан Ялтаның истәлекле урыннары белән танышасы иттек.

Кырымның көньяк-көнчыгышына урнашкан бәләкәй генә шушы курорт шәһәрчегенә моңа кадәр дә йөзләрчә мең ял итүче килеп киткән, моннан соң да ул шулай булыр дип уйлыйм. Хәтта күбрәк тә булыр. Ни өченме?! Беренчедән, хәзер Кырым янә, бу очракта шөкер дип әйтик, кире безгә, «үз ярларына» әйләнеп кайтты. Әле күптән түгел генә диңгез аша ике ярны – ике дөньяны тоташтырган, исеме тарихларга кереп, мәңгеләшкән Кырым күпере аша чыкканда моны аеруча нык тойдым. Әйе, мондый мөмкинлекләр тудырылгач, туристлар бирегә агылып кына торыр, Кырым туристларсыз калмас, дип барган идем. Килеп күргәч, исем китте. Кая ул туристларсыз калу?! Әйтәм бит, яр буенда алма төшәр урын да юк. Кая карама – халык. Кеше әллә махсус гасыр төзелешен – шул күперне күрим дип килгән, әллә шушы оҗмахны?!

Хуҗабыз Риза әфәнде: «Судакка килгән кеше Генуя ныгытмасын күрмичә китә алмый», – дип, безгә шәһәрчек артындагы корылмаларны барып күрергә тәкъдим итә. Крепость тавында урнашкан Генуя ныгытмасына җәяүләп бара башлагач, шактый арытты. Әмма һич кенә дә үкенмәдек. Гид әйткәнчә, заманында иң бай һәм күренекле шәһәрләрдән саналган Судак та нәкъ шул вакытларда бөлгенлеккә төшә. Ә бит кайчандыр Европадан Азиягә бөек ефәк юлы нәкъ менә Судак аша узган.

Инде юлыбыз – Ялтадан көнбатышта урнашкан, бу як халкының горурлыгы булган, без кинолардан гына күреп белгән архитектура һәйкәле – Ласточкино гнездо, ягъни Карлыгач оясына... Бирегә автобуста да, автомобильләрдә дә, су юлы буйлап катерда да киләләр. Киләләр һәм... килгән саен яңадан бер ачыш ясап китәләр. Бүген ул кырымлыларның мәдәни үзәгенә әверелгән.

Дөньядагы иң борынгы шәһәрләрнең берсе Керчьта да булып кайттык. Ул моннан 2600 еллар элек салынган. Әле Мәскәү дә, Киев та, Лондон, Париж да булмаган ул чагында. Ә Керчь менә булган! Шуңа күрә бирелә төрле чорлардан калган һәйкәлләр таң калдыра.



■ Өч катлы стенадан эшләнгән Генуя крепосте хәзергәчә үзенең хәрби-тарихи кыйммәтен югалтмаган. Греклар, әрмәннәр, мөселманнар яшәгән бу ныгытма бары төрекләр басып алгач кына җимерелә башлый.

■ Якыннан карaганда Ласточкино гнездо чыннан да уч төбедәй, карлыгач оясыдай.



Моннан бик күп еллар элек минем М. С. Воронцов Сараенда булганым бар иде инде. Очсыз-кырыйсыз биләмәләрендә моңарчы күз күрмәгән агачларга сокланып, лавр яфраклы аллеяларында хозурланып йөргәндә: «Граф үз биләмәләренә гади агачлар гына утыртмаган. Үсентеләрне чит илләрдән кайтарткан хәтта», – дигән сүзләр искә төшә. Гасырлар үтәр, ә менә Воронцов Сарае калыр! Гасырларга калыр!

...Кичләрен тар урамнар, диңгез яры буендагы сәүдә базарлары гөж килә. Монда сувенирлар, җиләк-җимеш, тәм-том... Ризыклар мичтә пешә тора, эреп, авызга китә тора. Бәяләре дә бигүк кыйммәт түгел, түзәрлек. Чакрымнарга сузылып киткән базар буйлап барганда берочтан концерт та карыйсың, цирк артистларының чыгышларын да күрәсең, оркестр уйнавын да тыңлыйсың, крокодиллар зоопаркына да кереп чыгасың... Йә булмаса «Төркиядә дә мондый матурлык юк», – дип, кипарислар аллеясында хисләнеп йөрисең. Җаның ни тели, кыскасы. Кипарис дигәннән... Пансионат хуҗасы Риза Ниметуллаев безгә бу серле, биек һәм бөек агачны үстерү серләрен озаклап, тәфсилләп аңлаткан иде аңлатуын. Ул сөйләгәннәрдән шуны хәтердә калдырдым: бик мәшәкатьле эш, зур түземлек сорый икән ул агач. Башта орлыгын алып чүлмәккә утыртасы, үсентесе чыгуга ук аны питомникка илтәсе, билгеле бер вакыттан соң барып аласы да өйдә үчтекиләп үстерәсе... Аннары гына урамга күчерәсе.

– Орлыгын алып китсәм, үсәрме бездә?

– Уйлама да, – ди ул елмаеп, – үсми ул сездә. Ул бары җылы якларда гына, анда да нык һәм белеп караганда гына үсә. Шуңа йөзәр ел яши дә ул!

«Иртәгә китәсе» дигән кечтә хуҗабыз: «Әле сезнең чын пылау ашаганыгыз юктыр», – дип, тел йотарлык пылау пешереп ашатты. Виноград шәрабы сатучы

«Бөтенләйгә килегез!» Судакта яшәүче Кырым татарлары безне шулай дип озатып калдылар.

егетебез Рамазан: «Пылауны виноград суы белән юып төшерәләр бездә», – дип, күчтәнәчен кыстырып килеп җитте. Кем әйтә Кырым татарлары бөтенләй башка, икенче ул, дип. Алар да безнең кебек: кунакчыл да, гади дә, шул ук вакытта ничектер серле дә булып кала беләләр. Аннары... шулкадәр якын да. Иртән юлга кузгалганда, алар безне кул изәп: «Тагын килегез, бөтенләйгә килегез!» – дип озатып калдылар. Киләбез, киләбез! Тик бөтенләйгә үк дип ышандырмыйбыз. Үзебезнең туган җир бик әйбәт, үзебезнең туган җир кадерле. Ә менә киләсе елга ял итәргә, янә бер шушы гүзәллеккә чумарга әзер без. Бик теләп һәм рәхәтләнеп...

Киңәш

■ Юл буйлап тезелеп киткән кафе-ашханәләрдә ашап, теләгәндә, душта коенып чыгуы да проблема түгел.

■ Өч кешелек бүлмәгә тәүлегенә 1500 сум акча алдылар. Шулай итеп, тугыз көн һәм сигез төнгә без 12 мең сум акча түләдек.

■ Ашханәдә бәяләр кыйммәт дип әйтмәс идем. Көненә, кеше башыннан исәпләгәндә, иң күбе 400 сум акча тотылды.

■ «Лежаклар»га килгәндә, бәяләр төрлечә. Пляжына карап, күрәсең. Кайда ул көненә – 200 сум, кайда сәгатенә – 100 сум.

■ Безне: «Кырым күперендә чират торачаксыз, «пробка» анда», – дип куркытканнар иде. Юлда барганда да, күпер чыкканда да бернинди этеш-төртеш булмады. ЮХИДИ хезмәткәрләре туристларны юккабарга туктатмыйлар. Безне, гомумән дә, туктатмадылар. Юлда тыныч булды, шөкер, бернинди маҗараларга очрамадык.

16+

ДӨНЬЯ – ХАТЫН-КЫЗ КУЛЫНДА



Шамил САДЫЙКОВ, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының генераль директоры;
гаилә стажы – 19 ел;
балалары – Данил (18 яшь), Зөһрә (13 яшь), Ясмин (3 яшь).

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Хатын-кыз бөтенләе белән төрле сигналлардан тора. Йөрү рәвеше, киенү стиле, кигән киеменең төсе, карашы, тавыш тембры, чәче... Болар барысы да аның эчке дөньясының чагылышы. Хатын-кыз серен яшерә белми бит ул: эчендәге тышында аның. Иң көчле инструмент, әлбәттә, караш: анда барысы да язылган. Бер нәрсә сөйләп, ә аның мәгънәсе чынлыкта бөтенләй икенче булу хатын-кызга шундый хас бит. Киная белән, әйтеп бетермичә, ярты юлда өзеп... Шушы сигналлар күп булу, аларның яшеренгәнлеге серлелек хисен барлыкка китерә һәм кызыксындыру тудыра... Мин бәхетле ир кеше. Юлымда кызык, мәхәббәтле хатын-кызлар очрады. Беренчедән, әнием. Безнең гаиләнең генералы! Минем тормышымда ул зур роль уйнады. Тормыш иптәше итеп Ләйсәнне сайлавым – икенче бәхетем. Үзем: «Мин аны сайладым», – дип уйлыйм инде... Ике кызым бар. Ике мәхәббәтем! Аннан – хатынымның әнисе. Безнең гаиләнең тотрыклылыгы өчен ул шактый өлеш кертә: нәрсә генә булса да, гел минем яклы.

2 Нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Алдауны. Ялган икәнен белмичә көтү, юкка өметләнүдән дә куркыныч нәрсә юк дөньяда. Ә хыянәт... Аның өчен исә хатын-кыз түгел, беренче чиратта ир-ат гаепле. Ул гөнаһ шуңа да уртага бүленә: димәк, ир-ат аның күңелен бөтенләе белән биләп ала алмаган – бушлык калган.

3 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Мәхәббәт ул этәргеч, кузгалып китү моменты гына. Мәрхүм әбием: «Мәхәббәт ул, улым, өч көнлек», – дия иде. Ә аннары тормыш башлана... Гаиләләрнең күпчелеге шуңа таркала да, чөнки бер мәхәббәт белән генә ерак китеп булмый. Кайсыдыр бер мизгелдә арада дуслык та урнашырга тиеш.

Хатын белән сөйләшергә сүз гел бар безнең. Икебез ике өлкәдә эшлибез – бүлешер мәгълүмат шактый җыела. Ә сөйләми, эчеңне бушатмый торырга ярамый. Сөйләү – тыңлаучы өчен түгел, сөйләүче өчен кирәк. Хатын белән дус булу шуңа яхшы да: ул син сөйләгәннәрне читкә чыгармый. Бу мәсьәләдә минем өчен хатын-кыз идеалы – әни. Буйга да бәләкәй генә, әмма барыбызны да ул этеп бара – безнең җилкәннәргә һава тутыра. Әти белән яңа гына алтын туйларын үткәрделәр. Өч ир бала үстерделәр. Әтине әни ничек илһамландырып торганы, аңа нинди якын дус булганы – барысы да күз алдында. Әти – шагыйрь безнең һәм аның шигырьләренең яртысы әнигә багышланган.

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Әни Актаныштан безнең. Шуңа күрә кечкенәдән бу төбәккә, аның табигатенә карата күңелдә аерым мәхәббәт яши. Ул як хатын-кызларына да үзгә мөнәсәбәт бездә. Юкка гына минем дә, абыйның да хатыннар Актаныштан түгел инде.

Студент чак. Актанышка бабайларга кунакка кайттым. Һәм... урамда Аны очраттым. Беренче күрүдән гашыйк булдым! Шундый ошады! Кояш кебек елмая. Чибәр! Энергетикасы якты! Сөйләшә башлап, 15 минут узуга мин аңа тәкъдим ясадым: «Миңа кияүгә чыгып, Казанга китәсеңме?» – дидем. Уен-көлке белән әйтсәм дә, әлеге сүзләрдә хаклык бар иде. Бу вакытта инде аякта нык басып тора идем. II курста ук «Эфир»да журналист булып эшли башладым, арендага алган фатирым, йөрергә машинам, кесәмдә акчам бар. Мин тәкъдим иттем, ул уйнап-шаярып риза булды. Барысы да үзеннән-үзе килеп чыкты. Мин аның Шәвәлиевлар кызы икәнен аңлап өлгергән идем инде. Безнең бабайлар исә гомерлек гаилә дуслары. Бабай гел алар хакында: «Дәрәҗәле нәсел», – дия иде, көчле, гыйлемле, дип, үрнәк итеп күрсәтте. Без ул гаиләгә хөрмәт белән үстек. Ләйсәнгә дә мин ят түгел – Имамовларның оныгы бит... (Сайлаган кешеңнең җиде буынын белергә кирәк, дип юкка әйтмиләр!) Икенче көнне Казанга киттем. Аны очраткач кабынган хис атна буе күңелемнән китмәде. Укытучы булып эшләгәнен белгән идем: ике көннән мәктәпкә шалтыратып аны таптым. Кесә телефоннары юк чак әле, ә мәктәп телефонын табу авырмыни – мин бит журналист. Директор аша чакыртып китердем. «Ләйсән, бу Ша-

мил. Исеңдәме танышуыбыз? Минем теге ниятем исән. Син бит ризадыр?» – дидем. «Риза», – дип җавап бирде ул. Бер атнадан соң без аларга кыз сорарга килдек. Икебезгә дә 20 яшь иде.

5 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр. Шулаймы?

– Мин үзем әнигә мәхәббәт белән яшәгән кеше, әмма хатынны аңа охшатып алмадым. Генерал хатын белән яши алмас идем, чөнки үзем генерал. Хатыным муенымда түгел, һәрвакыт кочагымда минем... Әни белән уртак тел таптылар алар, әлбәттә. Тормышта бу мөһим нәрсә, ләкин төп мәсьәлә түгел. Ул минем белән яши, уртак телне дә минем белән табарга тиеш. Ә хатын белән әнинең рольләрен дөрес итеп билгеләү – анысы инде ир кешедән тора.

6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Бер яктан бу аңлашыла, физик хезмәткә хәзер ихтирам аз, шуңа да ир кешенең роле көннән-көн кими. Икенче яктан, актив тормыш позициясе алып баручы хатын-кызлар арта. Безнең агентлыкта да төп рольләрдә күбрәк хатын-кызлар, журналистларның да күпчелеге – алар. Хатын-кыз психологик яктан тотрыклырак, алар сизгер, зирәк. Шуңа күрә хатын-кызның акча табуда гаиләдә беренче урынга чыгу очраклары күп тә. Үземне алганда, минем өчен авыр мәсьәлә бу. Күз алдына китерү дә кыен.... Ир-ат өчен җиңел язмыш түгелдер. Өйләнгәнсең икән, ат булып җигелергә, арбаны тартырга тиешсең. Акча мәсьәләсендә генә түгел, интеллектуаль, эмоциональ мәгънәдә дә.

7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Беренче адымны һәрвакыт хатын-кыз ясый. Ул беренче булып сигнал бирсә, ир-ат аның артыннан китәчәк, шул сигналны сизмәсә, ир-ат аңа якын килмәячәк. Ә сигнал төрлечә бирелә: кигән кием, күз карашы, сөйләмдәге интонацияләр белән. Әгәр ул сигналларны җибәрми, берәүне дә үзенә якын китерми икән, бу мәхәббәт хикәясе башланмаган килеш кала.

8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Ир-ат белән хатын-кызны, образлы итеп, чәчәк белән бал корты дип әйтер идем. Чәчәкнең бурычы – бал кортын үзенә җәлеп итеп, җимеш үстерү. Ә бал кортына бал кирәк: ул чәчәктән чәчәккә бик озак очарга мөмкин... Хатын-кыз өчен ир-ат – аның башындагы хыялларын тормышка ашыручы бер инструмент, шуңа күрә ул чәчәктән чәчәккә кунып йөрергә түгел, ә аныкы гына булырга тиеш. Хатын-кыз үзенә пар эзләгәндә барысын да уйлый: балаларны үстерешә алырмы, тугры булырмы, соңгы көнгәчә янымда калырмы... Бу хакта мин соңгы вакытта күп уйланам, чөнки олы кызым инде буй җитеп килә. Ул очрашачак егетләр нинди булырга тиеш, дип, эти кеше буларак фикер йөртәм. Хәзерге җәмгыятьтә, егетләргә караганда, кызларга ике тапкыр авыррак. Кайсы яктан алсаң да! Аларга матур, чибәр булырга, үзләрен һәрвакыт формада тотарга, матур киенергә кирәк. Физиологик яктан да авыррак – бала табасылары бар. Өчне түгел, бер бала тапса да ир-ат акылдан шашарга мөмкин бит!

9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Миңа инде 40 яшь тулды. Атылган патрон, җырланган җыр мин хәзер. Актив эзләү чорыннан күптән киттем. Алар белән минем арада дусларча мөнәсәбәт кенә була ала. Иң якын хезмәттәшләрем дә, дусларым да – хатын-кызлар. Алар белән уртак тел таба белүне бәхеткә саныйм.

Җитәкче буларак, хатын-кыз хезмәткәрләрем алдында җаваплылык хисе тоям: эшкә алганмын икән, әйткән сүземдә торырга, эш урынында мөмкинлекләр тудырырга тиешмен. Каты бәрелмәскә, кимсетмәскә, матур сүзне кызганмаска, эшкә илһамландыра белергә... Җитәкче булсаң да, ир кеше булып калырга кирәк.

10 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Яшьлектә хатын белән ярышырга тырышкан, киреләнгән чаклар да булгандыр. Хәзер, нәрсә генә булса да, кулымны күтәрәм дә: «Мин гаепле», – дим. Һәм бу мине соңгы вакытта бик коткара. Гаилә диген олы юлга чыгуга, без, ир-атлар, бөтен хатаны үз өстебезгә алырга тиешбез. Гаепле булмасак та... Чын ир-егет шулай эшли. Яши-яши шундый фикергә килдем әле.

11 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Тормыш бит – төрле хәл булырга мөмкин. Эштән бик алҗып кайтса, Ләйсән миңа алдан хәбәр итә: «Ашарга пешермәгән әле», – ди. Авылдан яшьли чыгып китеп, тулай торакта яшәдем – ашарга үзем дә пешерә беләм, алдыма китереп куйганнарын көтеп утыручылардан түгел. Икенчедән, пиццага да заказ бирә алам. Каядыр барып та ашап кайта алабыз – бүген андый мөмкинлекләр күп. Соңгы елда, әнисе өлгермәгәндә, ашарга кызым әзерли. Монысы – горурлык! Ул пешергән – ике тапкыр тәмлерәк!

Шөкер, хатыныма яхшы әни тәрбиясе эләккән. Бәлеше, өчпочмагы телне йотарлык. Ипине үзе сала. Кирәк булса, чәкчәк тә ясый. Ул яктан мин бәхетле... Ләкин хатын-кызны ашарга пешерүче итеп кенә кабул итәргә ярамый.

12 Хатын-кызлар соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

– Ир кешегә җиңел: чалбар, күлмәк кия дә, чыгып китә, ә хатын-кыз гел матур күренергә тиеш шул – ул һәр-нәрсәне уйлап сайлый. Яулыгын, күлмәген... Ләйсән күптән яулык бәйли, ул дини гаиләдә үскән. Без намазны бер вакытта укый башладык. Аның диндә булуы, икебез бер мохиттә яшәү, шул мохиткә балаларны тартып кертүебез – минем өчен зур бәхет. Ире дингә кереп, хатыны килмәсә, бу гаиләдә проблемага әйләнергә, каршылыклар туарга, картая башлагач, аралар бөтенләй бозылырга да мөмкин.

Әйе, элек хатын соңга кала иде, хәзер менә олы кызым үсеп җитте. Бергә кая гына барырга җыенсак та, Зөһрәне көтәбез хәзер. Кызлар киенергә ярата! Тик бу минем өчен шатлык кына. Аның әзер булып килеп чыгуын һәрвакыт кызыксынып көтәм: бу юлы нинди кием сайлады икән? Тормышта һәр мизгелнең үз шатлыгы бар...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

ЯШӘЕШ

БАЛАГА УЗА АЛМАУ – ХӨКЕМ КАРАРЫ ТҮГЕЛ



Зарыгып көтеп-көтеп тә, ни өчен кайбер хатын-кызлар балага уза алмый? Сәбәпләрен каян эзләргә? Гаеп хатын-кызда гынамы? Ничек дәваланырга? Болар хакында югары категорияле акушер-гинеколог, репродуктолог Елена КАПИЦКАЯ сөйли.

Өйдә бала-чага чыр-чуы, әтисенең йә әнисенең муенына сарылган нәни куллар, шау-шулы көннән соң арып, бала караватында мес-мес килеп йоклаучы сабый – һәркемнең хыялыдыр бу.

Ләкин соңгы елларда табиблар кайбер гаиләле парларның хыялларын чәлпәрәмә китерә торган диагноз куя – балага узмау. Мондый хәбәр аяз көнне яшен сугуга тиң.

Бу проблеманы булдырмый калып буламы соң? Дәвалану никадәр иртә башланса, савыгуга өмет тә зуррак.

Баласызлыкны дәвалау – күп тырышлык сорый торган һәм озакка сузылган процесс ул. Шуңа күрә әти-әниләр балаларының җенес органнары ялкынсынуына китерә торган сәбәпләрне вакытында ачыклап, тиз арада дәвалауны кайгыртырга тиеш. Алар кайчак төрле инфекцион авырулар фонында ачыла. Шулай ук үсмер чакта профилактика чараларын күрү зарур: малайларда гениталий һәм кече оча сөяге органнары ялкынсынуын (аднексит, цистит, уретрит), шулай ук кызларда күзәтелгән менструаль тайпылышларны вакытында дәвалау бик мөһим. Табибларга даими күренеп торуны кагыйдә итеп алу сорала. Ир балалар үстерүче әниләргә киңәш: подгузникларны артык еш кулланмагыз! Ир-атларның малай чакта күкәй капчыгы гел җылыда торуы да балага уза алмауга бер сәбәп булып тора.

Бүген матбугат чаралары, интернет бертуктаусыз сәламәт яшәү рәвешен пропагандалый. Чыннан да, саф һава, дөрес туклану, физик активлык төрле авыруларны булдырмый кала ала. Балага уза алмаудан да коткарырга мөмкин. Шуңа күрә табиб киңәшләренә игътибарлы булу сорала.

Балага уза алмауны кисәтү һәм дәвалау – репродуктолог-табибларның төп бурычы. Иртә җенси якынлык, партнерларны еш алыштыру күңелсез нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Бу проблема табиб кабинетында хәл ителмәсен өчен, гаиләдә, мәктәптә алдан ук аңлату эшләре алып барылырга тиеш. Иртә җенси якынлык та балага уза алмауга китерә. Кыз бала җенси яктан өлгерүгә үк якынлыкка керә ала дигән фикер миф ул. Хатын-кыз организмы 17-20 яшьләрдә генә йөклелеккә әзер була. Иртә җенси якынлыкка керү хатын-кызның репродуктив функциясен җимерә, егетләрдә исә иртә импотенция килеп чыгуга китерә. Абортларның, җенси юл белән күчкән авыруларның зыянлы һәм куркыныч икәне берәүгә дә сер түгел. Нәтиҗәләре төрлечә:

Баласызлыкның сәбәпләре

- Репродуктив һәм бәвел бүлеп чыгару системасы органнарындагы йогышлы-ялкынсынулы чирләр.
- Җенес органы үсешендә тумыштан булган кимчелекләр: күкәйнең күкәй капчыгына төшеп бетмәве (крипторхизм), бер күкәйнең тумыштан булмавы (монорхизм), бәвел бүлеп чыгару каналының җенес әгъзасында дөрес урнашмавы (гипоспадия), бәвел бүлеп чыгару каналының алгы стенкасы өлешчә яки тулаем ярылган булу (эписпадия) һәм башкалар.
- Варикоцеле (орлык чыгару юлы кан тамырларының икенчел дәрәҗәдән зуррак киңәюе).
- Системалы авырулар (бавыр циррозы, туберкулез, диабет, хроник бөер авыруы).
- Касык бүсере, уретраның тараюы, күкәйгә сары су җыелу, бәвел куыгы авырулары, простата шешләренә ясалган операцияләр.
- Интим характердагы проблемалар.
- Хромосома патологиясе. Нәселдән килә торган бу тайпылыш хромосомалар саны яки төзелеше үзгәргән булудан гыйбарәт.
- Исерткеч эчемлекләр һәм никотин белән мавыгу, организмның чамадан тыш җылынуы, травмалар, радиация нурланышы, сәнәгать һәм көнкүреш агулары белән эш итү, ир-ат җенес гормоннары һәм гормоннар нигезендә ясалган ялкынсынуны баса торган дарулар кабул итүләр дә балага узуны катлауландырырга мөмкин.

хатын-кыз организмының функцияләре бозыла, ир-егетләрдә импотентлык күзәтелә.

Безнең заманда үзеңне бердәнбер ир-атка – булачак ireңә саклау әхлак кагыйдәсе санала иде. Халкы сәламәтлеге турында кайгырткан теләсә кайсы дәүләт әхлак турында кайгыртачак, Америкадагы сыман тыелуны пропагандалаячак. Анда 1996 елдан ук инде яшьләр өчен «Тыелуга өйрәтү» программасы кертелгән. Бу программага 100 миллион долларлар тотыла.

Табибка даими күренеп тору, аның киңәшләрен үтәү балага узалмауга каршы иң яхшы профилактика санала. Күп хатын-кызлар гинекологка йөрергә яратмый (оялалар яки дискомфорт кичерәләр). Яшькә дә, кәефкә дә карап тормыйча, елына ике мәртәбә гинекологка күренергә кирәк.

Медицина соңгы елларда шактый алга китте, шулай да хатын-кызлар тормышында төрле хәлләр чыгып тора. Барлык күрсәткечләр яхшы булып та, балага уза алмасагыз, һәм табиблар аптырау хәлендә калса, психологик ысул белән дәваланып карагыз.

Хатын-кызларда балага уза алмауны беренчел һәм икенчел төрләргә аерып карыйлар: бер тапкыр да йөккә калмаган хатын-кызда – беренчел, кайчандыр бала табып та, инде балага уза алмау икенчел төре була.

Хатын-кызларның балага уза алмавының төп сәбәпләре

1 **ТӨРЛЕ ИНФЕКЦИЯЛӘР** (аднексит, хламидиоз, җенес органнары туберкулезы, гонорея һәм башкалар), операцияләр (сукыр эчәк, күкәйлек кистасы өзелү, корсак куышлыгы эндометриозы һәм башкалар) кичергәннән соң, күкәй күзәнәкләренең аналык көпшәләрендә йөреше тоткарлану.

2 **ОВУЛЯЦИЯ, ЯГЪНИ КҮКӘЙ КҮЗӘНӘКНЕҢ ӨЛГЕРҮ ҺӘМ КҮКӘЙЛЕКТӘН ЧЫГУ ПРОЦЕССЫ БОЗЫЛУ.** Мондый хәл берничә очракта күзәтелергә мөмкин. Беренчесе – эндокрин системасы авырулары. Эндокрин системасындагы тайпылышлар үз чиратында овуляция булмауга китерә. Икенче очрак – поликистоз күкәйлек синдромы (киста рәвешендәге яман булмаган шешләр барлыкка килү). Артык авырлык җыю яки, киресенчә, гәүдә авырлыгы тиешле күләмгә җитмәү шулай ук овуляцияне тоткарлый. Гормональ дисбаланс килеп чыкмаслык булсын. Озак вакыт җитди рәвештә физик эшчәнлек белән шөгыльләнү дә йогынты ясый.

3 **ЭНДОМЕТРИОЗ.** Бу гинекологик чир иммун һәм гормон системаларында тайпылышлар китереп чыгара, алар исә һаман да шул овуляция тоткарлануга, шулай ук аналык көпшәләренең элпә белән капланып тыгызлануына сәбәпче булырга мөмкин.

4 **АНАЛЫК ҮСЕШЕНДӘ ТУМЫШТАН БУЛГАН КИМЧЕЛЕКЛӘР.**

5 **ГИПЕРПРОЛАКТИНЕМИЯ.** Бу авыру хатын-кыз организмында гипофиз гормоны – пролактинның артуына китерә, ул исә җенес гормоннарына комачаулый.

6 **ИММУНОЛОГИК КЫСЫРЛЫК.** Кайбер хатын-кызларның организмы үзгә төр аксым – антиспермаль антитәнчекләр эшләп чыгара. Ул антитәнчекләр сперматозоидларны тоткарлый, аларга күкәй күзәнәк белән очрашырга мөмкинлек бирми. Ләкин мондый очракта хатын-кызның бер ир-аттан балага уза алмаса да, икенче ирдән балага узу ихтималы бар. Бу тайпылыш һаман да ахыргача өйрәнелеп бетмәгән әле.

7 **КҮКӘЙЛЕКЛӘРНЕҢ ВАКЫТЫННАН АЛДА ЯБЫГУЫ.** Ир-ат сәламәтлеге аркасында балага уза алмау очраклары да арткannan-арта бара.

Ир-атның баласызлыгын да берничә төргә аерып карыйлар

1 **ОЛИГОЗОСПЕРМИЯ** – сперматозоидларның аз булуы.

2 **АЗООСПЕРМИЯ** – сперматозоидларның бик аз күләмдә булуы.

3 **НЕКРОЗООСПЕРМИЯ** – хәрәкәтчән сперматозоидларның бөтенләй булмавы.

4 **ТЕРАТОЗООСПЕРМИЯ** – нормаль төзелешле сперматозоидларның бик аз күләмдә булуы.

Балага уза алмауның төгәл сәбәбен ачыклау һәм тиешле дәвалау терапиясе алу өчен табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Нинди генә диагноз куелса да, өметне өзәргә кирәкми. Бүгенге медицина чын-чынлап могҗиза тудырырга сәләтле. ЭКО ысулы – әнә шул могҗизалы ысулларның берсе. ЭКО ярдәмендә бүген бик күп парлар әти-әни булу бәхетен татый, тормышларының яме булган сабыйларын үстерә.

Лицензия ЛО-16-01-002821 от 01.08.13г.
Индивидуальный подход, благоприятная атмосфера - всё к Вашим услугам!
- ЭФФЕКТИВНОСТЬ ЭКО ПО ПРОГРАММЕ ОМС за 2017г. 60%
- УЗИ, ВСЕ ВИДЫ ЛАБОРАТОРНОЙ ДИАГНОСТИКИ
- У НАС ВЫ МОЖЕТЕ ПОЛУЧИТЬ НАПРАВЛЕНИЕ НА БЕСПЛАТНОЕ* ЭКО (ПО ОМС)
*подробности по телефону
276-95-35
ул. ЗУР УРАМ, д.33
КЛИНИКА СЕМЕЙНОЙ МЕДИЦИНЫ
www.ksm-eko.ru
РЕКЛАМА

PRESSA

ТӨЗ УТЫР, МАТУР УТЫР!



Сколиоз – балаларда иң еш очрый торган чирләрнең берсе. Сәбәбе нәрсә моның – хәрәкәт җитмәүме, дөрес тукланмаумы? Аны булдырмый калу юллары бармы? Сорауларыбызга җавап эзләп, медицина фәннәре докторы, Казан федераль университетының хирургия кафедрасы профессоры, Республика балалар клиник хастаханәсенең амбулатор травматология һәм ортопедия үзәге җитәкчесе, табиб-ортопед Илья РЯБЧИКОВка мөрәҗәгать иттек.

Сколиоз – умыртка баганасының бер якка таба кәкрәюе. Бу диагнозны 6 яшьтән алып 15 яшькә кадәрге балаларга куялар. Кызларда ул алты тапкырга күбрәк күзәтелә.

Бу чир нилектән килеп чыга соң? Сабый балаларның умыртка баганасы кимерчәкләрдән генә тора. Кимерчәкләрнең сөяккә әверелү процессы 17 яшьләренә кадәр бара. Шул чорда сколиоз чире башлану ихтималы бар. Кайбер балада бу чир тумыштан да күзәтелә. Сәбәпләре күп: умыртка сөягенең бергә кушылып үсүе, җитлегеп бетмәгән өстәмә умыртка сөякләре булу, кабыргаларның бергә берегүе... Тумыштан булган сколиоз балага бер яшь тулганчы ук үзен сиздерә.

Сколиозның берничә формасы була. Иң еш очрый торганы – идиопатик сколиоз. Бала үскән чорда умыртка баганасы дөрес формалашмый. Чирнең бу төре 10 яшьтән соң барлыкка килә.

Баласында сколиоз башлануын әти-әни үзе дә ачыклый ала. Аның иң беренче билгеләре: туры басканда баланың бер иңбашы астарак була. Арттан караганда, калак сөякләре дә бер яссылыкта түгел. Алга иелгәндә, умыртка баганасының туры булмавы аермачык күренә. Әгәр дә шушы билгеләрнең берәрсе булса, кичекмәстән баланы табиб-ортопедка күрсәтергә кирәк.

Дәваланмаган очракта, умыртка кәкрәю күңелсез нәтиҗәләргә китереп, сәламәтлеккә җитди зыян сала. Гәүдәнең торышы үзгәрү, бер якка янтаю, күкрәк читлеге авышу монысы әле бер хәл, бу бит эчке органнарның да үсешенә һәм аларның үз функцияләрен үтәвенә комачаулый.

Сколиозны булдырмый калу аны дәвалауга караганда күпкә җиңелрәк. Шуңа да әти-әниләр баланың физик үсешенә игътибар итәргә тиеш. Иң элек – дөрес туклану. Икенчесе – баланың йоклый торган урыны артык йомшак булмасын. Мөмкинлек булса, ортопедик матрас алыгыз.

Бала ничек йөри, ничек утыра – аны да күз уңыннан ычкындырырга ярамый. Алга сөрлегеп, башын иеп йөрмиме, бер якка янтаеп утырмыймы?

Тиздән яңа уку елына әзерлек чоры башлана. Умырткасы ныгып җитмәгән балаларга иңбашына элеп яки бер кулга гына тотып йөри торган портфельләр алмаска кирәк. Көн дә мәктәпкә йөртү өчен ортопедик рюкзак кулайрак. Шулай ук дәрес әзерли торган урынын да дөрес итеп көйләү әһәмиятле. Өстәл белән урындык баланың буена туры килергә тиеш.

Баланың сәламәтлеге өчен иң яхшы спорт төре – йөзү. Аны кече яшьтән үк йөзәргә өйрәтегез һәм бассейнга йөрү мөмкинлеген тудырырга тырышыгыз. Аның сәламәт, матур булып үсүе өчен бу бик мөһим.

Сколиоз диагнозы балага инде куелган икән, әти-әнинең бурычы – тәҗрибәле табибка күренү һәм аның белән берлектә дәва ысулларын сайлау, ул кушканны үтәү. Сколиозны дәвалау һәрвакыт команда эше. Ул командада – бала, әти-әни һәм табиб. Бу – озакка сузыла торган процесс. Әти-әнигә бу очракта үзләренә дә нык булырга, балага кыюлык һәм сабырлык үрнәге күрсәтергә туры киләчәк.

Белешмә

Россия дәүләт санитария баш табибының 2010 елның 29 декабрендә биргән күрсәтмәсе нигезендә балалар өчен көндәлек кулланылучы дәреслекләр һәм әсбаплар комплекты түбәндәге авырлыктан артмаска тиеш:
- 1-2 нче сыйныф укучылары өчен – 1,5 кг;
- 3-4 нче сыйныфта – 2 кг;
- 5-6 нчы сыйныфларда – 2,5 кг;
- 7-8 нче сыйныфларда – 3,5 кг;
- 9-11 нче сыйныфларда – 4 кг.

Киңәш

Өстәл-урындыкны буйга карап сайлыйбыз:
- буй 116–127 см булса, өстәл биеклеге – 53 см, урындыкныкы – 35 см.
- 128–136 см буйлы бала өчен өстәл – 56 см, урындык – 37 см.
- 137–144 см буйга өстәл биеклеге – 59 см, урындыкныкы – 40 см.
- 145–153 см буйлы баланың өстәле – 63 см, урындыгы – 43 см.
- өстәл өсте баланың диафрагмасы белән бер яссылыкта булсын.
- терсәкләре өстәлдә ятарга тиеш.
- өстәлнең җитәрлек киң булуы һәм авышлыгын үзгәртү мөмкинлеге дә мөһим. Уку өчен өстәл өслегенең почмагы 30 градус, ә язу өчен 7–12 градус булса яхшы. Ел да яңа җиһаз алмас өчен, бала белән бергә «үсә» торган өстәл-урындыкларга игътибар итегез.

ЙӨРӘК БЛОКАДАСЫ



Йөрәк – организмыбызның беркайчан да ял итми эшләп торучы органы ул. Туганнан алып (хәер, баланың йөрәге туганчы ук тибә башлый) соңгы сулышыбызгача эштә. Сәламәт кешенең йөрәге тыныч вакытта минутына 60-80 тибеш ясарга тиеш. Кайчак йөрәкнең ритмы бозылып та киткәли. Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсенең кардиология бүлеге мөдире, Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенең штаттан тыш баш кардиологы, доцент Зөлфия КИМ йөрәк эшчәнлеге һәм атрио-вентрикуляр блокада хакында сөйли.

Йөрәк насос кебек эшли – әле кыскарып, әле бушанып, канны башка әгъзаларга куа. Йөрәк мускулларының импульсын синуслы төен – йөрәкнең үткәрү системасының башлангыч өлеше тәэмин итә. Аннан килгән импульслар үткәрү системасы буйлап берничә төен аша уза һәм йөрәкнең эшче күзәнәкләренә – кардиомиоцитларга тапшырыла.

Үткәрү системасының кайсыдыр бер өлешендә әлеге импульслар акрынаерга яки бөтенләй тоткарланырга мөмкин. Блокада дип шушыңа әйтәләр. Кайсы өлештә тоткарланса да, алар бөтенләй үк тукталмый. Синуслы төен импульслар юллый алмаса, бу вазыйфаны аннан астарак торган атрио-вентрикуляр төен үз өстенә ала.

Бүген без йөрәкнең атрио-вентрикуляр блокадасы турында сөйләшәбез. Бу очракта синуслы төеннән килгән импульсларны үткәрү системасының икенче өлеше булган нәкъ менә шушы төен тоткарлый.

киңәш ителми

- яңа пешкән ипи, маилы камыр ашлары;
- каймак, майлы сөт, сыр;
- каз, үрдәк, дуңгыз ите, тозлы балык, тозлы уылдык;
- йомырка тәбәсе һәм каты пешкән йомырка;
- гөмбә, борчак, суган, кузгалак, шалкан, ачы торма, шпинат, тозлаган яшелчәләр, ак кәбестә;
- ит, балык, гөмбә шулпалары;
- кыздырылган ризыклар;
- шоколад һәм тортлар;
- какао, кофе.

Блокада функциональ һәм органик була. Органик блокаданың сәбәбе йөрәкнең ревматоидлы чире, кардиосклероз, йөрәк кимчелеге, кардиомиопатия, миокардит булырга мөмкин.

Иң еш очрый торган сәбәп – вируслы һәм аутоиммун чирләр, аллергия яки бактерияләр аркасында йөрәк күзәнәкләренең ялкынсынуы.

Кискен инфаркт кичергәннән соң да атрио-вентикуляр блокада күзәтелгән очраклар бар.

Бөерләрнең сәламәт булмавы, шул сәбәпле организмда күп күләмдә калий туплануы да атрио-вентрикуляр блокада китереп чыгара ала.

Пульсны киметүче препаратларны дөрес кулланмау да тәэсир итә. Бик сирәк кенә очракларда блокада тумыштан да була.

Атрио-вентрикуляр блокада өч дәрәҗәдә уза.

1 нче дәрәҗәдә йөрәкнең ритмы бозылмый, импульслар чак кына акрыная. Аны кеше үзе сизми, фәкать ЭКГ тикшеренүе генә күрсәтә. Беренче дәрәҗәдәге блокада махсус дәвалуны таләп итми, ләкин шушыңа китергән башка чирләрне ачыкларга һәм дәваларга кирәк була.

2 нче дәрәҗә – импульсларның бер яки берничә өлеше тапшырыла, бер өлеше – юк. Кеше баш әйләнүеннән, йөрәк эшчәнлегеннән зарлана.

3 нче дәрәҗәдәге атрио-вентрикуляр блокада – иң куркынычы. Бу очракта импульслар йөрәк карынчыгына тапшырылмый. Импульслар ясау вазыйфасын сафтан чыккан төеннән астарак урнашканы үзенә ала. Импульс чыганагы башлангыч төеннән никадәр түбәнрәк урнашса, йөрәкнең ритмы да шулкадәр сүлпәнрәк. Тулы атрио-вентрикуляр блокада вакытында йөрәк тибеше минутына кырык яки аннан да кимрәк була. Йөрәк начар эшләгәнлектән, организмны кислород белән тиешенчә тәэмин итә алмый. Кислород кытлыгына иң сизгер орган – баш мие. Йөрәк пульсы минутына 40 булганда – баш әйләнә. Аннан да кимрәк булса, кеше аңын югалта. Бу очракта инде электрокардиостимулятор кирәк була.

киңәш ителә

- бер-ике көнлек ак ипи, диетик печенье;
- майсыз сөт, оетылган сөт ризыклары;
- майсыз ит һәм майсыз балык;
- көненә берәр чиле-пешле йомырка;
- кыяр-помидор, пешкән кишер һәм яшь бәрәңге;
- карбыз-кавыннан кала, башка барлык җиләк-җимеш (карбыз-кавынны чама белән);
- яшелчәле һәм ярмалы ашлар;
- пешкән кабак, ташкабак, брокколи һәм кольраби;
- кесәлләр, мусслар, майлы булмаган сөтле кремнар. Кайнатмалар белән бик мавыкмаска;
- гөлҗимеш төнәтмәсе, җимеш сулары.

Йөрәкнең дөрес эшчәнлеге өчен сәламәт яшәү рәвешен саклау мөһим. Тәмәке тартуны ташларга һәм физик эш белән шөгыльләнергә кирәк. Ким дигәндә 40 минут җәяү йөрү дә файдалы. Күбрәк хәрәкәтләнегез. Бу кагыйдәләрне һәркем белә, ләкин минем белән болай булмас әле, дип, «тылсымлы төймә» кабып кына чирләрдән арынасы килә. Профилактика шул «тылсымлы төймә» инде ул.

PRESSA

ТУТЫРГАН ТАВЫК

Резеда ХӨСӘЕНОВА исеме – татар дөньясында таныш исем. Аның пешергән ашсуларын Америкада, Болгария, Австралия, Чехия, Төркиядә яшәүчеләрнең дә авыз иткәне, ул уздырган осталык дәресләрендә катнашканы бар. Халыкара Татар ашлары һәм мәдәнияте ассоциациясен җитәкләүче Резеда ханым – атаклы аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановның шәкерте, бары тик ул гына белгән серләрне, нечкәлекләрне остазның үзеннән өйрәнеп калган кулинар.
Без аның «Татарстан – Яңа гасыр» телеканалында барган «Тәмле булсын» сәхифәсен дә хәтерлибез. Казан үзәгендәге рестораны да милли кухняны үз итүче кунаклар өчен генә түгел, шушы ризыкларны әзерләү нечкәлекләрен өйрәнергә теләүчеләр өчен дә гел ачык. Никахтан соң яшь кәләшкә аш-су дәресе уздырып, ул пешергән бәлеш белән кунакларны сыйлау да биредә генә бугай. Хәзер популяр булган сый-нигъмәтләрне генә түгел, кайчандыр табын күрке булып та, инде онытыла торган ризыкларны әзерләү серләрен дә ачып бирә ул. Бүген исә Резеда ханым безгә бәйрәм ашы булган тутырган тавык әзерләргә өйрәтер. Тутырган тавык – кунак сые, иң тәмле ризыкларның берсе санала.





Кирәк

- артык зур булмаган тавык (1,5 кг чамасы);
- 4-5 йомырка;
- 100 мл сөт;
- бер тотам укроп;
- 1-2 аш кашыгы атланмай;
- тәменчә тоз.



Фото: Ксения Богданова

Эш барышы

тавыкның эчен-тышын юып, кашык ярдәмендә тиресен итеннән аерабыз. Моны корсак тиресеннән башласаң уңай. Кашыкны сак кына гел эчкәрәк кертә барып, түш, арка һәм ботларындагы тирене кубарабыз. Муен тиресен җеп белән кысып бәйләп куябыз.

■ Тирән эчле савытка йомырка сытып, тоз, сөт кушабыз. Бик вак итеп туралган укроп салып, барысын да яхшылап туглыйбыз. Шунда ук эретелгән май өстибез.

■ Туралган укроп урынына үтә вак угычтан лимон кабыгы уып салсаң да ярый, алай да тәмле булачак.

■ Тавыкны баштүбән әйләндереп, корсак ягыннан тутырабыз. Моны бүрәнкә ярдәмендә эшләве кулай. Бүрәнкә борынын тавыкның ите белән тиресе арасына тыгып, акрын гына эчлекне коябыз. Башта – түшкәнең бер ягыннан, аннары – икенче ягыннан.

■ Тутырып бетергәч, тавыкның корсак куышлыгын җеп белән тегеп яки агач таякчыклар белән кадап куябыз. Эчлек агып чыгарлык булмасын.

■ Тавыкны чиста марляга яки тастымалга төреп, акрын гына кайнап утырган шулпага батырабыз (аякларын өскә каратып). Биек, тар кәстрүлдә пешерүе җайлырак. Тавыкның тиресе кабара башласа, нечкә энә белән төртеп, һавасын чыгарырга кирәк.

■ Талгын гына утта кайнатып, тавыкны 1-1,5 сәгать пешерәбез. Пешкәч, шулпадан алып, табынга бөтен килеш, аштәмләткеч үләннәр һәм яшелчәләр белән бизәп чыгарабыз. Аяк очларына чуклап телгән ак кәгазь салфетка урарга була.

■ Тутырган тавыкны кайнар килеш кисүе кыен. Шуңа да аның суынгагын көтәргә кирәк. Суынган тавыкны өлешләп турап, тагын бер кат кайнарлатып алалар.

■ Тутырыр өчен кибет тавыгы отышлырак. Авыл тавыгын да тутырып була, ләкин аны пешекләгәндә сак булырга кирәк, кайнар суда озак тотып, тиресен пешерергә ярамый. Суга тыкмыйча, кайнар пар өстендә генә пешекләсәң, бигрәк тә әйбәт. Эчен алганда кисемне дә кечерәк кенә итеп ясарга тырышыгыз. Тавыкның муенлысын сайларга кирәк – бәйләп куярлык тиресе булсын.



АРТИСТЛАР КЫШКА

Август – урамда гына түгел, аш-су бүлмәсендә дә кызу ай. Тизрәк кыяр тозларга, салатлар ясарга, компот кайнатырга җитешәсе... Һәр хуҗабикәнең яраткан һәм сыналган үз рецепты була. Артистларыбызның да шундый рецептларын барладык һәм аларны сезнең белән дә бүлешергә булдык.



Илсөя Бәдретдинова

Кышкы салат

- 1 кг баллы борыч;
- 3 кг кызыл помидор;
- 1 кг суган;
- 1 кг кишер;
- 6 аш кашыгы (өеп) шикәр комы;
- 300 г көнбагыш мае;
- 6 аш кашыгы аш серкәсе (6% лысы);
- 6 аш кашыгы тоз (тулыр-тулмас кына).

Помидорларны эре кисәкләргә бүләргә, кишер белән борычны – саламлап, суганны ярым боҗралап турарга. Тураган яшелчәләрне зур табакка бушатып, тозын-шикәрен, маен салып болгатырга һәм 3-4 сәгатькә калдырырга. Бу вакытта салатның суы чыга. Аннары утка куеп, кайнатып чыгарырга, аш серкәсе кушып, 5 минут пешерергә. Сүндереп, кайнар килеш парланган чиста банкаларга тутырып, калай капкач белән томаларга. Банкаларны әйләндереп каплап, калын юрган астында суытырга.

Алсу Фазлыева



Сарымсаклы помидор

Катырак һәм артык эре булмаган помидорларны юып, сабак төбен уеп алабыз да, эченә бер тырнак чистартылган сарымсак батырабыз. Әзер помидорларны парландырылган чиста банкаларга тутырып, өстеннән тозлык коябыз.

Тозлык болай ясала:

- 6 стакан су;
- 1 стакан шикәр комы;
- 6 чәй кашыгы тоз;
- 1 аш кашыгы аш серкәсе (9% лысы);
- 3-4 борчак хуш исле борыч;
- 1-2 данә канәфер.

Шушыларның барысын бергә кушып кайнатабыз.

Тозлыкны салгач, банкаларны кайнар суга утыртып, 15 минут стерильләштерәбез һәм калай капкач белән томалыйбыз.

1 литрлы банкага 2 стакан су алына.



НИЧЕК ӘЗЕРЛӘНӘ?



Лилия Муллагалиева

Өч җимеш компоты

«Бу компотның тәмен белү өчен, аны ясап карарга кирәк. Искиткеч тәмле, һәр җимешнең үз тәме чыккан була», – дип мактагач, безнең дә ясап карыйсы килеп китте.

Компот өч төрле җимештән әзерләнә:

- 5 абрикос;
- 6-7 слива;
- 15 бөртек чия.

Җимешләрне юып, 3 литрлы парланган чиста банкага салабыз, 1 стакан шикәр комы өстибез (баллырак яратучылар бераз күбрәк тә сала ала) һәм шаулап кайнап торган су коеп, шунда ук калай капкач белән томалыйбыз.

Дарчинлы помидорлар

Ваграк, катырак помидорларны юып, кабыгы шартламасын өчен берничә җиреннән энә белән тишкәләп, стерильләштерелгән банкаларга тутырабыз. Өстеннән кайнар су коеп, 15 минут тотабыз да суын бушатабыз.

Өлгерүе җитеп, изелә башлаган помидорларны блендер белән издереп, тоз, шикәр комы, сарымсак, дарчин салып, кайнатып чыгарабыз.

Литр ярымлы банкага ясасагыз, бер банкага 1 аш кашыгы тоз, 2 аш кашыгы шикәр комы, 2 тырнак сарымсак, бер чеметем дарчин, 1 аш кашыгы 9% лы аш серкәсе кирәк.

Банкадагы помидорлар өстенә кайнап торган шушы тозлыкны коеп, аш серкәсе салабыз һәм калай капкач белән томалыйбыз.

Айгөл Бариева



Баклажан кабымлыгы

Бу салатның үзенчәлеге – аның серкәсез ясалуы. Аны әзерләү өчен түбәндәге яшелчәләр кирәк:

- 3 кг помидор;
- 1,5 кг баллы борыч;
- 1,5 кг баклажан;
- 2-4 аш кашыгы тоз (кем ничек ярата бит);
- 0,5 стакан үсемлек мае;
- 0,5 стакан шикәр комы.

Помидорны иттарткычның эре иләге аша чыгарып, табакка бушатабыз да, 30 минут пешерәбез. Аннары үсемлек мае, тоз, шикәр комы салып, пешерүне дәвам итәбез. 15 минуттан саламлап туралган борыч белән бруслап туралган баклажанны өстәп, тагын 30 минут утта тотабыз. Соңыннан кайнар килеш стерильләштерелгән банкаларга тутырып, калай капкач белән томалыйбыз.





Фото: Камилә Димөхәммәтова

ХУМУС

НӘРСӘ УЛ ХУМУС?

Әлеге ризык – якын көнчыгыш халыклары кухнясыннан. Хәзер бездә дә торган саен популяррак була бара, чөнки ул тәмле генә түгел, бик файдалы да. Хумус – нут борчагы боламыгыннан әзерләнгән кабымлык.

ХУМУСНЫҢ ФАЙДАСЫ

Ул – протеин, азык җепселләре чыганагы. Аның составындагы тахини аминокислоталарга, метионинга бай. Ә болар, үз чиратында, картаюдан саклый, актив радикалларны юк итә. Тахини организмда майларны эретү өчен дә бик кирәк. Шуның аркасында майлар бил тирәсенә утырмый, бавыр күзәнәкләрен тыгылдырмый, ә чиста энергиягә әверелә. Ул организмнан зарарлы матдәләрне, авыр металларны чыгаруда катнаша.

Хумус куллану тән тиресенә, тырнакларга яхшы йогынты ясый. Файдалы май кислоталарына һәм клетчаткага бай булуы холестеринны киметергә ярдәм итә. Алай да хумусны чамалап кына ашарга кирәк, ул бик туклыклы, артыгын куллансаң, тазарта.

НӘРСӘ БЕЛӘН АШЫЙЛАР?

Хумус үзе генә дә бик тәмле. Янына майсыз гына кыздырылган көрпәле ипи бирергә була. Шулай ук хумусны төрле бутербродларда майонез урынына кулланырга мөмкин.

ХУМУС РЕЦЕПТЫ

300 г нутны төнгә салкын суга салып калдырабыз. Икенче көнне аны чиста суда чайкатып, кабаттан су өстибез һәм 1-1,5 сәгать пешерәбез. Суын сөзәбез, ләкин түкмибез, бер стакан чамасы суны кырыйга алып куеп торабыз. Пешкән нутка тахини өстибез. (Аның әзерен генә сатып алырга да була, үзегез дә ясый аласыз. Тахини – табада киптерелгән көнҗет орлыгын кофетарткычтан чыгарып яки киледә төеп әзерләнгән паста ул.) Тахинидан соң, 2 аш кашыгы зәйтүн мае салып, хумусны төерләре калмаслык итеп блендер белән туглыйбыз. Тәменчә тоз, кара борыч, паприка, 2 тырнак сарымсак салабыз. Ярты лимоннан сыгылган сутны өсти-өсти, туглауны дәвам итәбез. Куерак булса, стакандагы суны өстәп җибәрәбез.

Табынга биргәндә хумусны көнҗет орлыгы, паприка белән бизибез. Өске ягына матур сары бөҗралар ясап, зәйтүн мае сибәбез.







Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА әзерләде.


Кучкар. Әйдаманлык сыйфаты сездә элек тә булган, хәзер аеруча көчле сизелә. Уйлаганнарыгызны тормышка ашыру өчен бу сезгә ярдәм дә итәчәк, ләкин якыннарыгыз белән низагка да китерергә мөмкин.


Үгезбозау. Вакыйгаларга бай ай. Барысы да җиңел генә бармаса да, айны яхшы нәтиҗә белән төгәлләрсез. Чишелеше булмаган мәсьәләләргә ачыклык керер. Яңа хыял яки шөгылегез барлыкка килер.


Игезәкләр. Җиңел энергетикалы, куанычлы ай. Күңел күтәренкелеге эштән тәм табарга, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итәр. Яңа эшкә керешсәгез, отарсыз. Көтелмәгән табыш чыганагы барлыкка килер.


Кысла. Очрашулар, яңа танышулар көтә сезне. Күбрәк гаиләгез, туганнарыгыз турында уйларга туры килер. Моңарчы аралашмаган якын кешегез белән җылы мөнәсәбәтләр урнашыр. Артык-портыктан арынып өчен әйбәт вакыт.


Арыслан. Күтәрелеш ае. Керемегез, һөнәри дәрәҗәгез, гаиләдә кадерегез артыр. Хыялларга ирешү, башланган эшләрне төгәлләү өчен уңай шартлар булыр. Нәрсәдер телисез икән, сезне тукта-туы кыен, максатка ирешмичә тукталмассыз.


Сөмбелә. Сүзегездә тора алуыгыз хәлиткеч роль уйнар. Кызыклы идеяләрегез күп, язмыш шуларны тормышка ашырырга булышыр кеше белән очраштырыр. Эшегез белән бәйле куаныч кичерерсез.


Бизмән. Ниһаять, планнарыгызны тормышка ашыра башлар өчен көчегез дә, вакытыгыз да барлыкка килер. Каядыр чакыралар икән, баш тартмагыз, киләчәктә файдасы тиярдәй кеше белән танышырсыз.


Чаян. Айның беренче яртысы – ыгы-зыгылы вакыт. Эштә көтелмәгән хәл килеп чыгарга яки башка берәүнең вазыйфасын йөкләргә мөмкиннәр. Җитди сорауларга чишелеш табарга туры килер. Ай ахыры тыныч узачак.


Укчы. Башкаларның проблемаларын уйлап, сәламәтлегегезне һәм көчегезне исраф итмәгез. Айның икенче яртысы зур эшләр башлау яки кыйммәтле әйберләр сатып алу өчен яхшы вакыт.


Кәҗәмөгез. Ай башында акча белән бәйле киеренкелек үзен сиздерер. Шуңа да булганын кысып тотыгыз. Ә менә көч-куәтегез – искиткеч! Нәрсәгә тотынсагыз, шуны коеп куярсыз. Ай ахырында бераз күңел төшенкелеге булуы ихтимал.


Сукояр. Гаиләгездә яңадан романтик хисләр өстенлек итәр. Гаиләсезләрнең үз насыйпларын очрату ихтималы зур. Эштә дә һөнәри үсеш, яңа уңышлар көтелә. Ниндидер бик вак булып күренгән әйбер файда китерәчәк.


Балык. Тормышыгызның рәхәт һәм иң күңелле чоры булып хәтерегездә калыр. Хезмәтегездә дә күпкә ирешерсез. Иң мөһиме: уңыш сезгә үзеннән-үзе, сиздермичә, артык көч түкми генә киләчәк.

*август*та кабынган йолдызлар

Чит илләр – Россия – Татарстан



Венера Ихсанова (23.08.1933) – **журналист, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.**

Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылында туа. Әти-әнисе икесе дә орденлы укытучылар. Балачагы сугыш елларына туры килгән кызга тормыш арбасына иртә җигелергә туры килә. «8 яшьтән сыер сава идем. Мәктәп китапханәсендәге китапларны 4 нче класста ук укып чыктым», – ди ул, балачак хатирәләре белән бүлешеп. Хыялы, әлбәттә, укытучы булу. Мәктәпне тәмамлауга, игезәк туганы Ренат белән Казан педучилищесына укырга керә. Соңрак, 1958 елда, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Журналист эшчәнлеген «Совет Татарстаны» газетасында башлап җибәрә. 1960 елда аны «Яшь ленинчы» газетасына баш мөхәррир итеп чакыралар. Сугыштан соң чыгудан тукталган газетаны кабат торгызу эше йөкләнә аңа. 1977–1988 елларда – журналыбызның баш мөхәррире.



Валентина Леонтьева (1.08.1923–20.05.2007) – **телевидение дикторы, СССРның халык артисты.**

Совет чоры балаларының яраткан «тетя Валя»сы. Петербург шәһәрендә туып-үсә, Ленинград камалышын кичерә. Химия-технология институтына укырга керә, ләкин бер көн дә укымый, поликлиникага эшкә урнаша. Аннары Станиславскийның опера-драма студиясен тәмамлап, Тамбов театрында эшли. Телевидениедә – 1954 елдан, башта режиссер ярдәмчесе, соңрак «Голубой огонек», «Спокойной ночи, малыши», «Будильник», «От всей души» тапшыруларын алып бара. Соңгысы өчен СССРның дәүләт премиясенә лаек була. «Объяснение в любви» автобиографик китап авторы. Сугыш чорын һәм соңгы көннәрен уздырган Ульяновски өлкәсендә халык аңа һәйкәл куйган.



Мадонна (16.08.1958) – **җырчы, автор-башкаручы, музыкант, актриса.**

Иң бай хатын-кыз музыкант булып танылачак Мадонна Луиза Чикконе Мичиганда алты балалы гаиләдә туа, 5 яшендә әнисез кала. 1976 елда мәктәпне экстерн тәмамлап, Мичиган университетында биюче һөнәрен үзләштерә башлый. Ләкин укуын ташлап, Нью-Йоркка килә. 1982 елда «Breakfast Club» группасында бәрмә инструментта уйный башлый, җырлар яза, үзе дә җырлый. Шушы елны аның «Madonna» дип аталган беренче дискы дөнья күрә. «Like a Virgin» альбомы исә 26 миллион данәдә сатылып, Мадоннаны дөньяга таныта. Бүгенге көндә егерме тапкыр «MTV Video Music Awards» премиясен алган, җиде «Грэмми», ике «Алтын глобус»ка ия булган җырчы.

Фото: www.aeslib.ru; www.vokrug.tv

PRESSA





ҖАНГА УЕЛГАННАРДАН...

Мәскәүдәге В. И. Суриков исемендәге академик сәнгать институтын тәмамлаганнан соң, башкалада эшли башлаган яшь рәссамны әти-әнисе туган якка кайтырга күндерә. Бәлки, Илнур Сираҗиев шунда төпләнеп тә калган булыр иде. Кем белә, ул чагында бүген рәссам иҗатында тәмләп язылган авыл темасы да булмас иде... Өч еллап башкала рухы белән яшәп алган рәссам Казанга кайтып урнаша. Сәнгать академиясенә аспирантурага (Харис Якупов остаханәсенә) укырга керә, бер ел дәвамында Рәссамнар берлегендә җаваплы сәркатип булып эшли. 2003 елда ул инде Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы. «Арт-Сити» иҗат студиясе оештыра, дистә елга якын шуның сәнгать җитәкчесе булып тора. Озакламый студияне егетләргә калдырып, янәдән үз стихиясенә, баштанаяк рәсем сәнгатенә чума. Иҗат белән беррәттән, Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтының Казан филиалында 2011 елдан алып ябылганчыга кадәр студентларга дәресләр бирә. Илнур Сираҗиев ул елларда Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлекчәсе каршындагы яшь рәссамнар төркемен җитәкләүче лидер буларак та, шул ук берлек бүлекчәсендә беренче урынбасар буларак та абруй казана. Бүген ул – әлеге иҗат берлеге рәисе.

Рәссамның эшләрендә авыл темасы һәрчак үзәктә. Баксаң, балачагы Актанышның Яңа Әлемендә Мөзәлия әбисе белән Ханнан бабасы янында үткән икән. (Бу вакытта әнисе Рәйсә ханым Алабуга пединститутында укый, әтисе Ильбрус Хаҗи улы чирәм җирләрдә эшләп йөри; ул Татарстанның атказанган төзүчесе, прорабтан башлап СМУ җитәкчесенә кадәр күтәрелә).

– Бабам 1943 елда Сталинград сугышында каты яраланып, бер кулсыз кайта. Башта колхоз рәисе була, аннан атлар карый. Без аның белән печәнгә, ә авыл малайлары белән Сөнгә, Агыйделгә чыгып йөри торган идек. Әтиемнең туган ягы Әтнә районы Күәм авылына да кайтып йөрдек, – ди рәссам. – Мин бит авылны күз белән күреп кенә түгел, ә аның исенең нинди икәнен дә беләм. Әйтик, күн исе, мунча исе, яңа бәйләнгән себерке, яңа сауган сөт исе... Язганда миңа шул һәр нечкәлекне тоясың... Агач идәннең ничек шыгырдавы да хәтергә уелган хәтта... Әбинең мичтән яңа гына чыккан ипиенә ягылган сөт өсте, мәтрүшкә, урманнан җыелган үләннәр салып пешергән такта чәй... Көтү кайтыр вакыт җитсә, әби матур оекбашларын, чиста галошларын киеп капка төбенә чыга торган иде. Миңа шуларның бөтенесе әлегәчә күңелдә саклана...

Портрет геройларын да читтән эзләми. Иңгә-иң бер иҗат остаханәсендә кайнаган рәссамнарга юнәлтә ул игътибарын. Портретлар галереясы елның-елында Алабугада узган халыкара арт-симпозиумга чит илләрдән килүче сәнгать әһелләре – төрле милләт рәссамнарының портретлары хисабына да байый бара.

Кешелеккә яшәеш бүләк итүче хатын-кыз – аналар темасы исә авторның бөтен композицияләрендә дә чагылыш таба диярлек. Заманча Сөембикә белән тарихи Сөембикәне янәшә куясы килү теләге дә юк түгел. Рәссам Илнур Сираҗиевның мольбертында эш өзелеп тормый. Һәркайсы «үз эше белән мәшгуль» әбиләре – Фирая апа, Рәмзия апалар чират көтә булыр. Әле дә ике эш бергә төгәлләнеп килә. Монда да үзе якыннан белгән кешеләр. Әнә кулы-кулга йокмаган Маһинур әби шәл бәйләргә утырган. Үзе бер бәйрәм төсен алган «Каз өмәсе» дә озак көттермәс кебек... Милли йолаларны саклап көн күрүче замандашларыбыз – үзәктә.

Расиха ФАИЗОВА









ИЛНУР СИРАҖИЕВ



СЕЗНЕҢ МӨМКИНЛЕКЛӘР МӘЙДАНЫ

www.syuyumbike.ru

www. vk.com/suumbike

www.facebook.com/syuyumbike

www.instagram.com/suyumbike_journal

Реклама бүлеге: +7 (843) 222-09-78